## ЭЧТӘЛЕК


Исемең матур, кемнәр куйган? . . . . . . . . 3
Нинди исемнәр була? . . . . . . . . . . 5
Антропонимика — исем-фамилияләр турындагы фән . . 7
Борынгы төрки-татар кеше исемнәренең барлыкка килү һәм бирелү мотивлары . . . . . . . . . . . 12
Мәҗүси ышануларга һәм йолаларга нигезләнеп барлыкка килгән кеше исемнәре . . . . . . . 13
Болгар-татарларда балага исем кушуга караган йола һәм традицияләргә бәйләнешле исемнәр . . . . . 55
Ислам һәм татар исемнәре . . . . . . . . . . 136
Бөек Октябрь һәм исемнәребез . . . . . . . . 158
*Кушымта.* Татар исемнәре тупламы . . . . . 166
Әдәбият (Исемнәр турында нәрсәләр укырга) . . . 256



*Гумер Фаизович Саттаров*

КЕМ ДАНО ТВОЕ ПРЕКРАСНОЕ ИМЯ?

(на татарском языке)

ИБ № 5385

Рецензенты *Р. Ахметьянов.* Редакторы *А. Тимергалин.* Художнигы *Т. Фәезов.* Художество редакторы *Ш. Насыйров.* Техник редакторы *С. Әхмәтҗанова.* Корректоры М. *Кәримова.* Җыярга тапшырылды 7.07.89. Басарга кул куелды 24.10.89. ПФ 09196. Форматы 84×108¹/₃₂. Типогр. кәгазе № 2. Гарнитурасы «Литературная». Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 13,44. Шартлы буяу-оттиск 13,86. Нәшер-хисап табагы 12,12. Тиражы 30 000 экз. Заказ З-325. Бәясе 60 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

ББК 81(2Р-Тат)
С23

**Саттаров Г. Ф.**

С23 Исемең матур, кемнәр куйган? — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.— 256 бит.
ISBN 5—298—00243—9

Бу китапта татар исемнәренең килеп чыгышы, барлыкка килү-бирелү мотивлары, сабыйга исем сайлау һәм кушуның милли традицияләре, үсеш юллары бәян ителә. Кушымта итеп бирелгән «Татар исемнәре тупламы» 5 меңнән артык исемне үз эченә ала.

Китап киң җәмагатьчелеккә, ата-аналарга һәм ЗАГС хезмәткәрләренә адреслана.

С $\frac{4602000000—306}{М 132(03)—89}$ 286—89 ББК 81(2Р-Тат)

ISBN 5—298—00243—9

© Гомәр Саттаров, 1989

***Бөек Ватан сугышы кырларында башын салган газиз этием Фәйзерахман Габдрахман улы Саттаровның якты истәлегенә багышлыйм.***

# ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?

(Кереш сүз урынына)

Кыз бала исемендә йолдыз балкышы яки чәчәк нәфислеге, ир-ат исемендә кылыч чыңы һәм китап акылы чагылсын!

*Рәсүл Гамзатов*

Бала туды. Дөньяга яңа кеше килде. Өйгә, гаиләгә яңа ямь, юаныч, куаныч, бәхет өстәлде. Шуның белән бергә яңа туган сабый ата-анасына өстәмә мәшәкатьләр дә китерде. Аларның иң беренчесе — балага исем кушу. Аңа нинди исем бирергә? Бу сорау һәрбер ата-ананы, баланың өлкән туганнарын, кардәш-тумачаларын борчый. Чөнки исем кешегә бер генә мәртәбә бирелә һәм ул аның гомерлек юлдашына әверелә. Һәр кеше үз исеменә шулкадәр күнегә ки, ул аның туган теленең иң якын, иң газиз, иң кадерле сүзе булып тоела.

Татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Исеме җисеменә туры килә торган матур эчтәлекле, аһәңле, җиңел һәм анык әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан. Без моны татар халкының борынгы җыры «Рәйхан»дагы:

Аклы ситса күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган?
Исемең матур, кемнәр куйган?
Сине күреп кем туйган? —

дигән шигъри юлларда бик ачык күрәбез.

Татарларда урта гасырларда һәм XVIII—XIX йөзләрдә Рәйхан — киң таралган хатын-кыз исемнәреннән берсе.

Безгә гарәп теленнән кергән бу исем «зәңгәр чәчәкле хуш исле гөл, рәйхан гөле (базилика)» һәм «рәхәтлек», «ләззәт» мәгънәләренә ия. Күрәбез, Рәйхан исеменең мәгънәсе ифрат матур, үзе гаять аһәңле, әйтелеше үтә җиңел һәм ачык. Рәйхан кебек матур исемнәр халкыбызның күңеленә хуш килгән, кешегә шундый һәйбәт исем кушучылар җырларда макталган. Рәйхан, Зөбәйдә, Зифа, Зөһрә, Зөлфия, Айсылу, Миңсылу, Галиябану, Гөлниса, Алсу, Әлфия һ. б. кебек матур һәм аһәңле хатын-кыз исемнәребез әдәби һәм сәнгать әсәрләренең исемнәре булып киткәннәр.

Без дә бу китабыбызны халкыбызның «Рәйхан» җырындагы нәфис шигъри юл белән «Исемең матур, кемнәр куйган?» — дип атадык.

Кеше исемнәре — күренекле татар-башкорт шагыйре Шәехзадә Бабич әйткәнчә, гаҗәеп бер бакча ул. Ш. Бабичның, бер шигырен «Исемнәр бакчасында» дип атап, байтак кына хатын-кыз исемнәренә карата күңел түрендә уелып калырдай шигъри юллар язуы билгеле:

...Гөлнур туташ, гөлең бар бит, нурың бар бит,
Күзеңдә «сүр», күкрәгеңдә «нурың» бар бит,
Сигез оҗмах каршысында синең белән
Җир мактанган: «Минем дә бер хурым бар!» — дип.

Гөлгенәнең керфекләре гөл киенгән,
Ике күзе кичке тонык күл диелгән,
Ай-кояшның ак нурларын оялтырлык
Күзләренә чем-карачкыл нур җыелган.

Айзирәк кыз, ай, зирәк кыз, үткер теле,
Изгеләрдән изгерәктер, юктыр кере,
Күзләр — тылсым, сүзләр — әфсен, йөзе — әфлисун,
Аның кебек оҗмахында юктыр хуры...—

дигән шигъри юлларны укыгач, кем генә эстетик ләззәт, канәгатьләнү алмас икән дә, кем генә Гөлнур, Гөлгенә, Айзирәк исемен үз итмәс, аларны аһәңле һәм матур дип санамас икән?

XIX йөз башы татар шагыйре Габделҗаббар Кандалый да атаклы «Сәхипҗамал» поэмасында Сәхипҗамал исемен данлыклап: «Үзе — гел наз, күзе — нәргиз, йөзе — гүзәллек шаһы, исеменә җисемнәрен тиң яраткан илаһи»,— дип язган иде.

Җимеш бакчасында төрле агачлар үскән кебек, исемнәр бакчасында да төрле җимешләр — исемнәр бар. Халык кеше исемнәре дөньясында мәгънәви матурлыкка омтылуның классик үрнәкләрен тудырган, үзенең идеалларын

һәм тарихын чагылдыра торган исемнәр хәзинәсен (антропонимиконын) барлыкка китергән.

Яңа туган сабыйга кушу өчен исем эзләгәндә, ул исемнең җыйнак, җиңел әйтелешле, яхшы мәгънәле һәм аһәңле булырга тиешлеген истә тоту зарури. Күркәм исемнәребез күп булганга, һәрбер ата-ана шулар арасыннан үзенә ошаганын, зәвыгына туры, күңеленә хуш килгәнен, әлбәттә, заман таләпләренә җавап бирә торганын сайлый ала.

Бу китап, исемнәребезнең барлыкка килүе һәм эволюциясен мөмкин кадәр эзлекле яктыртып, укучы күңеленә хуш килә торган яхшы исем табарга булышыр дип өметләнәм. Чөнки, Дагстан халык шагыйре Гамзат Цадаса әйткәнчә:

Яхшы исем кыйммәт барсыннан да,
Аннан тугры дусны күрмисең;
Безнең хакта мәңге ядкарь саклап
Картаймыйча яши һәр исем.

## НИНДИ ИСЕМНӘР БУЛА?

Дөньядагы һәрнәрсәнең исеме бар. Кешеләр, җанварлар, шәһәр һәм авыллар, елгалар-күлләр, диңгезләр һәм океаннар, таулар һәм чокырлар, юллар һәм сукмаклар, тыкрык һәм урамнар, кинотеатр һәм завод-фабрикаларның, татлы конфетлардан алып океан пароходларынача, җыйнап әйткәндә, безне чолгап алган барлык нәрсәләрнең исемнәре бар.

Телдәге исемнәр исә гомумилекне яки аерымлыкны белдерүләре ягыннан бер-берсенә капма-каршы куела торган ике зур төркемгә аерылалар. Бер төрдән булган әйберләрнең барысы өчен уртак, гомуми атамасы — аларның күмәклек (уртаклык) исемен (мәсәлән, *кеше, шәһәр, елга, агач, таш, урман, урам, базар* һ. б.), бары тик берсен генә белдергәне — шәхси, ялгызлык исем барлыкка китерә (мәсәлән, Алсу, Айназ, Айназар, Айдар, Идел, Казан, Зөя, Арча, Саратов, Балтач, Саба, Бишбалта, Кабан, Болак, Ташаяк һ. б.). Ялгызлык исемнәренә кеше, ыруг, кабилә, халык; мифологик образлар һәм аллалар; йорт хайваннары; төрле географик объектлар; күк җисемнәре; китап, газета-журналлар, предприятие һәм учреждение исемнәре; төрле әйбер, товар атамалары һ. б. керә.

Ялгызлык исемнәре үзләре күмәклек исемнәреннән килеп чыкканнар: Тимерша — *тимер шаһ,* Тимерхан — *тимер хан* дигән сүзләрдән, Гәүһәр һәм Җәүһәр — кыйммәтле

таш исеменнән, Гүзәл — татар телендә «чибәр, күркәм, сылу» мәгънәсенә ия булган *гүзәл* сүзеннән. Саратов — «сары тау»дан, Актүбә — «ак түбә»дән, Карамасар — «карамалы»дан һ. б. Киресенчә, ялгызлык исемнәреннән күмәклек исемнәре ясалырга да мөмкин. Мәсәлән, *шовинизм* сүзе Наполеонның Шовин дигән бер солдаты исемен ән барлыкка килгән (ул башка милләт вәкилләрен өнәмәгән). *Кашемир ~ кәшемир* — йомшак, юка йон тукыма (*кәшемир күлмәк, кәшемир яулык, кәшемир шәл* һ. б.). Бу төр йон тукыма беренче башлап Һиндстандагы Кашмир штатында җитештерелгән. Тукыманың исеме әлеге штат атамасыннан алынган. *Шотландка ~ шотланкы* — башлап Шотландиядә җитештерелгән ике ягы да шакмаклы тукыма. *Сәрфинкә ~ сәрпинкә* (русча: *сарпинка*) — шакмаклы яки юл-юл бизәкле мамык җеп тукыма. Бу тукыма Саратов тирәсендәге Сарепта поселогында (Сарпа елгасы исеменнән) эшләнгән. Болгарда эшләнгән затлы күнне *болгари күн*, шул күннән тегелгән читекне *болгари читек* дигәннәр. Гражданнар сугышының атаклы герое В. И. Чапаев яратып кигән аерым формалы папаха *чапаевка* исемен алган. Сардин дигән диңгез балыгының исеме Урта диңгездәге Сардиния утравы атамасыннан алынган.

Бу төрдәге ялгызлык исемнәреннән икенче төр ялгызлык исемнәре барлыкка килергә дә мөмкин. Мәсәлән, аерым шәхесләрнең исем-фамилияләре белән аталган континент, ил-дәүләт, өлкәләр, шәһәрләр, авыллар һ. б. бар. Билгеле булганча, атаклы испан диңгез сәяхәтчесе Христофор Колумб 1498 елда Американы ача. Шушы вакыйгадан соң өч ел соңрак Көньяк Американың төньяк яры буйлап Италия сәяхәтчесе Америго Веспуччи сәяхәт иткән. Яңа континент аның исеме белән Америка дип аталган. Колумб та онытылмаган. Көньяк Америкадагы Колумбия дәүләте, АКШның башкаласы Вашингтон урнашкан административ округ, Көньяк Каролина штатының үзәк шәһәре, Огайо штатындагы шәһәр, Канада һәм АКШ территориясеннән ага торган елга һәм Канаданың көнбатышындагы бер провинция Колумб исеме белән аталган. Көньяк Америкада испан колонизаторларына каршы көрәшкән халык армиясенең башында торган генерал Семен Боливар исеме белән Боливия дәүләте һәм кара атлас тукымадан тегелгән киң итәкле эшләпә *боливар* дип аталган.

1508 елда Португалия сәяхәтчесе Васко да Гама беренче булып Африканың Мозамбик территориясенә аяк баса. Монда ул вакытта шәех Муса Мбики хакимлек итә. Менә шуңа португаллар аның биләмәләрен «Муса Мбик утра-

вы» дип исемлиләр, тора-бара бөтен илне, Муса Мбики әйтелешен үз телләренә җайлаштырып, Мозамбик дип atый башлыйлар.

1924 елның 26 январенда Октябрь революциясенең бишеге Петроград шәһәре В. И. Ленин хөрмәтенә Ленинград дип аталды. Туган илебездә Ленин исемен йөрткән тагын бик күп географик атамалар бар.

## АНТРОПОНИМИКА — ИСЕМ-ФАМИЛИЯЛӘР ТУРЫНДАГЫ ФӘН

Барлык төр ялгызлык исемнәренең килеп чыгышын, үсешен, ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән тел белеменең о н о м а с т и к а (грекча «исем кушу сәнгате» мәгънәсендәге сүздән) дигән махсус тармагы шөгыльләнә. Топонимика белән антропонимика ономастиканың ике иң мөһим һәм зур бүлекләрен тәшкил итәләр. Топонимика барлык төр географик атамаларны (топонимнарны) өйрәнә. Топонимиканың су чыганакларының исемнәрен — гидронимнарны тикшерә торган бүлеге гидронимика дип, ландшафт атамаларын өйрәнә торган бүлеге — оронимика, торак пункт исемнәрен тикшерә тооган бүлеге — ойконимика, җирле, зур булмаган географик объектларның атамаларын өйрәнә торган бүлеге микротопонимика дип атала.

Һәрбер телдә кешегә эндәшү, мөрәҗәгать итү өчен хезмәт итә торган билгеле бер антропонимик категорияләр бар. А н т р о п о н и м термины (грекча *антропос* — «кеше» һәм *онома* — «исем» сүзләреннән) кешеләрне атау өчен хезмәт итә торган исем, отчество, фамилия, кушамат һәм псевдоним төшенчәләрен аңлата һәм билгеле бер телдә кешеләрне конкрет атау берәмлекләрен билдерү өчен хезмәт итә (мәсәлән, Закир — исем, Куштан — кушамат, Шакирович — отчество, Бакиров — фамилия, Тиктормас — псевдоним һ. б. — болар барысы да антропонимнар). Татар телендә кешегә эндәшү, атап мөрәҗәгать итү категорияләренә исем, кушамат, ата исеме (отчество) һәм фамилия керә. Бу категорияләрнең килеп чыгышын, төзелеш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын ономастиканың а н т р о п о н и м и к а дигән бүлеге өйрәнә. А н т р о п о н и м и я — теге яки бу телдәге кеше исемнәре, кушаматлар, отчество һәм фамилияләрнең тулаем җыелмасының аталышы.

Ялгызлык исемнәренең этимологиясен, этнолингвистик катламнарын, структур-семантик һәм ясалыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәрешен, таралыш-кулланылыш хасиятлә-

рен өйрәнүнең тел һәм халык тарихы, этнография һәм этногенез өчен гаять зур әһәмияте бар. Чөнки кеше исемнәре, җирле географик атамалар үзләрендә телебезнең борынгы сүзләрен, грамматик күренешләрен мул саклаганнар. Боларда халыкның борынгы теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, материаль һәм рухи культурасы эзлекле чагыла.

Хәзерге вакытта ономастика фәне кызу темплар белән үсә. 1990 елның 13—18 августында Финляндиянең башкаласы Хельсинкида — XVII Халыкара ономастика конгрессы үткәреләчәк. ЮНЕСКО каршында ономастика фәннәренең Халыкара Комитеты оештырылу, безнең илдә ономастика мәсьәләләренә багышланган региональ, зональ һәм бөтенсоюз конференцияләренең шактый еш үткәрелүе, СССР Фәннәр академиясе һәм Азәрбайҗан ССР Фәннәр академиясе органы «Советская тюркология» журналы битләрендә «Ономастика» рубрикасының даими урын алуы, тюркологларның совет комитетында «Төрки ономастика» секциясе оештырылу да әнә шул турыда бик ачык сөйли.

Шунысы да игътибарга лаек, ономастика күзлегеннән караганда, туган республикабыз Татарстан — гаҗәп кызыклы һәм үзенчәлекле төбәк. Ул кимендә биш этник дөньяның: борынгы иран кабиләләренең (сармат-аланнарның һ. б.), фин-угыр, төрки, монгол һәм славян халыкларының «аралашу зонасы». Менә шул кабилә һәм халыкларның тел стихиясе чал тарих дәвамында Татарстан топонимиясе, антропонимиясе, антропотопонимиясе һәм этнотопонимиясенең этнолингвистик катламнарын тудырган, аларның үзара ныклы керешүләрен, бер-берсенә сизелерлек йогынтысын китереп чыгарган.

Татарстан топонимиясе һәм татар антропонимиясенең тарихи катламнарын ачу һәм җентекле итеп өйрәнү исә татар теле белеме алдында тора торган бурычларның гаять мөһиме дип карала. Махсус тикшерүне көтеп ята торган кичектергесез проблемалардан, мәсәлән, татар һәм башкорт халыкларының кеше исемнәрен, кушаматларын һәм фамилияләрен өйрәнүне, Идел буе топонимиясенең төрле төрки телләргә караган барлык катламнарын аеруны, фин-угыр топонимиясен тикшерүне һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Борынгы татар теленә хас булган фонетик, лексик һәм грамматик күренешләрне чагылдыра торган язма истәлекләр безнең көннәргәчә аз сакланган. Татар теленең тарихи лексикологиясе әлегә аеруча аз эшкәртелгән. Шуңа күрә татар теле тарихын, бигрәк тә тарихи лексикологиябез-

не өйрәнү, борынгы тел күренешләрен ачу өчен ономастика фәненең роле ифрат зур. Шунлыктан «...халыкларның борынгы тарихларын өйрәнү ихтыяҗы топонимияне махсус тикшерүне, шул исәптән аерым, географик районнарның гидронимиясен һәм антропонимиясен (ягъни төрки яки башка чыгышлы кеше исемнәрен һәм фамилияләрне) өйрәнүне таләп итә» (Зәкиев М. З.).

Татар исемнәрен өйрәнүнең тел тарихын, башка ономастик берәмлекләрнең килеп чыгышын, Урта Идел һәм Урал җирлегендә яшәүче фин-угыр халыклары һәм, аерата, татар һәм башка төрки халыкларның этногенезын ачыклау, татар һәм рус телләренең антропонимия тармагында багланышларын, үзара йогынтысын һ. б. ачыклау өчен гаять зур әһәмияте бар. Шушы җәһәттән берничә конкрет мисалга тукталыйк.

Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Котлыбөкәш авылы атамасының килеп чыгышы хакында җирле халык телендә ике төрле риваять йөри.

Аларның беренчесендә: «Безнең авыл исеме Бөки яки Бөкихан дигән кеше исеменнән алынган»,— дип сөйләнә. Икенчесендә исә: «Шумбут елгасы борылыш ясаган урынны элекке халык «елга бөгеше» дип атап йөрткән. Шул урынга утырганга, безнең авыл Бөгеш исемен алган»,— диелә.

Бу риваятьләрнең беренчесе игътибарга лаек булса да, атаманың Котлыбөкәш дигән тулы формасының килеп чыгышы һәм мәгънәсе бәян ителми. Риваятьләрнең икенчесе дә Котлыбөкәш атамасының асылын ачмый.

Котлыбөкәш авылы атамасының асылында Котлыбөкәш дигән борынгы төрки-болгар кеше исеме ята. Бу исем ике сүз кушылып ясалган: *котлы+бөкәш*.

Борынгы төрки телдә *кутлуг* сүзе «бәхетле», «уңыш» мәгънәсендә кулланылган. Аңа нигезләнеп: Кутлуг, Кутлуг бәк, Кутлуг бука, Кутлуг бөрт һ. б. кебек исемнәр ясалган. Котлыкыя — «Идегәй» дастаны баш герое Идегәйнең этисе исеме.

Кутлуг сүзенең азагындагы *«г»* авазы төшеп калган кутлу, татар телендә *котлы* (бәхетле) варианты байтак кына иске татар (мәсәлән, Котлыбай, Котлызаман, Котлыкай, Котлыбикә, Котлытимер, Котлыбулат, Котлыяр һ. б.) һәм башкорт (мәсәлән, Котло, Котлобай, Котлобикә, Котлобулат, Котлокилде, Котлочура, Котлоюл, Котлош һ. б.) исемнәрен ясауда актив катнашкан.

Борынгы төрки телдә *бөгә* сүзе «герой, көчле кеше, баһадир» мәгънәсен белдергән. Бөгә будрач, Бөгә йаугушы

һ. б. кебек кеше исемнәре булган. Бөек төрки каганат ханнарыннан берсе Бөке-хан (герой, көчле, кодрәтле хан) исемен йөрткән.

*Бөгә* сүзенең *бөкәш* варианты болгарларның Котлыбөкәш исемендә урын алган һәм «бәхетле баһадир, герой» дигән мәгънәгә ия булган. *Бөкәй*~*букәй* (баһадир, герой) сүзе болгар бабаларыбызда мифик образ, герой төшенчәсендә кулланылышта йөргән. Казан татарларында елый торган баланы елаудан туктату өчен: «Елама, Бүкәй килә, Бүкәй алып китәр» (Тау ягы сөйләшләрендә «Мүки килә») дип куркыту гадәте бар. Бүкәй безгә болгар бабаларыбыздан күчкән мифик образ, кодрәтле көч, мәҗүси каһарман (мифологик мирас) булып чыга.

*Букәй* сүзе элекке чорда татарлар арасында кеше исеме булып та йөргән. Пермь татарларында Букаев фамилиясе бар. Мәҗүси чуваш исемнәре тезмәсендә Мукай, Мукей исемнәре очрый. Букәй, Букай, Мукай, Мукей исемнәренең семантикасы шулай ук «көчле кеше, көрәшче, баһадир» (чагыштырыгыз: монгол телендә *бөке* — «сугышчы, көрәшче, атлет», чыгтай телләрендә *бөкә* — «көч», кыргыз телендә *пөкө* — «көчле», «кыю», якут телендә *бөгә* — «нык», «ныклык» һ. б.) мәгънәсенә ия.

Шулай итеп, Идел-Кама болгарларының Котлыбөкәш исеме «бәхетле герой, баһадир» мәгънәсен белдерә икән һәм ул, кеше исеменнән авыл атамасына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган.

Бугуруслан — Оренбург өлкәсендәге шәһәр. Бу шәһәрнең атамасы Богаарслан дигән кеше исеменнән алынган. *Бога* сүзе борынгы төрки телдә «үгез» дигән мәгънәдә йөргән. Тара татарлары хәзер дә үгезне «бога» диләр. Шушы мәгънәсендә *бога* сүзе борынгы венгр теленә кабул ителгән. Рус телендәге «бугай» (бык) да *бога*~*букадан* килеп чыккан. Богаарслан исеме кеше белән хайваннарның килеп чыгышлары уртак дип карауга нигезләнгән борынгы тотемистик ышануга барып тоташа. Әтисе арыслан ыруыннан, әнисе бога ыруыннан, яки, киресенчә булган ир балага Богаарслан дигән исем бирелгән. Богаарслан сүзе, кеше исеме буларак, хәзерге телебездән кулланылыштан төшсә дә, фамилиягә (мәсәлән, Татарстанның Зеленодольск районы Татар Танае авылында Бугуруслановлар бар) һәм топонимга әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган.

* * *

Кеше исемнәренең барлыкка килүе, үсеш-үзгәреше җәмгыятьнең социаль-тарихи һәм культура-идеология эволюциясе, иҗтимагый-экономик күренешләр белән бик тыгыз бәйләнгән. Шушы җәһәттән, татар телендә кеше исемнәренең барлыкка килү һәм үсеш-эволюциясен өч чорга: 1) мәҗүсилек ышанулары, йолалары тәэсирендә булган борынгы төрки чорга (I—X йөзләр); 2) ислам дине һәм шәригать кануннары йогынтысында булган икенче чорга (X йөз — XX йөз башы) һәм 3) Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соңгы чорга бүлеп карый алабыз.

## БОРЫНГЫ ТӨРКИ-ТАТАР КЕШЕ ИСЕМНӘРЕНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮ ҺӘМ БИРЕЛҮ МОТИВЛАРЫ

Сәяхәтчеләр иң артта калган кабиләләрдә дә һәр кешенең исеме булуы турында язалар. Мәсәлән, борынгы заманда ыруг исеме шул ыруг кешеләренең исеме булып та торган. Ф. Энгельс «Семьяның, хосусый милекнең һәм дәүләтнең килеп чыгуы» дигән хезмәтендә ыругның аерым вәкиленең исеме аның кайсы ыругка каравын да белдерә дип язды. Л. В. Никулина Төньяк Суматрада (Индонезия) яшәүче тоба-батак халкында ыруг исемнәренең буыннан-буынга бернинди үзгәрешсез мирас булып күчеп саклануын һәм гомум ыруг исемен бары тик шул ыруг кешеләре генә йөртүен күрсәтеп: «Сирегар ыругының тотемы — маймыл, Ситомпулның — эт, Бабиятның — юлбарыс, Сипоспосның — мәче, Харахапның — күгәрчен, Насутионның — ак буйвол»,— дип яза.

Соңга таба кешеләрне гаиләдә, коллективта бер-берсеннән аеру өчен шәхси исемнәр, үзләренә генә кушыла торган ялгызлык исемнәре барлыкка килгән. Исем, барыннан да бигрәк, кешегә мөрәҗәгать итү, эндәшү, бер кешене икенчесеннән аеру өчен хезмәт иткән һәм итә.

Борынгы кеше табигать кочагында яшәп, аны даими өйрәнгән, тәҗрибә туплаган, аңы камилләшкән. Кешелек үткән бу эволюция җәмгыятьнең тарихи үсешен билгели һәм ул кеше исемнәрендә дә чагылыш таба. Кешелек җәмгыяте һәм тел эволюциясе кеше исемнәре өлкәсендә ике тарихи-лингвистик катлам тудырган: 1) **җанлы һәм җансыз табигатьтәге конкрет объектларның яки күренешләрнең атамаларына нисбәтле исемнәр**. Бу төр исемнәр кешелек җәмгыятенең түбән баскычында ук туган. Алар, башлыча, тамыр сүзләрдән гыйбарәт булганнар һәм соңрак кушма төзелешле кеше исемнәрен ясауда актив катнаша башлаганнар; 2) **абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләргә нигезләнеп ясалган исемнәр**. Бу төр исемнәр кешелек җәмгыятенең дөньяны танып белүе, аң үсеше һәм камилләшүе белән бәйләнешле

рәвештә барлыкка килгән. Кеше исемнәрендә тормышның төрле ягы: җәмгыять төзелеше, хуҗалык итү ысулы, сыйнфый һәм туганлык-кардәшлек мөнәсәбәтләре, дөньяга карашлары, мифология, халыкның дини ышанулары, гореф-гадәтләре, йолалары, аң-белем һәм әхлакый-эстетик зәвыгы чагыла.

Йолалар — кешеләрнең үз-үзен тотышының тотрыклы кагыйдәләре, гадәтләре, традицияләре алар. Мондый кагыйдәләр хуҗалык тормышы, тарих, географик мохит, культура, идеология, мәгълүм социаль группаның гадәтләре нигезендә урнашалар. Йолалар тормыштагы мәгълүм вакыйгаларга үзенә күрә бер төрле җавап кайтару нормалары һәм кагыйдәләре булып торалар. Социаль гадәтләр һәм йолалар традиция төсен алалар.

Безнең карашыбызча, борынгы төрки-татар кеше исемнәрен ике зур төркемгә (бу төркемнәр эчендә берничә төркемчәгә) аерырга мөмкин:

I. Мәҗүсилек ышануларына, йолаларына нигезләнеп барлыкка килгән исемнәр.

II. Болгар-татарларда балага исем кушуга нисбәтле, борынгыдан килгән төрле ышанулар, йолалар һәм традицияләр белән бәйләнешле исемнәр.

Иң борынгы исемнәрнең барлыкка килүендә мәҗүси ышанулар зур урын тоткан. Мәҗүси ышанулар һәм йолалар ифрат күп төрле булган. Шулардан борынгы төрки-татар кеше исемнәрен барлыкка китерүдә: тотемистик ышанулар; анимистик ышанулар; күк-тәңре, күк җисемнәре культы, җир-су культы; ата-баба культы һәм туганлык терминнарының роле һәм йогынтысы аерата зур булган.

Болгар-татарларда балага исем кушу йолалары һәм традицияләре белән бәйләнешле исемнәрне, үз чиратында, тагын ике төркемгә аерып карый алабыз: 1) баланың ата-анасының, туган-кардәшләренең, нәсел-ыруның теләге, хискичерешләре, бу бала шундый сыйфатка, холыкка, дәрәҗәгә ия булсын иде дигән ниятләре яткан ышанулар, йолалар һәм традицияләргә нисбәтле исемнәр; 2) асылларында баланың үзенә нисбәтле төрле ышану-йолалар, гадәт-традицияләр яткан исемнәр.

## МӘҖҮСИ ЫШАНУЛАРГА ҺӘМ ЙОЛАЛАРГА НИГЕЗЛӘНЕП БАРЛЫККА КИЛГӘН КЕШЕ ИСЕМНӘРЕ

Авторлар коллективы тарафыннан язылган «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) дигән этнографик хезмәтнең уникенче бүлегендә татарларның борынгы

ышанулары һәм аның калдыклары турында сөйләнә. Анда татарларның борынгы бабаларының мәҗүси ышануларга нигезләнгән төрле йолаларны башкарулары: хайваннарны, кошларны, балыкларны, агачларны, үсемлекләрне, минералларны аллалаштырулары, аларга табынулары (тотемизм); җан мәңге яши, ул үлемсез дип караулары (анимизм); күккә, тәңрегә, җир-суга, утка, кояшка, айга табынулары; ата-баба культы һәм башка мәҗүси ышанулары, йолалары һәм аларның калдыклары шактый җентекләп бәян ителгән.

Мәҗүсилек ышанулары борынгы дини төшенчәләрне китереп чыгарган. Шуларның иң тәүгесе булып тотемистик ышанулар санала, алар кешегә исем бирүдә зур роль уйнаганнар.

## Тотемистик ышануларга нисбәтле борынгы төрки-татар кеше исемнәре

Тотемизм борынгы халыкларның этногенез мәсьәләләренә примитив һәм мистик карашларын чагылдыра. Борынгылар кеше заты хайваннардан яки кошлардан туган дип санаганнар. Кытай чыганакларына таянып, Л. Н. Гумилев төрки халыкларның һәм монголларның бабалары бүредән, ә Тибет халыкларының — маймылдан туган булуына ышанулары турында яза.

Казан татарларының элгәрләре булган болгарлар да бик борынгы чорда үзләренең килеп чыгышлары турында, башка борынгы халыклар кебек үк, примитив фикер йөрткәннәр. Алар уйлавынча, ыруг-кабилә башлангычында ниндидер хайван баба (тотем) торган булырга тиеш.

Борынгы төрки чорда ук таралган генеалогик риваятьләрнең берсендә һуннарның зур бер сазлык янында, ягъни Көнбатыш диңгез (Каспий, Азов) буенда дошманнар тарафыннан кырып бетерелүе хакында сүз бара. Бу сугышта ун яшьлек бер малай гына исән кала. Аны дошманнар табып алып, уң кулын, бер аягын чабып өзәләр һәм бер күзен чокып чыгарып, сазлыкка ташлыйлар. Үлемгә дучар ителгән бу малайны ана бүре табып, тәрбияләп үстерә. Ун елдан соң дошманнар белән сугышта бу егет үтерелә. Ә ана бүре таулар белән әйләндереп алынган далага кереп яшеренә һәм анда ун ир бала тудыра. Шуннан инде ун төрки кабиләнең тарихы башлана.

Бу риваятьтәге «гариплек» мотивын чагылдырган сыннар болгар шәһәрлекләрендә еш очрый. Мондый сыннар,

кагыйдә буларак, эткә, барска, бүрегә атланып утырган гарип ир яки хатын-кызны сурәтли.

Борынгы заманнарда бүрене ата-баба итеп санау, бүре тотемы төрки-монгол кабиләләре исемендә һәм, шул нигездә, кеше исемнәрендә дә чагылыш тапкан.

V йөздә Төрки каганлыгына Ашин династиясе нигез сала. Борынгы монгол телендә *ашин* сүзе «бүре» төшенчәсен белдергән. Ашин, Ашан дигән кеше исемнәре болгар-татарларда да кулланылышта йөргән (бу исемнәр казан татарларында Ашинов, Ашанов фамилияләрендә сакланган). Ашыт (ашинның күплек формасы — «бүреләр») кабиләсенең бер өлеше IV—VII гасырларда башка борынгы төрки кабиләләр составында (һуннар, торклар, түргәшләр, кәчеләр һ. б.) хәзерге Татарстанның Казан арты территориясенә килеп чыккан һәм анда Иләт елгасына коючы Ашыт елгасына үз исемен биреп мәңгеләштергән булса кирәк. Шушы елга исеменнән Иске Ашыт, Яңа Ашыт, Ашытбаш дигән татар авылларының исемнәре барлыкка килгән. Ашыт исеме болгар кабер ташы язмаларында очрый. Ашыт Тарзимин исем-фамилиясе Казан губернасы буенча 1834 елда уздырылган Ревизские сказки материалларына теркәлгән.

Төрки башкорт халкының этнонимы *баш+корт* (бүре) компонентларыннан гыйбарәт кушма сүз тәшкил итә. Төрки телләрнең угыз группасына карый торган төрек, төрекмән, азәрбайҗан телләрендә *корт* сүзе хәзер дә «бүре» мәгънәсендә кулланыла.

Бүре тотемына бәйләнешле рәвештә һәм, әлеге тотем сүзнең семантикасы киңәеп, болгар-татарларда *бүре* сүзе изгеләштерелгән һәм кешегә исем итеп бирү йоласы барлыкка килгән. Болгар-татарлар ир бала туганда ук тешле булып туса, яки, киресенчә, тугач озак вакыт теш чыкмый торса, аңа Бүре исеме яки бүре компонентлы башка исемнәр биргәннәр. Шушы җирлектә Бүре, Бүребай, Байбүре, Башбүре, Бүрекәй, Бүриш, Бүрехан исемнәре урын алган. Болардан Буриев, Бүребаев, Байбурин, Буркиев, Буркеев, Бурикаев, Башбурин, Башбуров (соңгы икесе керәшен татарларында) кебек фамилияләр ясалган. Татар халкының бер дастанында Бүрехан исеме бар. Башкортларда Акбүре-бий дигән шәхеснең булуы билгеле.

Югарыда әйтелгән мәҗүси ышану һәм йола белән бәйләнешле рәвештә, борынгы төрки телдәге *бүре* сүзенең синонимы булып йөргән *кашкар∼кашкур, корт,* монгол теленнән кергән *ашан* һәм *чаны* сүзләрен ир балаларга исем итеп кушканнар. Шушы җирлектә борынгы антропоними-

юныбызда Бүре, Кашкар, Кашкур, Ашан, Чаны, Корт кебек мәгънәдәш кеше исемнәре барлыкка килгән. Әлеге исем компонентлары катнашында Бүребай ~ Кашкарбай ~ Качкурбай ~ Чанбай ~ Кортбай; Бүриш ~ Чаныш; Бүрекәй ~ Чәнәкәй кебек синонимдаш кушма исемнәр ясалган. Болардан татар-мишәрләрдә Кашкарев, Кашкарбаев, Чанышев, Чинәкәй, Чинакаев, Чинкин, Куртов, Куртаев, Куртбаев фамилияләре барлыкка килгән. Кашкарев, Куртяев, Чинкин фамилияләре русларда да бар.

Болгар-татарларда изге барс тотемына нисбәтле рәвештә, ир бала барс (юлбарыс) кебек көчле, кодрәтле булып үссен дигән теләктән чыгып һәм борынгы төрки календарь буенча барс елында туган ир балаларга Барс исемен кушу йоласы булган. *Барс* сүзе катнашып: Айбарс, Акбарс, Барсбай, Байбарс, Барсай, Бүребарс, Бибарс, Барсби, Барсбуга, Барсхан, Илбарс, Ирбарс, Ишбарс, Карабарс, Тайбарс, Тиңбарс, Туйбарс кебек кушма исемнәр барлыкка килгән. Айбарыс, Акпарс, Анбарыс, Байбарыс, Тойбарыс, Тулбарыс (<Тулыбарыс), Тымбарыс, Элбарыс, Эшпарс, Ямбарс исемнәре — мариларда, Барс исеме — русларда (шуннан руслардагы Барсов фамилиясе ясалган), Барыс исеме исә удмуртларда да кулланылышта йөргән.

Әлеге исемнәрдән Казан татарларында һәм мариларда Айбарсов, Акбарсов, Акбарцев, Акпарсов, Ямьбарсов, Ямбарсов фамилияләре, татар-мишәрләрдә Байбарсов, Байбарцев, Байбарисов, Бибарсов, Бибарцев, Тайбарсов, Тайбарцев, Туйбарсов, Туйбарцев, Янбарисов, Янбарсов, Чанбарсов, Чанбарисов фамилияләре ясалган. Урал татарларында Барсаев фамилиясе бар. Татарларда Илбарс ~ Илбарис исеме хәзер дә шактый еш очрый.

Болгарларның барсил кабиләсе атамасының күплек кушымчасы *-т* ялганып ясалган Барсит ~ Бөрсет ~ Берсут вариантыннан Татарстан җирлегендә Берсут елгасы (Камага коя), Мамадыш районындагы Берсут-Елга, Югары Берсут, Түбән Берсут, Берсут-Сукачы дигән татар авылларының исемнәре барлыкка килгән.

Барсхан исеме башка төрки халыкларда (уйгырларда, казахларда һ. б.) да булган. Мәхмүт Кашгари «Диван»ында атасы Хөсәеннең Ыссык Күл янындагы Барсхан шәһәрендә яшәгәнлеге турында яза. Шулардан чыгып, Мәхмүт Кашгарины Барсханда әмирлек иткән Хөсәен ибне Мөхәммәт улы булырга тиеш дип саныйлар (Притцак О). Барсхан шәһәренең атамасы исә Барсхан дигән борынгы төрки кеше исеменнән алынган. «Борынгы төрки сүзлек»-

тә (Древнетюркский словарь, Л., 1969) *барс* (тигр) дигән төрки ыруг атамасы, *барсган* дигән кабилә исеме, Барс бег, Барс буга, Барс кан һ. б. кебек кеше исемнәренең булуы күрсәтелгән.

Кайбер болгар кабиләләре үзләренең килеп чыгышын эт белән бәйләгәннәр. Археологик материаллар һәм чыганаклар болгарларның һәм Казан татарларының бу хайванга хөрмәт белән карауларын раслый.

Борынгы төрки халыкларның күбесендә эт культы да була. Дунай болгарлары, Идел болгарлары, хазарлар, чувашлар, Казан татарлары һ. б. этне яман көчләрдән саклый торган изге хайван итеп санаганнар, аңа хөрмәт күрсәткәннәр. Кешене күмгәндә, йорт нигезләгәндә, борынгы төрки мәҗүси гадәт буенча, этне корбан итеп чалганнар. Эт бинаны явыз көчләрдән саклый, аларны якын китерми дип ышанып, Идел болгарлары йорт салганда аның нигезенә эт күмеп калдыра торган булганнар. Болгар дәүләте чорында салынган күп кенә ташпулатлар нигезеннән археологларның эт сөякләре яки эт рәсеме төшерелгән амулет табулары әнә шул турыда сөйли. Казан шәһәрен салганда беренче йорт нигезенә тере эт күмеп калдыру турындагы риваять тә болгар бабаларыбыздан ук килә торган борынгы мәҗүси йоланы чагылдыра. А. Х. Халиков бу турыда түбәндәгеләрне яза: «Болгарларда шулай ук эткә табыну да бик нык таралган булган. Этнең болгарча борынгы атамасы «куче» хәзерге болгар телендә үзгәрешсез саклана, ә Казан татарларында «көчек» формасында әле булса да яшәвен дәвам итә. Идел буендагы борынгы каберлекләрдә (Тархан, Танкеево), шулай ук Нови-Пазар (Дунай Болгариясе — *Г. С.*) каберлегендә табылган эт сөякләре мәет күмү ритуалында этнең үзенә бер төрле урын тотканлыгын раслап тора. Идел буе болгарлары эт улавын яхшыга юрый торган булганнар, моны без Ибне Фадлан язмалары буенча беләбез. Эткә табыну йоласы Казанның салынуы турындагы риваятьтә дә чагылып үтә: Казан стеналары астына терелэй эт күмеп калдырганнар, имеш. Казан татарларында әле соңгы вакытларгача шундый бер кызыклы гадәт яшәп килгәнлеге билгеле: бала тугач, аңа «көчек күлмәге» кидерә торган булганнар. Аерым ыруг һәм кабиләләрнең килеп чыгышлары кайбер легенда һәм риваятьләрдә эт исеме белән бәйләнештә бирелүе дә игътибарга лаеклы. Ә IX—X гасырларда Урта Идел буе өлкәләрен Шәрыкта еш кына «эттән туган печенеглар иле» («эт бечене») дип атай йөрткәннәр, Ибне Фадлан исә Идел

буе болгарларын печенегча «сакалаблар», ягъни «эттән туган кешеләр» дип атый.

Болгар-татарларда ир бала талымсыз, авыруларга бирешми торган булсын дигән теләктән чыгып, «эт» мәгънәсенә ия булган сүзләрне кеше исеме итеп бирү йоласы булган. Шушы йола аркасында борынгы телебездә «эт» төшенчәсен белдерә торган *көчек ~ коцок, канчык, әнчек, ногай, әнәк, әгер, йыт, барак, көпәк ~ күбәк* сүзләре кеше исеме булып та йөргәннәр. Тарихи антропонимиконыбызда Күбәк[1] (шушы исемнән Кубаков, Кубяков, Кибяков фамилияләре ясалган, Е. Пугачев җитәкчелегендәге восстаниегә караган документларда Аккүбәк исеменнән ясалган Аккубаков фамилиясе очрый; Мөслим районында Күбәк дигән, Питрәч районында Күбәк иле исемле татар авыллары бар. Түмән өлкәсе Вагай районындагы бер Себер татарлары авылы да Күбәк исемен йөртә), Әгер (Азнакай районында Әгер дигән татар авылы бар), Әнәк (Актаныш һәм Сарман районындагы бер татар авылы Әнәк~Анак исемен йөртә), Көчек, Барак, Әнчек исемнәре синонимдаш булганнар.

Борынгы һәм иске татар телендә Этбай, Эткол, Эткөчек, Этҗимас («эт ашамас»), Эткенә һ. б. кебек исемнәр булган.

«Казан өязенең 1602—1603 елларда сан алу кенәгәсе»ндә Көчек Атагечев, Көчек Карачаров, Көчек Тегишев, Көчек Тохтамышев, Көчек Тялтиков исем-фамилияләре бар. Болгар-татарлардан мариларда Кочек, Кочекбай, удмуртларда Кучук (шуннан Кучуков, Кучугов фамилияләре ясалган) исемнәре кулланылышка алынган. Көчек исеменнән Казан татарларында Кучуков фамилиясе ясалган. Бу фамилия русларда да очрый. Республикабызның Кукмара һәм Әгерҗе районнарындагы Көчек дигән татар авыллары атамасының асылында да болгар-татарларның Көчек исеме ята. Казан ханлыгы чорында Арча юлы өстендә Көчек исемле татар авылы булган. Борынгы Көчекбай исеме Урал татарларында Кучукбаев фамилиясендә саклан- ган.

К. Насыйри «Зөя өязе авыллары» исемле хезмәтендә: «Иң әүвәл бу Бәчек авылына Болгар яки Биләр шәһәре

---

[1] ТАССР Дәүләт музеенда Казан ханы Мөхәммәтәминнең (1487—1496 һәм 1501—1518 нче елларда ханлык иткән) гаскәр башлыгы Күбәккә моннан 500 еллар элек бакыр эшләре остасы Насыйр бүләк иткән җиз савыт саклана. Аңа чукып язылган текстта Күбәк исеме ике мәртәбә кабатлана

тарафыннан 3 кеше килеп утырганнар. Алар Бәчек баба, Әнчек баба, Янчек баба ага-эне булганнар. Олугсы Бәчек баба диерләр икән. Бәчек авылы аның исеме белән аталгандыр»,— дип яза. Биредә Әнчекнең кеше исеме булуы яхшы аңлашыла. Урта диалектның Тау ягы сөйләшләрендә *әнчек* сүзе бүгенге көндә дә «эт» мәгънәсендә кулланылышта йөри.

Кыпчакларда «эт» мәгънәсенә ия булган Кобяк һәм Барак исемнәре кулланылышта йөргән. Барак исеменнән татар-мишәрдәге һәм руслардагы Бараков фамилиясе ясалган. Башкортларда Күбәк исеме әле дә кулланылышта.

Тарихи антропонимиконыбызда монгол теленнән кергән Ногай (монголча *ноқай* — «эт») исеме дә булган. Борынгы төрки һәм монгол телләрендә н о к а й и л (эт елы) — 12 хайван циклына нигезләнгән ел исәбенең унберенче елы. Шушы елда туган ир балага еш кына Ногай (Нугай) исеме бирелгән (төрдәше Нагай). Нугай, Нагай исемнәре Казан татарларында XVI—VIII йөзләрдә актив кулланылган һәм болардан Нугаев, Нагаев фамилияләре ясалган.

Борынгы төрки халыклардан кыпчакларда эт атамалары һәм кушаматларына нисбәтле кеше исемнәре аерата популяр булган. Мондый исемнәрне байтак кына кыпчак князьләре һәм ханнары да йөрткән: Кобяк<көбәк — зур гәүдәле эт, Борак<*борак* — йонлач эт, Кочий<*көчек* — эт баласы, Боняк<*бойны ак,* ягъни ак муен (башкортларда Муйнак дигән кеше исеме булганлыгы мәгълүм), Дулеп< *түләп* — токымлы эт һ. б.

Борынгы заманнарда болгар-татарларда башка хайваннарны (*буга* — «үгез», *аю, арыслан, сыртлан, кабан, каплан, болан, борындык, бурсык, кама, кондыз* һ. б.), кошларны (*ябалак, күке, күгәрчен, карга, саескан, тукран, чыпчык, бөркет, торымтай «карчыга», тургай* һ. б.), балыкларны (*чабак, шамбы~шәмбә, ташбаш, чуртан, чөгә* һ. б.) изге итеп санау, аларны илаһи көчкә ия дип карау белән бәйләнешле, я булмаса асылларында әлеге хайваннарга, кошларга, балыкларга нисбәтле берәр мотив яткан кеше исемнәре дә барлыкка килгән һәм озак заманнар кулланылышта йөргән. Мондый исемнәрнең кайберләре, нәсел-ыруг кушаматларына, фамилияләргә һәм торак пункт (башлыча авыл) атамаларына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланып килеп җиткәннәр.

*Бога~буга~бука* сүзе борынгы төрки телдә «үгез» төшенчәсен белдергән. Себер татарлары хәзер дә үгезне *бога* диләр. Нагайбәк сөйләшендә *бугай* — «печелмәгән

үгез». Шушы мәгънәсендә *буга* сүзе борынгы венгр (мадьяр) теленә кабул ителгән. Рус телендәге «бык» та «бога∼бука»дан килеп чыккан дип уйлыйлар.

Бога (үгез) тотемына нисбәтле рәвештә, һәм, ир баланың үгез кебек куәтле булуын теләү ырым-йоласы нигезендә, төрки халыкларда *буга∼бука* сүзен исем итеп бирү гадәте булган. Борынгы төрки телдә мәсәлән, Буга, Буга кан исемнәре кулланылышта йөргән. Буга∼Бука, Бугай исемнәре татарларда Букаев, Мукаев, Бугаев, Буков, Букин фамилияләрендә сакланган. Бугай исеме русларда да булган, шуннан руслардагы Бугаев фамилиясе ясалган. Составларына *бога∼буга∼бука* сүзе кергән: Айбуга, Акбуга, Алабуга, Букатимер, Бишбука, Илбуга, Ишбуга, Исәнбуга, Котлыбуга, Күкебуга, Сасыбука, Сарыбуга, Ташбуга, Тайбуга, Төгәлбуга һ. б. кебек кеше исемнәре төрки халыкларның барысында да диярлек, шул исәптән болгар-татарларда да, булган.

Алабуга исеме Татарстандагы Алабуга шәһәре һәм районы атамасында сакланган. Электә Тамбов һәм Тобол губерналарында Алабуга исемле икешәр авыл булган. Ала-Бука авылы — Кыргызстанның Ош өлкәсендә район үзәге.

Идел болгарлары эпитафикасында урын алган кеше исемнәре арасында Инүк исеме дә бар (Хакимзянов Ф. С.). Бу исемнең асылында борынгы төрки телдә «сыер» төшенчәсен белдергән *инәк* сүзе ята. Казахлар, Себер татарлары, хакаслар, тувалар сыерны хәзер дә *инәк* диләр.

Татарларда аюны олылап, хөрмәт итеп, «аю бабай» дип атау гадәте бар. Монда аюны беренче бабабыз дип санау, аюга табыну чагылыш тапса кирәк. Төрки халыклардан якутлар аюны әле дә изге хайван итеп саныйлар, ерак бабалары дип беләләр. Башкортларда аю ыругы бар.

Аю тотемы һәм ир баланың аю кебек нык, көчле булуын теләү йоласы нигезендә, болгар-татарларда Аю, Аюбай, Аюби, Аюкай, Аюкач, Аюташ, Аюхан, Аючы исемнәре барлыкка килгән һәм урта гасыр азакларына чаклы кулланылышта йөргән. Болардан Казан татарларындагы Аюбаев, Аюбиев, Аюбеев, Аюкаев; татар-мишәрләрдәге Аюков, Аюкацев, Аюкасов, Аюташев, Аюханов, Аючиев, Аючин фамилияләре ясалган. Республикабызның Минзәлә районындагы Аю дигән татар авылы атамасының асылында Аю дигән борынгы төрки кеше исеме яки аю ыругы атамасы ята. Башкортстанның Дәүләкән районында Аюхан исемле татар, Стәрлетамак районында Аючы дигән башкорт авылы бар. Татарстанның Мамадыш районындагы Түбән Яке авылы янында 1310 елда куелган бер

кабер ташында түбәндәгеләрне укыйбыз: «...Ягкут ылы Йунус ылы Аю ылы Хөсәен бәлүкү (кабертаты)...» (Хакимзянов Ф. С.). Күргәнебезчә, без монда Аю дигән болгар исеме белән очрашабыз.

Соңгы елларда татарларда яңа туган ир балаларга Артур исемен бирү модага кереп китте. Ул нинди мәгънә аңлата соң?

Артур исеме борынгы кельт телендәге (кельтлар — Британиядә формалашкан инглиз халкының бер этник компоненты) *арт* — «аю» сүзеннән ясалган. Артур — Британиянең VI йөздә яшәгән легендар короленең исеме, ул күп кенә рыцарь романнарының төп персонажы булып киткән. Артур Бертон — Э. Войничның атаклы «Кигәвен» романының герое. Э. Войнич романы һәм шул роман буенча куелган «Кигәвен» фильмы йогынтысында, Артур исеме 60 нчы еллардан башлап татар гаиләләрендә ир балаларга еш кушыла башлады.

Артур исеме башка халыкларда да шактый актив кулланышка ия. В. А. Никонов «Ищем имя» дигән китабында: «Русларда Артур исеме һәр җирдә таралган, уртача яңа туган мең малайга бер исем туры килә»,— дип яза. Бу исем французларда Артур, Артюс, итальян һәм испаннарда Артуро, португалларда, шведларда һәм немецларда Артур, финнарда Арттури рәвешле кулланыла. Инглизләрдә кыскартылган төрләре: Арт, Арти.

Татарларда соңгы 30—40 елда Артур исеменең шактый актив кулланылышка ия булуының тагын бер сәбәбе шунда: традицион ир-ат исемнәребезнең күбесе (Тимер, Айдар, Тайфур, Гафур һ. б.) кебек, җыйнак калыпка (ике иҗектән тора) салынган булуында һәм, сонор «р» яңгырау тартыгына бетеп, аһәңле яңгыравында.

Артур исеменең «аю» мәгънәсенә ия булуы хәзер безнең өчен шактый гаҗәп тоела. Әмма дөнья халыкларында кеше исемнәренең барлыкка килү мотивларын яхшы белгәндә, бу — табигый хәл.

«Аю» мәгънәсен белдергән Медведь исеме XVIII гасырга чаклы русларда шактый актив кулланылышка ия булган. Мәсәлән, Медведь Чеботов (XIV гасырның беренче яртысы), Медведь Пожарский (XVI гасыр азагы) кебек шәхесләр мәгълүм.

Борын-борыннан төрки халыкларда җанварлар патшасы арыслан көч һәм елгырлык, азатлык символы булып санала. Болгар-татарларда һәм башка төрки халыкларда бик күптәннән Арыслан ~ Арслан исеме кушылып килгән. *Арыслан* зоологик термины борынгы төрки *арсил*

*«җирән»* + *аң* «ерткыч» сүзләре кушылып ясалган. Борынгы төрки телләрдә Арслан балбан, Арслан тегин һ. б. кеше исемнәре кулланылышта йөргән.

Арслан исемен татар теле диалект һәм сөйләшләрендә Арс, Арсай, Арсук, Арсый, Аслай, Аслан, Ослан рәвешле әйтү хас. Руслан — Арслан исеменең славянлашкан формасы. Рус телендә аның Еруслан варианты да булган. Руслан исеме хәзер татарларда да кулланыла.

Арслан антрополексемасы катнашып, чал тарих дәвамында милли антропонимиконыбызда байтак кына кушма исемнәр барлыкка килгән: Арсланбай, Байарслан, Арсланбәк, Арслангали, Арслангәрәй, Арсланбикә, Арсланбиби һ. б.

Татар исемнәр хәзинәсендә гарәп теленнән «арыслан» мәгънәсенә ия булган Газанфар, Лаис, Хәйдәр (казахларда Кайдар; Казан татарларында Кайдаров фамилиясе бар; азәрбайҗаннарда Гайдар), Әсәд һәм фарсы теленнән Шир исемнәре алыну җирлегендә әлеге исемнең 6 лексик берәмлектән гыйбарәт синонимик рәте барлыкка килгән.

«Җанварлар патшасы» атамасы *арыслан* сүзеннән ясалган болгар-татар кеше исемнәре оясына тагын *сыртлан* сүзеннән ясалган кеше исемнәрен дә өсти алабыз. «Сыртлан» дип чуар арысланга әйтәләр. Шушы зоонимик терминга нисбәтле рәвештә: Сыртлан, Сыртланбай, Байсыртлан, Сыртланбәк кебек кеше исемнәребез барлыкка килгән. Татарларда Сыртлан исеменең диалекталь вариантлары Сыртак, Сартак, Сыртай, Сыртый. Болардан Сыртланов, Сыртланбаев, Байсыртланов, Сыртланбеков, Сыртаков, Сартаков, Сыртаев, Сыртиев фамилияләре ясалган.

Академик А. П. Окладников карашынча, кабан культы монгол телле халыкларда гына түгел, Европа һәм Азиянең башка халыкларында да киң таралган була. Галимнең фикеренчә, кабан ирлек көч-куәтен, гайрәтен зооморф формада гәүдәләндергән.

Болгар-татарларда кабан дуңгызын изге хайван итеп олылауга һәм ир баланың кабан кебек көчле, гайрәтле, батыр булуын теләү йоласына бәйле рәвештә: Кабан, Кабанай, Кабанбай, Кабанбәк, Ташкабан һ. б. исемнәр барлыкка килгән. Бу исемнәрдән Казан татарларындагы Кабанов, Кабанаев, Кабанбаев, Кабанбиков фамилияләре ясалган. Кабанов фамилиясе русларда да бар.

Борынгы төрки телдә «яшь кабан» төшенчәсен белдергән *торай* зоологик терминыннан Торай, Турай, Турай-

бәк, Турайхан һ. б. кебек кеше исемнәре ясалган. Болгар каберташ язмаларында Торай исеме бар (Хакимзянов Ф. С.). Калмыкларда «яшь кабан» төшенчәсен белдергән Шовшур исеме кулланылышта йөргән.

Турай исеме, Татарстанның Менделеевск районында Турай дигән татар авылы атамасына күчеп, безнең көннәргәчә сакланган. Әлеге авыл зиратының милади белән 1596 елга караган каберташ язмасында Турай исеме очрый. Турай исеменнән Казан татарларында Тураев фамилиясе ясалган. Бу фамилия русларда да бар.

Борынгы заманнарда төрки халыкларда хайван балаларының атамалары булып йөри торган зоологик терминнарны, хайван балаларының сөйкемле, матур, шаян булуларын күздә тотып, башлыча ир балаларга исем итеп бирү гадәте булган. Борында әлеге йола белән бәйләнешле рәвештә: Бүлтерек (бүре баласы), Көчек (эт баласы), Колын, Тай, Бузагу (бозау), Пәрәү (бозау), Кузый∼Күзи (язгы бәти), Түләк (көзге бәти), Бота (дөя баласы) һ. б. кебек кеше исемнәре барлыкка килгән. Аларның Колынбай, Колынтай, Колынкай, Колынбикә; Кузыбай, Кузыбала, Кузыбәк, Кузыкилде, Кузыгол; Көчекбай, Көчеккол; Тайбуга, Тайбарс, Тайбәк, Тайбикә, Тайхан, Тайхуҗа, Тайчура, Тайлак; Актай, Каратай, Тансыктай; Төгәлбота, Ботагөз һ. б. кебек кушма төзелешле төрләре дә кулланылышта булган. М. З. Зәкиев 633 елда Бөек Болгар дәүләтен төзегән Кубрат ханның олы улы Батбай исеме *бота* (дөя баласы)+*бай* сүзләреннән гыйбарәт дигән карашта тора. Бу төр кеше исемнәре хәзерге антропонимиконыбызда очрамый. Күбесе татар фамилияләренә (мәсәлән, Колынбаев, Колынкаев, Актаев, Каратаев, Каратай, Кузыев, Кузиев, Кузеев, Кузубаев, Кузыгилдиев, Кузыбеков, Көчеков, Кучуков, Кучукбаев, Тайбугин, Тайбарсов, Тайбеков, Тайханов, Тайгузин, Тайчуров, Тайчурин, Тансыктаев һ. б.) һәм авыл атамаларына әверелеп, безнең көннәргә килеп җиткәннәр.

Мәсәлән, Лаеш районында Пәрәү дигән татар авылы бар. Бу авылның Казан ханлыгы чорында булуы мәгълүм. Пәрәү атамасының асылында Пәрәү дигән борынгы төрки-болгар кеше исеме ята. Хәзерге Ульяновск өлкәсенең төньягындагы Парау (Боровки) дигән татар авылы да бик борынгы болгар авылларыннан санала. Электә аны Парау иле дип йөрткәннәр. XIX йөзнең беренче яртысында яшәгән татар шагыйре Габделҗаббар Кандалый бу авылның исемен «Сәхипҗамал» поэмасында берничә мәртәбә телгә ала:

Саба җиле, исәр булсаң, Парау атлыйг нәфис җайга,
Сәламемне тикергәйсән Сәхипҗамал абыстайга.

Борынгы кыпчак исемнәре арасында да килеп чыгышлары йорт хайваннары балаларының атамаларына кайтып кала торганнары байтак: Тоглый<*тоглу*~*тоглы* — өч айлык бәрән, Гзак<*козу*~*кузу* — сарык бәрәне, Алак<*улак* — кәҗә бәрәне, Турундей<*торун*~*турун* — дөя баласы һ. б.

Төрки-татарларда атны аеруча ярatkаннар һәм атның төрле атамалары да, тотемистик ат культы йогынтысында, кеше исеменә әверелгән: Елкыбай, Елкычура, Аргынбай, Аргын (*аргын* — кыргый ат белән йорт атыннан туган токым. Казан татарлары составында аргын дигән кабилә булган), Субай (*субай* — хәрби ат. Субай исеменнән Субаев фамилиясе ясалган), Атбасар, Байтал (шуннан Байталов фамилиясе), Алаша (шуннан Алашаев фамилиясе) һ. б. Чабыш атлары токымын белдерә торган *юртак, аргамак, чаптар, юрга, тулпар* сүзләренә нигезләнеп, Юртак, Аргамак, Чаптар, Юрга, Юргатай, Тулпар кебек исемнәребез ясалган. Бу исемнәр Аргамаков, Чаптаров, Юртаков, Юргин, Юргатаев, Тулпаров кебек фамилияләрдә сакланганнар.

*Каплан* (леопард) зоологик терминына нигезләнеп ясалган борынгы исемнәр күп түгел: Каплан, Капланбай, Капланбәк, Каплангәрәй. Бу исемнәрдән татар-мишәрләрдә Капланов, Капланбаев, Капланбеков фамилияләре ясалган.

Төрки халыкларда болан — сылулык һәм нәфислек символы исәпләнгән. Болгар-татарларда *болан* сүзенә нигезләнеп: Болан, Боланбай, Боланбәк, Боланбикә, Боланкай, Боланчы, Болантай исемнәре барлыкка килгән. Казан ханлыгы чорында Болан исеме актив кулланылышта булган.

Керәшен татарларында Болан исеменнән Боланов (Буланов) фамилиясе ясалган. Казан татарларында Боланкаев (Буланкаев), Буланчиев, Буланчин, Боланбеков (Буланбеков), Боланбаев (Буланбаев) фамилияләре бар.

Болгар-татарларда һәм аларның ут күршеләре башкортларда *бурсык, кама, сусар, кондыз, байбак* кебек җәнлекләрнең атамаларыннан ясалган Бурсык, Камабай, Камакай>Камкай, Сусар, Сусарбай, Сусарсылу, Кондыз, Кондызбай, Кондызбикә, Байбак һ. б. кеше исемнәре дә булган. Бурсык исеменнән Казан һәм Себер татарларында Бурсуков, Барсуков фамилияләре барлыкка килгән. Барсуков фамилиясе русларда да бар. Камакай исеменең фонетик тартылыш кичергән Камкай вариантыннан Себер

татарларында һәм татар-мишәрләрдә Камкаев фамилиясе, мишәрләрдәге Камка вариантыннан Әлки һәм Чирмешән районнарындагы Камка авыллары атамасы ясалган. Казан татарларында Байбак (суер) исеменнән Байбаков фамилиясе барлыкка килгән (русларда да бар).

Болгар-татарларда борындык дигән җәнлек атамасына нигезләнгән Борындык исеме кулланылышта йөргән. Каюм Насыйри фикеренчә, Борындык — болгар исеме. Бу исем, авыл атамаларына һәм фамилияләргә эверелеп, безнең көннәргәчә сакланган. Казан губернасының Зөя өязендәге (хәзер Татарстанның Апас районындагы) Борындык авылы исеменең килеп чыгышы хакында К. Насыйри менә нәрсә яза: «Болгар харап булган вакытларда Арыслан дигән бер адәм бар икән; үзе Болгарда вафат булгандыр. Аның ике углы Болгардан күчеп, Зөя янына күчеп килгәннәр. Бер углына Борындык баба диерләр икән. Икенче углы Чулпан баба дип мәшһүрдер. Борындык баба исемле углы килеп, Зөя суы янына, Бәрле суы тамагына урман эченә урын ачып утыргандыр. Борындык авылы дип исем шуннан калган икән».

Татарстанның Чүпрәле районында Борындык дигән татар-чуваш-рус поселогы һәм тимер юл станциясе бар. Казан татарларында Борындыков (Бурундуков), русларда Бурундуков фамилиясе очрый. Казан шәһәрендә яшәүче руслар арасында Бурундуковский фамилиясен йөртүче шәхесләр бар.

Кыйммәтле мех бирә торган су җәнлеге җофар зоологик терминына нигезләнеп, ир-ат һәм хатын-кыз исеме булып йөри торган Җофар исеме һәм Җофарбану, Җофарбикә, Җофарсолтан, Җофарсылу һ. б. кебек хатын-кыз исемнәре ясалган.

Асылларында кыйммәтле мехлы җәнлек *кеш* атамасы яткан Кеш, Кешбай, Кешби, Кешмөхәммәт кебек кеше исемнәре татарларда XVIII йөзгә чаклы кулланылышта йөргән. Кешбикә дигән хатын-кыз исеме, Касыйм татарларында Кишбикә рәвешен алып, XVII йөздә язылган «Кишбикә бикәч» васыятьнамәсендә сакланган. Кеш исеме гарәпләрдән кергән Сәмүр (кеш) исеме белән синонимдаш. Соңгысыннан Самуров, Самурин фамилияләре барлыкка килгән.

Кыргый хайваннарны һәм кошларны гомумиләштереп атаучы *киек* зоологик терминына нигезләнеп, борынгы заманнарда ук Киек, Киекбай, Киекхан кебек кеше исемнәре ясалган. Болардан Киеков, Киюков, Киекбаев, Киекханов кебек фамилияләр барлыкка килгән.

Борынгы төрки телдә *аң* сүзе дә «киек, пошп, болан, кош-корт» мәгънәсен белдергән (шуннан *аңчи* — аучы, сунарчы). Себер татарлары хәзер дә пошины *аң* диләр. Борынгы төрки-татар Аңкилде исеме «киек, болан (күчерелмә мәгънәдә — бала) килде, туды» мәгънәсенә ия. Бу исем Казан шәһәренең 1565/68 һәм 1646 еллардагы сан алу кенәгәләрендә очрый.

Мәҗүси заманнарда Ябалак, Өге, Козгын, Күке, Күгәрчен, Карга, Саесккан (Себер татарларында Саускан), Чыпчык, Торымтай (карчыга), Акчарлак, Тургай, Торна һ. б. кебек исемнәр барлыкка килгән.

Татар халык әкиятләрендә *ябалак* — бәхет китерүче кош. Төрки халыкларда бу кош атамасын, ир баланың бәхетле булуын теләп, исем итеп бирү йоласы булган. Ябалак исеменнән Казан татарларында Ябалаков фамилиясе ясалган. Татарстанның Апас районында Ябалак исемен йөртүче ике авыл бар.

Билгеле булганча, мәче башлы ябалакны *байгыш* диләр. Байгыш сүзенә нигезләнеп, Байгыш исеме ясалган һәм иске татар телендә кулланылган. Шул исемнән татарларда һәм русларда Байгышев, Байгушев, Байгушов фамилияләре барлыкка килгән.

Борынгы төрки халыкларда *козгын* хакимлек, акыллылык символы булган. Козгын зоологик терминыннан Козгын исеме барлыкка килгән. Бу исем татар-мишәрләрдә Козгынов (Кузгунов) фамилиясендә сакланган.

Борынгы заманнарда төрки халыкларда һәм монголларда *күке* (кәккүк) кошы атамасын гаиләнең бердәнбер ир баласына исем итеп бирү йоласы булган. Шул җирлектә төрки халыкларда Күке, Кәккүк, Күкебай, Күкехан, Күке-Буга һ. б. кебек исемнәр барлыкка килгән. Төрки зоонимик терминнан ясалган Күке ~ Кәккүк ир-ат исеме безгә гарәпләрдән кергән Зәйнәп (күке, кәккүк) дигән хатын-кыз исеме белән мәгънәдәш. Тарихи чыганаклардан 1391 елда Алтын Урданың Җүҗи олысында Күке-Буга исемле гаскәр башлыгының булуы билгеле. Бу исем ике зоологик терминнан тора: Күке — кәккүк, Буга — үгез. Күке исеме Татарстанның Зеленодольск районы Мулла иле авылында Күке нәселе шәҗәрәсендә һәм нәсел кушаматында сакланган: Күке баба ⟶ Сәйфулла ⟶ Фәтхулла ⟶ Хәйбулла ⟶ Габдесаттар ⟶ Габдрахман ⟶ Фәйзерахман ⟶ Гомәр ⟶ Айвар ⟶ Айназар.

Галимнәр, шәҗәрәләргә нигезләнеп, тарихи даталарны билгеләгәндә, буын арасында уртача 25—30 ел вакыт саныйлар. Димәк, Күке нәселенең җеп очында торган Күке

баба моннан 250—300 еллар элек, ягъни XVII гасыр азаклары — XVIII гасыр башларында яшәгән һәм шул вакытларда Казан татарларында Күке исеме кулланылышта йөргән булып чыга.

Болгар-татарлардан марилрга Куке, Кукубай, удмуртларга Кукя, Кукылей исемнәре кулланылышка алынган. Үзбәкләрдә Куки, Кукибай, Куким, Кукиммирза, Кукихон исемнәре әле дә кулланылышта йөри.

Иске татар телендә асылында *күгәрчен* зоологик термины яткан Күгәрчен исеме дә кулланылышта булган. Шушы исемгә мәгънәдәш фарсы Кабутар, гарәби Юныс исемнәрен кулланылышка алу антропонимиябездә үзара синонимдаш ир-ат исемнәре рәтен барлыкка китергән. Татарларда Күгәрчен һәм Кабутар исемнәрен хәзер кушмыйлар. Татарстанның Балык Бистәсе районында Күгәрчен дигән татар авылы, Башкортстанда Күгәрчен дигән район үзәге бар. Кубутар исеменнән Казан татарларындагы Кубутаров фамилиясе ясалган. Юныс исеме әле дә киң кулланыла.

Н. А. Баскаков бөек рус язучысы Н. В. Гоголь фамилиясе килеп чыгышы белән поляк-украин чыгышлы Гоголь фамилиясенә барып тоташа, бу фамилиянең асылында исә күк, күксел мәгънәсендәге төрки *гөгүл∼көгүл* (шуннан кыргызча *көгәл,* татар диалектында *күгәл* «ата үрдәк») сүзе ята дип саный. Юрий Федосюк бу фамилиянең этимологиясен кыр үрдәкләренең чумарга яратучан бер токымын белдерә торган *гоголь* зоологик терминына кайтарып калдыра. Хәлбуки, гоголь кошы атамасының килеп чыгышы без югарыда сүз алып барган *гөгүл* сүзенә кайтып кала.

Болгар-татарларда ир баланың кыю һәм җитез булуын теләп ау кошы атамасын исем итеп кушу йоласы да булган. Шушы тотемистик йолага нисбәтле рәвештә, борынгы заманнарда ук Бөркет, Лачын, Каракош, Алчын, Шонкар, Тогрул кебек синонимдаш исемнәребез барлыкка килгән. Соңрак болгар-татарларга фарсы теленнән кергән Шаһбаз (бөркет) һәм Шаһин (аксыл төстәге лачын) исемнәре өстәлгән. Әлеге антропонимик синонимик ояга болгар бабаларыбыз V—VII йөзләрдә Азов буе далаларында яшәгәндә скифлардан алган Чәркәс (бөркет) исеме дә керә.

Борынгы заманнарда ук татар исемнәре хәзинәсенә «бөркет баласы» мәгънәсен белдерә торган *балапан* зоологик терминыннан ясалган Балапан исеме дә өстәлгән.

Без югарыда сүз алып барган исемнәргә нигезләнеп, Казан татарларында Бөркетов (Беркутов), Алчинов, Ла-

чынов (Лачинов), Тогрулов, Шонкарев (Шункарев), Шаһбазов, Шагинов, Балапанов фамилияләре барлыкка килгән. Удмуртларда һәм русларда да Беркутов фамилиясе бар. Шоңкар исеменең фонетик үзгәреш кичергән Шыңар вариантыннан Татарстанның Саба районындагы Олы Шыңар, Кече Шыңар авылларының исемнәре барлыкка килгән. Бу борынгы авылларның Казан ханлыгы чорында булулары мәгълүм.

Ерткыч кош *карчыга* атамасын белдерә торган орнитонимнарга нигезләнеп тә кеше исемнәре ясалган. Карчыга, Тойгын (ак карчыга), Торымтай, Сарыч кебек үзара синонимдаш исемнәребез әнә шундыйлардан. Әлеге исемнәрдән Казан татарларында Сарычев (бу фамилия русларда да бар), Себер татарларында Турымтаев, Турынтаев фамилияләре барлыкка килгән.

Татарларда *кубаш* һәм *суер* кошы атамаларына нигезләнеп Кубаш, Суер, Суербай кебек борынгы ир-ат исемнәре ясалган. Алар, Кубашев, Суеров, Суербаев фамилияләренә әверелеп, безнең көннәргәчә сакланып килеп җиткәннәр.

Болгар-татарлар төс-гәүдәсе белән күркәм яки матур сайрый торган кошларның атамаларын борын-борыннан кыз балаларга исем итеп кушканнар: Аккош, Сузгын (фазан), Сузгынбикә, Сандугач, Сандугачбану, Сандугачбикә, Сандугачсылу, Былбыл (фарсыча *былбыл* — сандугач), Былбылниса, Гандәлиф (гарәпчә *гандәлип* — сандугач), Карлыгач, Карлыгачбану, Карлыгачбикә, Карлыгачсылу, Тутый (попугай), Һөдһөд һ. б.

Татар антропонимиконының кош атамаларыннан ясалган кеше исемнәре төркеменә фарсыча «кош» төшенчәсен белдерүче Тайфур, гарәпчә «яр карлыгачы, кершә» мәгънәсенә ия булган Әбабил исемнәре өстәлгән. Соңгысыннан Абабилов, Бабилов фамилияләре ясалган.

Татар антропонимик системасында асылларында балык атамалары яткан борынгы кеше исемнәре дә урын ала. Чабак, Чабакай, Чуртан, Комай, Керкә (пескарь), Ташбаш, Сазан, Шамбы, Чөгә кебек кеше исемнәре әнә шундыйлардан. Балык атамаларыннан гыйбарәт төркемгә караган кеше исемнәре борынгы заманнарда русларда да булган: Линь, Окунь, Сом, Судак, Ерш, Карась, Щука һ. б.

Чабак, Чапак, Чупак, Чабакай, Чуртан, Сазан, Ташбаш, Шамбы, Чөгә һ. б. кебек нәсел-ыру кушаматлары (мәсәлән, Зеленодольск районы Мулла иле авылында Чупак, Чөкә, Шәмбә, Ташбаш нәсел-ыру кушаматлары бар)

ясалган. Үз чиратында, әлеге кушаматларга нигезләнеп, XIX йөз урталарында Чабаков (Тәтеш районы Олы Тархин авылы), Чапаков (Апас районы Апас авылы, Төмән өлкәсененең Төмән районы Ямбай авылы), Чабакаев (Арча районы Олы Мәңгәр авылы), Чупаков (Зеленодольск районы Мулла иле авылы), Сазанов, Чуртанов, Ташбашев кебек фамилияләр барлыкка килгән.

Мәҗүси ышануларга бәйле исем йолаларының бер үзенчәлекле ягы — кеше исемнәрен табулаштыру.

Н. А. Баскаков Алтай халыкларының өлкән буыннары телендә бүгенге көнгәчә *табу* эзләре саклануы турында яза, гаилә һәм ыруның өлкән ир кешеләренең исемен хатын-кызларга әйтергә ярамавын, аларның исемнәре тиешле эвфемизмнар белән алмаштырылып йөртелүен әйтеп үтә. Мәсәлән, Куй дигән ирләр исеме тасвири эвфемизм Мараачы (Мөңгерәүче), Чочка яки Какай (Дуңгыз) — Түрткүн (Казучы) эвфемизмы, Малта (Балта) исеме — Кезинер (Кисүче), Бөрү (Бүре) исеме — Улуучы (Улаучы), Ийт (Эт) исеме Үречи (Өрүче) исемнәре белән алмаштырыла икән.

Билгеле булганча, *табу* — кулланырга ярамый торган, тыелган сүз.

Борынгы заманнарда кешеләр, балага бирелгән исем аша югары, илаһи көчләрнең уңай тәэсиренә өметләнү белән бергә, ул көчләрне ачуландырмау, ярсытмау чараларын да табарга тырышканнар.

Күп кенә халыклар ата-баба исемен йөрткән баланың исемен билгеле бер вакытка кадәр әйтмәгәннәр, кабатламаганнар. Шул юл белән ата-баба рухын ачуландырмаска тырышканнар. Таҗикларда, мәсәлән, ата-баба исемен йөртүче баланың исемен әйтмәү яки кабатламау гына түгел, хәтта аның үзен дә ачуланмаска кирәк.

Татарларда балага исем бирелгәч, теге яки бу сәбәпләр аркасында, аңа, баштагы исемен алмаштырып, яңа исем бирү очраклары а н т р о п о н и м и к  т а б у күренешенә керә:

а) гаиләдә бала тугач, үлү еш кабатланса, яңа туган баланың беренче кушылган исеме алмаштырылып, яңа исем бирелә. Мәсәлән, балага башта Мөхәммәтҗан яки Галимҗан исеме бирелгән булса, ата-ана аны, Тимерҗан яки Туктар исеме белән атап, баланы сакларга омтыла.

б) бала туып, йола тәртибендә исем кушылганнан соң, баланы фиктив төстә «сатып алалар» һәм аңа Сатылды, Сатыбалды, Сатбай, Сатбикә, Сатыш, Сатлык, Сату, Сатлак һ. б. кебек исемнәр бирелә. Алтайлыларда әле хәзер дә

ир балаларга Сатлак, Сатылыш, Сату исемнәрен кушалар.

Һәр очракта да беренче исемгә табу салына, ягъни ул исемне әйтү тыела.

в) бала үсә башлагач, аңарда теге яки бу (күп очракта начарга юрала торган) үзенчәлек ачыла һәм исем яңа исемгә алмаштырыла (мәсәлән, берәр җиренә миң чыккач, азмасын өчен, Миңлебай, Миңсылу, Миңлегөл, Миңлеяр, Миңлехан һ. б. исемнәр кушыла).

г) гаиләдә килеп чыккан теге яки бу күңелсез хәлдән соң, баланың исемен алыштыру. Мәсәлән, гаилә башлыгы, аны туйдыручы һәм тәрбияләүче ата кинәт үлеп китсә, ана, ятим калган балаларына, бәхетле, бай һәм тук тормыш теләп, яңа исемнәр (Байбул, Байтор, Бәхтияр һ. б. кебек) бирә.

Октябрьгә кадәр татар гаиләләрендә киленнәр иренең әтисеннән һәм өлкән ир туганнарыннан тел яшергәннәр, алар белән сөйләшмәгәннәр. Ир белән хатын бер-берсенә үз исемнәре белән эндәшмәгән, исемне *сиңа әйтәм*>*сиңайтәм* сүзтезмәсе яки *атасы (әтисе), анасы (әнисе)* сүзләре белән алмаштырганнар. Без биредә ерак гасырларда барлыкка килгән антропонимик табу күренешенең тагын бер калдыгын очратабыз.

Агач, үсемлек, аларның җимешләре, өлешләре атамаларына нигезләнеп тә кеше исемнәре ясалган. Борынгы заманнарда төрки халыкларның, шул исәптән болгар-татарларның, *артыш, имән, тирәк, карагач, карагай, нарат, каен, арча, бадьян, тал* агачларын изге итеп санаулары, илаһи көчкә ия дип караулары нәтиҗәсендә, асылларында теге яки бу фитоним (агач, үсемлек атамасы) яткан кеше исемнәре барлыкка килгән.

Болгар-татарларда *имән* агачын изге итеп санау һәм ир баланың имән кебек нык-таза, чыдам булуын теләү җирлегендә: Имән, Имәнәй, Имәнбай, Имәнгол, Имәнкилде, Имәнбәк, Имәнкәй исемнәре ясалган. Болардан Имәнбаев, Имәнголов, Юмангулов, Имәнәев, Имәнбеков кебек фамилияләребез барлыкка килгән.

Борынгы төрки халыкларда изге агач (ыруг агачы) булып саналган *тирәк* атамасын ир балаларга исем итеп бирү — аларның озын гомерле булуларын теләү белән бәйләнешле. Шул җирлектә болгар-татарларда да Тирәк (бу исем Азнакай районындагы Урсай авылында Тирәков фамилиясендә сакланган), Актирәк, Байтирәк (өянке) исемнәре кулланылышта йөргән. Байтирәк исеме әтисе йортында калачак ир балага кушылган. Татарларда Бай-

тирәков фамилиясе шактый киң таралган. Удмурт һәм мариларда Байтирәк исеме хәзер дә кулланылышта йөри. Казан татарларында Байтирәк формасында бернинди кушымча алмаган фамилия дә бар. Иштирәк — иш тирәк, таяныч, Куштирәк — куш тирәк, таяныч. Борында болгар-татарларда игезәк ир балалар туса, берсенә Иштирәк, икенчесенә Куштирәк дип исем кушу гадәте булган. Бу исемнәр бездә Иштирәков һәм Куштирәков фамилияләрендә сакланган. Иштирәк — Татарстанның Тукай һәм Әлмәт районнарындагы татар авыллары атамасы. Илтирәк исеме — ил тирәге, таяныч мәгънәсендә (шуннан Илтирәков фамилиясе ясалган).

Этимологияләре агач атамаларына нисбәтле Бадьян, Карагач, Куак, Куакбай, Карагай, Нарат, Ишнарат, Артыш, Каенкол, Талморза кебек борынгы исемнәребезнең төрдәшләре юк диярлек, алар, башлыча, аерым семантик оялар тәшкил итми торган ялгызак исемнәр. Урал һәм Башкортстан татарларында Карагаев, Себер татарларында Карагачев, Казан татарларында Артышев (Газиз Кашаповның «Язмышыңа ышан» романының баш герое — Фазыл Артышевич Айбулатов), Каенкулов, Талмурзаев, Талмурзин фамилияләре бар.

*Алма* ботаник терминына нигезләнеп Алмакай, Алмахан дигән ир-ат; Алма, Алмабикә, Алмабану, Алмагөл, Алмайөз кебек хатын-кыз исемнәребез ясалган. Өрек дигән ир-ат, Йөзем, Хөрмә дигән хатын-кыз исемнәребез булган. Җиләк, Чия кебек хатын-кыз исемнәре әле дә кулланылышта йөри.

Агачның бер өлешен белдерә торган *ботак* терминыннан Ботак дигән борынгы исемебез ясалган. Бу исемне нәсел агачының аерым ботагын тәшкил итүче ир балага кушканнар. Казан татарларында Ботаков, русларда Бутаков фамилиясе бар. Азәрбайҗаннарда Будагов фамилиясе — киң таралган фамилияләрнең берсе.

Агач атамаларына нисбәтле төрки-татар чыгышлы борынгы исемнәребез төркеменә соңрак фарсы теленнән кергән Анар — Анара (гранат агачы һәм җимеше), Гөлнар, Гөлнара, Бадам (миндаль агачы һәм җимеше), Бадамша, Сәбак (алма) исемнәре өстәлгән.

Камыш исеме төз, зифа буйлы булып үссен дигән теләктән чыгып, ир балаларга да, кыз балаларга да кушылган. Казан татарларында Камышев фамилиясе бар. Камышбикә — камыш кебек төз, зифа буйлы, сылу мәгънәсендәге исем.

Борында төрки халыкларда, шул исәптән болгар-татарларда, Арпа, Борай, Ногыт, Кузак, Ясмык һ. б. кебек иген-тару атамаларына нигезләнеп ясалган ир-ат исемнәре дә кулланылышта йөргән.

Матурлык, гүзәллек, сафлык, мәхәббәт символы булган гөлчәчәк атамаларын кыз балаларга исем итеп бирү, аларның гөлчәчәк кебек матур һәм саф булып үсүләрен теләү борын-борыннан дөньядагы барлык халыкларга да диярлек хас булган. Шуңа бәйләнешле рәвештә, татар исемнәре хәзинәсендә генезислары төрле телләргә карый торган Чәчәк, Чәчкә, Гөлчәчәк, Чәчкәгөл, Чәчкәнур, Гөлсирень, Гөлүсә, Гөлия, Гөлфая, Фаягөл, Миңлегөл, Гөлсылу, Сылугөл, Айгөл, Гөләем, Гөлкәй, Гөлсу, Гөлназ, Гөлсинә, Гөлниса, Гөлзифа, Гөлшат, Гөлгенә, Гөлчирә, Гөлбостан, Гөлҗамал, Гөлзадә, Гөлзавәр, Гөлфия, Ганҗә (чәчәк бөресе, бутон), Ислегөл, Исмегөл, Рәүзәт (гөл бакчасы), Рауза (гөлбакча, чәчәклек), Рәгънә (роза чәчәге), Раузабикә, Зәригөл (алтын гөл), Вәгъдәгөл, Ачылгөл (ачылыр, терелер, сәламәтләнер гөл — кыз бала), Рәйхан ~ Рәйханә, Рәния (рәна чәчәге), Лалә, Тюльпан, Лилия, Сөмбел, Сөмбелә, Миләүшә, Фиалка, Виолетта, Нәркис, Ландыш, Резеда, Роза, Розагөл, Розалина, Розалия, Ясминә, Раузагөл һ. б. кебек «чәчәкле-гөлле» хатын-кыз исемнәребез барлыкка килгән. Аларның байтагы бүгенге көндә дә киң таралышка һәм актив кулланылышка ия.

Тотемистик ышанулар нигезендә төрле минерал, металл һәм алардан ясалган төрле корал, әйбер атамаларына нисбәтле рәвештә барлыкка килгән борынгы исемнәребез үзләренә бер мәгънәви төркем тәшкил итәләр.

Борынгы заманнарда төрки халыклар төрле минерал, тау токымнары (таш, чакма таш, чуерташ, агат, гранит һ. б.) һәм металларны (тимер, корыч, булат, бакыр, җиз һ. б.) илаһи көчкә ия дип санаганнар, аларны изгеләштергәннәр. Катылык һәм ныклык хас булган металл, минераллар, алардан ясалган тормыш-көнкүреш әйберләре һәм сугыш кораллары (мәсәлән, балта, ат дагасы, кылыч, сөңге, ук, урак, кусар, хәнҗәр һ. б.) усал көчләрне куркыта, аларны кешегә якын җибәрми дип ышанганнар. Шушы җирлектә бала авыруларга, усал көчләргә бирешмәсен, сәламәт булып үссен дигән теләктән чыгып, минерал һәм металл исемнәрен, алардан ясалган әйбер атамаларын балага исем итеп бирү йоласы барлыкка килгән.

Каты, нык минерал, таш һәм аның төрләре (чакматаш, чуерташ, такташ — гранит һ. б.) атамасын кеше исеме

итеп биру татарларда һәм башка төрки халыкларда киң таралышка ия булган. «Ташлы» исемнәребезгә Таш (шуннан Ташев фамилиясе), Ташбай, Ташбулат, Ташбакты, Асылташ, Ташбикә (соңгы икесе хатын-кыз исеме), Ташбәк, Ташкабан, Ташкай, Ташморза, Ташмөхәммәт, Таштимер, Тимерташ, Акташ, Караташ, Бикташ, Күкташ, Ташкал (таш миң — тәнендә таш кебек каты миңе булган ир балага кушылган; Себер татарларында Ташкалов фамилиясендә сакланган), Ташкол, Таңташ (татар-мишәрләрдә Таңташев, Танташев фамилияләрендә сакланган), Чуерташ, Чынташ һ. б. мисал итеп китерә алабыз.

Борынгы төрки телдә *такташ* сүзе гранит, кыя ташы төшенчәсен белдергән. Әлеге минерал атамасына нигезләнеп Такташ исеме ясалган. Бу исем татар-мишәрләрдә Такташ (мәсәлән, атаклы татар совет шагыйре Һади Такташ), Такташев фамилияләрендә сакланган.

Төрки халыкларда борында балага исем кушканда чакма ташы чагу гадәте булган. Берәү чакма чаккан, икенче берәү исем әйтеп торган. Кайсы исемне әйткәндә, чакмадан ут чыкса, балага шул исемне кушканнар. Чакматаш, Чакма, Чакмак, Чакмагыш кебек исемнәрне дә әйткәннәр. Болар бик борынгы төрки мәҗүси исемнәр булып, утка табынуны чагылдырсалар кирәк. Чакмак исеме үзбәкләрдә хәзер дә кулланылышта йөри. Бу исем мариларда да бар. Иске Чакмак, Олы Чакмак — Татарстанның Мөслим районындагы татар авыллары атамасы. Чакмагыш — Башкортстан АССРдагы бер район һәм район үзәге исеме. Фарсы телендә «чакматаш» төшенчәсен белдерә торган Мәрват исемен татарлар кулланылышка чагыштырмача соңрак алганнар.

Бала тимердәй нык-таза булсын, аның янына явыз көчләр, авырулар килмәсен дигән теләктән чыгып, аңа *тимер* сүзе кергән исемнәр биргәннәр. Балалары тормаган, тугач та үлеп барган гаиләләрдә дә яңа туган сабыйга «тимерле» исем кушканнар. Шул рәвешле татар телендә Тимер (диалекталь вариантлары Тимри, Тимрәй, Тимәш, Тимаш, Тимуш, Тимук, Тимәй), Тимеркыя, Тимербай, Байтимер, Тимербикә, Тимербулат, Булаттимер, Тимербәк, Таштимер, Тимеркәй, Чынтымир һ. б. кебек исемнәр барлыкка килгән. Тимер исеменең рус теленә алынган варианты — Тимур. Соңгы елларда татар гаиләләрендә дә Тимур исеме шактый еш кушыла башлады.

Бакыр металлы атамасын исем итеп кушу мотивлары да шуңа охшаш. Ул *бакыр* төсле кызгылт-җирән чәчле булып туган балаларга да кушылган: Бакыр, Бакырбай,

Бакыргали, Бакырбәк, Бакырбикә һ. б. Бакыр исеме башта Бакыр нәсел-ыру кушаматына, аннан Бакыров фамилиясенә әверелеп, безнең көннәргәчә килеп җиткән.

*Корыч, булат, чуен* кебек тимер эретмәләре атамаларын да борынгы заманнарда ата-бабаларыбыз, бала янына усал көчләр, авырулар килмәсен, ул сәламәт үссен дигән теләктән чыгып, ир балаларга исем итеп биргәннәр. Шушы җирлектә: Корыч, Корычбәк, Корычбай, Корычбулат, Корычтимер, Корычхан, Корычҗан; Булат, Булаттимер, Тимербулат, Булатхан, Булатҗан, Айбулат, Акбулат, Исәнбулат, Ирбулат, Илбулат, Ташбулат, Чынбулат, Нурбулат, Бирдебулат, Булатбирде, Котлыбулат, Булаткотлы; Чуен, Чуенбай, Чуенбәк исемнәре барлыкка килгән. Татар халкының алыплар турындагы бик борынгыдан килгән хикәятләрендә Тимер алып, Чуен алып кебек исемнәр белән очрашабыз.

*Балта* атамасына нигезләнгән исемнәр дә шактый: Балтай (бу исем удмуртларда да бар), Балтабай, Байбалта, Балтакол, Балтан, Балтакай, Бишбалта, Балтык һ. б. Әлеге исемнәрдән Казан татарларында һәм татар-мишәрләрдә Балтин, Балтаев, Балтанов, Балтакаев, Балтакулов, Балтуков фамилияләре, Башкортстан татарларында Балтабаев фамилиясе ясалган. Казан янындагы Бишбалта (соңрак Бишбалта бистәсе), Тау ягындагы Түбән Балтай, Урта Балтай, Югары Балтай авылларының (хәзерге Апас районында) Казан ханлыгы чорында да булулары мәгълүм.

Болгар-татарлар яңа туган ир баладан явыз көчләр үткен кылычтан курыккан шикелле курыксын, бала үскәч тә кылыч кебек үткен булсын дигән теләктән чыгып, Кылыч дип исем кушканнар. «Кылыч» компонентлы Кылычарслан, Кылычбай (Пермь татарларында Кылычбаев фамилиясендә сакланган), Байкылыч (татар-мишәрләрдә Байгылычев фамилиясендә сакланган) кебек мәҗүси исемнәр дә кулланылышта йөргән. Татар антропонимиконына, X гасырдан башлап, ислам идеологиясен чагылдыра торган исемнәр белән беррәттән, гарәпләрдән «кылыч» мәгънәсенә ия булган Саяф, Сәйф, Хисам, фарсылардан Шәмсир, Шәмсирә исемнәре алынган. Сәйф ~ Сәйфе, Хисам кебек исем компоненты булган Сәйфетдин (диалекталь вариантлары: Сәйфи, Сәйпи, Сәйфүк, Сәйфүш), Сәйфулла, Сәйфелислам, Сәйфелмөлек, Сәйфегази, Сәйфегали, Сәйфегани, Сәйфелгабит, Сәйфисаттар, Сәйфисолтан, Саяфетдин, Хисаметдин кебек кушма төзелешле кеше исемнәре таралган.

*Сеңге, ук, сагайдак>садак* (ук), *калкан, алпак* (тимер башлык), *хәнҗәр* кебек сугыш коралы атамаларын балага исем итеп кушу да ерак бабаларыбызның сүзнең магик көченә ышанулары нигезендә булган. Шушы җирлектә Ук, Укбай, Укатар (Угатаров фамилиясендә сакланган), Укбирде, Алпак (Казан татарларында Алпаков фамилиясендә сакланган. Бу фамилия казахларда да бар), Калкан (татар-мишәрләрдә Калканов фамилиясендә сакланган), Хәнҗәр (шуннан Хәнҗәров, Ханджаров) кебек кеше исемнәре барлыкка килгән.

Төрки-татар чыгышлы борынгы Сеңге ир-ат исеменә фарсылардан кергән Наиз — Наизә~Нәйзә, гарәпләрдән алынган Симбук исемнәре синонимдаш. Соңгысыннан татар-мишәрләрдә Симбуков фамилиясе ясалган.

Борынгы заманнарда болгар-татарларның тимердән ясалган *чукеч, урак, кусар* кебек хуҗалык кораллары атамаларын балага исем итеп кушу йола-гадәтенең асылында бала эштә ярдәмче булып үссен дигән теләк ята. Шушы йола белән бәйләнешле рәвештә Чукеш (шуннан Чукушев фамилиясе), Урак, Акурак, Уракбай, Ураккай (керәшен татарларында Ураккаев фамилиясе бар), Уракбикә, Кусар кебек борынгы мәҗүси исемнәребез барлыкка килгән. Кусар исеме, Зеленодольск районы Мулла иле авылында Кусар дигән нәсел-ыру кушаматына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган.

*Алтын* һәм *көмеш* кебек затлы металларның атамасы болгар-татарларда байтак кына борынгы ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре составында урын алган.

Кыйммәтле һәм затлы металл атамасы *алтын* сүзе катнашкан исем баланың ата-ана һәм гаилә өчен бик кадерле, кыйммәтле булуын белдергән, аның мул тормышта яшәргә тиешлегенә ишарә иткән. Шушы җирлектә Алтын (ир-ат һәм хатын-кыз исеме, шулай ук исем компоненты), Алтынбай, Алтынай, Алтынбуга, Алтынбулат, Алтынбәк, Алтынбикә, Алтынгали, Алтынгәрәй, Алтынчура, Алтынсылу, Алтынчәч кебек борынгы исемнәребез барлыкка килгән. Болгар кабер таш язмаларында Алтын Берте (хатын-кыз исеме), Алтын Бу исемнәре очрый. Болгарның соңгы ханы Габдулланың Алтынбәк һәм Галибәк исемле уллары булуы билгеле.

*Көмеш* татар халкында эчке сафлык, пакьлек, гөнаһсызлык символы булып санала. Составларында *көмеш* сүзе булган Көмеш, Көмешай, Көмешбай, Көмешбәк, Көмешбикә, Көмешбану, Көмешнур, Көмешсылу, Көмешчәч кебек кеше исемнәренең асылында баланың көмеш кебек

саф, пакь, гөнаһсыз һәм инсафлы булып үсүен теләү мотивы ята.

Урта гасырларда татар антропонимиконына гарәплэрдән Ибриз (саф алтын), Тыйлла (алтын), фарсылардан Зәр (алтын) кебек «алтынлы» исемнәр һәм соңгысының Зәрбану, Зәригөл, Зәрия, Зәрмөхәммәт, Зәринә, Зәррәгөл кебек ясалмалары алынган. Фарсылардан көмеш мәгънәсенә ия булган Нократ, Нокрә, гарәплэрдән Физә (Физза) исемнәре кабул ителгән. Соңгысының Физәнур, Нурфизә кебек төрдәшләре дә бар.

Күпчелек халыкларда *асылташлар* белән бәйләнешле төрле инану-ышанулар, ырымнар һәм гадәтләр яши. Мәсәлән, асылташлар мәркәзе булып саналган Һиндстанда бик күптәнге инану буенча, һәр айның үзенә туры килә торган асылташ бар. Январь — гранат (анар) ташы ае, ул даимилек, тотрыклылык билгесе. Февраль — хисләрнең ихласлыгын белдерүче аметист белән билгеләнә. Мартның юлдашы — аквамарин, ягъни батырлык. Апрель сафлык, нәфислек символы булган алмаз белән юлдаш. Майның асылташы — зөбәрҗәт. Ул кешеләргә мәхәббәт һәм уңыш китерергә тиеш. Июньнең ташлары: сәламәтлек китерүче александрит (ай ташы) һәм энҗе. Августта сардоникс (кара көрән юллы ахак) абруйлы: ул гаиләгә бәхет китерә дип уйлыйлар. Иң кыйммәтле ташлардан берсе сапфирны сентябрь белән бәйлиләр. Һиндлеләр бу ташны зирәклек билгесе итеп йөртәләр. Октябрьнең ташы икәү: опал белән турмалин. Җирле халык үзенең омтылышларын һәм өметләрен шушы асылташлар белән бәйли. Ноябрь ташы — топаз. Ул — тугрылык һәм өмет билгесе. Декабрь аеның юлдашы — фирәзә. Ул сәламәтлек һәм бәхетле мәхәббәт китерүче асылташ булып санала.

Болгар-татар теленә асылташ исемнәренең күбесе гарәп-фарсы яки Көнбатыш Европа телләреннән алынган, чөнки асылташлар болгар-татарларга читтән китерелгәннәр. «Болгар ярминкәсендә төрле товар белән сәүдә иткән Русь, Гарәбстан, Иран, Урта Азия, Әрмәнстан, Византия һәм хәтта Кытай купецлары күп очрашканнар... Болгарга күп төрле товарлар кертелгән. Чит илләрдән чимал (тимер, көмеш, алтын, аккургаш, ахак, фирәзә, гәрәбә һәм бүтән кыйммәтле ташлар) һәм башка төрле әйберләр кергән» (Татарстан АССР тарихы, Казан, 1959).

Татар антропонимиконында асылташ атамасына нигезләнгән ир-ат исемнәре күп түгел: Алмаз, Бату (Батый), Агат, Якут, Рубин.

Алмаз исеме үтә күренмәле, нурлы һәм иң каты ми-

нерал *алмаз* атамасыннан ясалган. Гарәпләр алмаз атамасын грекча «җимерелмәс, какшамас, иң нык» мәгънәсендәге *адамантос* сүзеннән алганнар. Гарәплэрдән бу сүз төрки телләргә кергән. Борынгы заманнарда алмазны кешегә көч һәм ныклык бирә, аны бәла-казадан, сихердән һәм авырулардан саклый, зирәк итә дип санаганнар. Алмазны сугыш коралларының сапларына куйганнар.

Алмаз ташның әлеге тылсымлы сыйфатларына ышану җирлегендә татарларда ир балага Алмаз, кыз балага Алмазия исемен бирү шактый еш очрый. Алмаз исеме һәм Алмазов фамилиясе русларда да бар.

Бату, Батый исемнәре монголча «асыл таш» дигән мәгънәне белдерәләр. Тарихта Алтын Урда ханы Бату хан (Батый хан) исеме билгеле. Бу исем Башкортстан татарларында Батыев фамилиясендә сакланган.

Агат — күп катлы һәм буй-буй сызыклы ярымасылташ (ахак, халцедон). Татарларда Агат вариантында ир-ат исеме булып йөрсә, Ахак вариантында хатын-кыз исеме буларак кулланыла.

Якут исеменең чыганагы гарәп теленә кайтып кала. Якут шулай ук кыйммәтле һәм каты минерал. Урта гасыр медицинасында ул күп төрле авырулардан дәвалый торган шифалы таш булып саналган. Шушы таш исемен йөртүче кешегә дә бернинди авыру да тими дип ышанганнар. Якутелҗиһан (дөньяның якуты) — хатын-кыз исеме.

Кызыл якут — *рубин* (латинча *рубер,* немецча *рубин* — кызыл) минералы атамасыннан 50 нче елларда татар исемнәре хәзинәсенә килеп кергән Рубин һәм Рубина исемнәре ясалган.

Бездә «асылташлы» исемнәренең күпчелеген хатын-кыз исемнәре тәшкил итә. Бу аңлашыла да, чөнки халкыбызның эстетик карашлары кыз баланың затлы, чибәр, керсез-саф булып үсүен һәм яшәвен таләп иткән.

Гарәби чыгышлы *җәүһәр* (асылташларның гомуми атамасы, күчерелмә мәгънәдә — «иң кыйммәтле, бик кадерле нәрсә») сүзе фарсы телендә *гәүһәр* әйтелешен алган һәм болгар-татар теленә шушы ике вариант та кабул ителгән. Бер үк эчтәлекле әлеге дублет сүзләргә нигезләнеп, Җәүһәр, Җәүһәрә, Җәүһәрия, Гөлҗәүһәр; Гәүһәр, Гәүһәрия, Гәүһәрә, Гәүһәрбар (гәүһәр чәчүче), Гәүһәрзат, Гәүһәршат, Гәүһәрташ кебек хатын-кыз исемнәребез барлыкка килгән.

Зөбәрҗәт исеменең асылында фарсыча *зөмәррәд* дип атала торган (русча *изумруд*) ачык яшел төстәге үтә

җуренмәле асылташ атамасы ята. Шуңа нигезләнеп Зөмрад, Зөмәррәт, Зөмәррә кебек хатын-кыз исемнәре дә ясалган. Зөбәрҗәт Шәрык халыкларында кешегә мәхәббәт һәм уңыш китерүче таш булып саналган. Аны туйда кияүгә һәм кәләшкә бүләк иткәннәр. Эсмеральда — испаннарда зөбәрҗәт ташы атамасыннан алынган исем.

Фирәзә һәм Фирүзә исемнәренең генезисы фарсы телендәге Фирүзә (сыек зәңгәр төстәге тонык минерал) асылташы атамасына барып тоташа. Фирәзә ташы (русча *бирюза*) көнчыгыш илләрендә сәламәтлек һәм бәхетле мәхәббәт символы булып санала.

Татар хатын-кыз исемнәре хәзинәсендә «энҗе-мәрҗәнле» исемнәрнең тулы бер синонимик оясы бар.

Көнчыгыш халыкларында *энҗе* борын-борыннан бәхет юлдашы һәм сәламәтлек китерүче затлы әйбер булып санала. Энҗе исеме һәм Энҗия, Энҗекәй, Энҗебикә, Энҗебану, Энҗегөл, Энҗекамал, Энҗенур, Энҗесылу, Энҗечәчәк, Энҗеҗамал, Энҗеҗиһан кебек хатын-кыз исемнәренең асылында кытай телендә кайбер диңгез моллюскларының кабырчыкларында үсә тогран затлы бөртекне белдерүче сүз ята. Бу сүз борынгы төрки телләрдә *йәнчү, йенчү, йәнҗү, инҗү, йенйү* (М. Кашгари), угыз һәм кыпчак телләрендә *җенҗү* формаларында кулланылган. Җенҗү формасыннан русча *җенчюг, җемчуг* барлыкка килгән. Энҗенең иске татар теленә фарсы теленнән кергән *мәрмәр, мәрвәрт* синонимнарыннан Мәрвәр, Мәрвәрә, Мәрвәрия, Мәрвәрит, Мәрвәрвафа исемнәре, ә гарәп теленнән алынган *дөррә*> *дөр* синонимыннан Дөрбиби, Дөрлемәрҗан, Дөрлеҗамал, Дөрниса, Дөррия һ. б. кебек хатын-кыз исемнәре ясалган. Дөрзаман, Дәрзаман (заманның энҗесе) — ир-ат исеме. Бу ояга гарәплектән кергән Фәридә (энҗе бөртеге), Фәридәбану, Фәридәбикә, Гөлфәридә исемнәре өстәлгән. 40 нчы елларда рус теле аша грекча «энҗе бөртеге» мәгънәсенә ия булган Маргарита исеме алынган (иркәләп-кечерәйтеп әйтү формасы Рита).

Болгар-татарларга гарәп теленнән кергән *мәрҗан* сүзе кызыл яки алсу төстәге кораллны белдерә һәм кеше исеме булып та йөри. XIX йөздә яшәгән атаклы татар галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818—1889) тәхәллусе — туган авылы Мәрҗан атамасына нигезләнеп ясалган. Мәрҗәнә, Мәрҗәния, Мәрҗанбану, Мәрҗәнбикә, Гөлмәрҗан, Мәрҗәнгөл — хатын-кыз исемнәре.

Сөт өстендәге вак пыяладан эшләнгән (ясалма) энҗенең татар-мишәр шивәсендәге атамасы *сәйләнгә* (фарсы телендә сәйлән — төрле төстәге вак пыяла энҗе) нигезлә-

неп, Сәйлән, Сәйләнә дигән хатын-кыз исемнәребез барлыкка килгән.

Иске татар телендә гарәпләрдә «хрусталь» төшенчәсен белдерә торган *бәллүр* сүзеннән Бәллүр дигән ир-ат исеме ясалган булса, хәзерге татар исемнәре хәзинәсенә 40 нчы елларда рус теленнән француз телендә «нурлы» мәгънәсенә ия булган, шомартылган һәм кырланган алмаз атамасы *бриллиантка* нигезләнеп ясалган Бриллиант дигән хатын-кыз исеме кулланылышка алынды.

Күреп үткәнебезчә, чал тарих дәвамында татар исемнәре хәзинәсенең, төнге күк гөмбәзендәге эреле-ваклы йолдызлар кебек җемелдәп («йолдызлы» исемнәребез турында сүз соңрак булыр), төрле төстәге якты нур чәчеп торучы «асылташлы, энҗе-мәрҗәнле» кеше исемнәре барлыкка килгән.

## Анимистик ышанулар белән бәйләнешле борынгы исемнәр

Борынгы исемнәребезнең бер өлеше ерак ыруглык җәмгыятендә яшәгән кабиләләрнең һәр әйбернең җаны бар дип карауларына, табигать көчләрен һәм күренешләрен аллалаштыруына нигезләнгән анимизмга (латинча *анима* — «җан») нисбәтле рәвештә барлыкка килгән. Бу төр ышануларның калдыклары безнең җанлы сөйләм телебездә хәзер дә чагыла әле. Менә шуңа күрә дә философия фәннәре докторы М. И. Абдрахманов «Диалектик материализм» (Казан, 1966) дигән хезмәтендә: «Көндәлек тормышта без еш кына, бер яктан, «аңым китте», «котым очты», «җаны чыкты» кебек, ә икенче яктан, «акыллы баш», «аңлы», «аңсыз» һ. б. шундый сүзләр кулланабыз. Гадәттә, без аларның эчтәлегендә бик борынгы кешеләрнең дөньяга карашлары чагылуы турында уйламыйбыз да. Ә бит бу сүзләрнең беренчеләрендә «җанның», «аңның» матдәдән, тәннән башка яшәве мөмкин дип санау, үзенә бер мөстәкыйль әйбер итеп карау чагыла, ә икенчеләрендә «аңның», «акылның» башка нәрсәгә бәйле булуын, ул нәрсәнең сыйфаты, үзлеге икәнен аңларга тырышу күренә»,— дип яза.

Бик борынгы заманнарда табигатьтәге тере һәм тере булмаган әйбернең җаны бар, җан мәңге яши, кеше үзе үлсә дә, аның җаны үлми дип ышанганнар. Кешегә «җан» төшенчәсен белдерә торган исем бирелсә, ул озын гомерле була дип уйлаганнар. Борынгы татар антропонимиконында да, анимистик ышанулар тәэсирендә, «җан» төшен-

чәсен белдерүче сүзләр чагылыш тапкан кеше исемнәре урын алган.

Чал тарих дәвамында татар телендә «җан» төшенчәсен белдерә торган сүзләрнең (*өн, өрәк～өзәк～үзәк, үз～ыз, кот, җан, рух, әрвах*) һәм аларга мөнәсәбәтле кеше исемнәренең синонимик оялары барлыкка килгән.

*Өн, өрәк, үз (ыз)* сүзләре, матриархат чоры мифологиясе белән бәйләнешле рәвештә, илаһи тереклек көче — җанны белдерү өчен барлыкка килгән булса, *кот* сүзе патриархат чоры мифологиясенә нисбәтле. Ислам дине кабул ителгәннән соң, татар теленә фарсы теленнән *җан*, әгарәп теленнән *рух* һәм *әрвах* сүзләре алынган.

К. Насыйри «Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр» дигән хезмәтендә: «Татарларның «җан» дигән сүзләре фарсыдан, шул ук вакытта өрәк дигән сүзнең «өрмәк»тән алынуы мөмкинлеген игътибарга алсак, өрәк турындагы әкиятләрдә татарларның кеше җаны турында, исламны кабул итүләренә кадәр булган кайбер төшенчәләре (җанны «өрәк» дип йөртүләре) хәзергәчә сакланып калуын әйтә алабыз»,— дип яза. «Өрәк»не *өрмәк, өрү* (ягъни сулышны, тынны чыгару) сүзләреннән килеп чыккан дип санау игътибарга лаек.

Акад. В. В. Радлов Казан татарларында *өрәк* сүзенең, «үлгән кеше җаны» мәгънәсеннән тыш, «кешенең акылы, характеры» мәгънәсендә дә йөрүен әйтә.

Этнографик һәм лингвистик әдәбиятта өрәк кайчандыр хатын-кызларның игелек, яхшылык тәңресе булган, матриархатны патриархат җиңгәннән соң исә усал тәңрегә, усал көчкә әверелгән, дип карала.

*Өр>Үз (ыз)>өрәк>үзәк* сүзләре кушма төзелешле кеше исемнәре составында урын алган. Бу исә кешенең озын гомерле, сәламәт булуын теләү белән бәйләнешле булса кирәк. Мисаллар китерик: 1. Өр>өрәк белән: Өрәктимер, Өркелди (*өр* «җан»+*келди* — «килде». Зеленодольск районы Татар Танае авылында Өркелдиев фамилиясендә сакланган), Өрәккилде, Өрчүн, Өркүн, Орахкуза, Оракпи чуваш телендә *орах — «өрәк»*) һ. б.; 2. *Өз>үз (ыз)>үзәк* белән: Өзтимер, Өзкер, Үзбилге, Үзбей, Үзбәк (ягъни җан+бәк — сословие титулы; бу исем төрки халыкларының күбесендә бар), Үзәккәй, Үзьяшәр. Әлеге исемнәр Татарстанның Актаныш районы Зөбәер авылының Закир Саттаров тарафыннан язылган нәсел шәҗәрәсендә бар. Бу авылга беренче башлап 1615 елда Бүләккәй бабай килеп утырган. Аның улы Үзәкәй (Үзәккәй), аның улы Үзьяшәр,

аның улы Шактай (Шактай 1670 елда кантонлык алган), аның уллары Тукмөхәммәт (Тукмәт) һәм Җортбагыш...), Үзәкбай Казан татарларында XVI гасыр азагы — XVII гасыр башында Өзембирде («Җанымбирде») исеме кулланылышта йөргән. Шуннан Өзембердеев фамилиясе ясалган. В. Г. Тизенгаузенның «Сборник материалов относящихся к истории Золотой Орды» (т. II М.-Л., 1941) дигән китабында Уз-Менгу һәм Ур-Менгу (Үзмәңге һәм Өрмәңге — *Г. С.*) исемнәренең бер үк исем булуы күрсәтелгән. Без биредә, *р*~*з* тартыклары тәңгәллеге җирлегендә, бер үк исемне ике төрле әйтү (фонетик параллелизм күренеше) белән очрашабыз. Бу хезмәттә Урек-Тимер (Өрәктимер) Тукта-Тимер улы дигән исем дә бар.

Борынгы телебездә *өн* сүзенең «җан» төшенчәсен белдергән мәгънәсе булган. Бу мәгънә кайбер фразеологик тәкъбирләрдә, туганлык терминнарында һәм ялгызлык исемнәрендә шактый сиземләнә эле.

*Өне китү, өнсез калу, өне бетү, өне югалу, өне качты, өн җыю, өнеңне алырмын, өнеңне чыгарма* һ. б. кебек фразеологизмнарда өн сүзенең аваз, тавыш һәм җан мәгънәсен белдерүе яхшы аңлашыла.

«Җан» төшенчәсен белдергән *өн* сүзе борынгы кеше исемнәре составында да урын алган.

Б. Аталай туплап бастырган борынгы төрек кеше исемнәре арасында Өнкүр һәм Өзкүр исемнәре бар. «Җан» төшенчәсен белдерүче *өн* һәм *өз* компонентлары һәм икенче компонентларының (күр) уртаклыгы аларның мәгънәдәш булуын күрсәтә.

Борынгы төрки телдә «җан» төшенчәсен белдергән *кот* сүзенә нигезләнеп тә татар телендә байтак кына башка сүзләр һәм тәгъбирләр барлыкка килгән. Күренекле этнограф Һ. В. Юсупов татарларның исламга кадәр җан турындагы карашлары патриархат чоры мифологиясе тудырган илаһи тереклек көче «кот»та гәүдәләнеш тапкан дип карый.

«Кот» кешене ташласа, аның тәненнән аерылса, кеше үлә, ә тәннән очкан «кот» үлемсез, мәңге яши дип ышанганнар борынгылар. Менә шуңа: *кот очу, кот чыгу, кот кою, кот калмау, кот алыну, котым китте* һ. б. ш. кебек фразеологик тәгъбирләрдә «кот»ның кешене ташлап китә, тәннән аерыла алуына ишарә ителә.

Татар телендә «кот» белән бәйләнешле сүзләрдән: *коткару* — җанны саклап калу, үтермәү (көнбатыш диалектта *котказу*); *коткы, коткы салу* — җан борчуы; *котыру* — җанның ярсуы; *котырткыч* — җан борчучы, орыштыручы,

әләкче; *котылу* — җанның (кешенең) бәла-казадан, кыенлыктан азат булуы; *котылгысыз* — җанның бәла-казадан, авырлыктан азат була алмавы, чарасызлыгы һ. б. күрсәтә алабыз.

Борынгы төрки телдә үк *кут* (кот) сүзе, «җан» төшенчәсе белән бергә, «бәхет», «шатлык» төшенчәләрен дә белдергән. Кот бәхет, шатлык, байлык итеп танылган, шулар белән тиңләштерелгән. Төрки каганатта Улуг кут — «Зур бәхет», «Зур шатлык» дигән титул булган. Безгә «Кутадгу белиг» («Бәхетле булу турындагы фән») исемле борынгы төрки китап мәгълүм. Татар телендә *кот* сүзенә *-лы* кушымчасы ялганып, *котлы* (бәхетле) дигән сыйфат ясалган. Котлы (бәхетле) сүзенең дә мәгънәсе «җанлы» төшенчәсенә якын. Котлының антоним пары котсызда ул аерата сиземләнә. *Котсыз* — җансыз, ямьсез, матур түгел (мәсәлән, *котсыз кеше; котсызга кот кунмас, умартасында корт тормас* — мәкаль). Котсыз сүзенең беренчел мәгънәсе үлгән кеше, җансыз кеше төшенчәсе белән бәйләнешле булса кирәк.

Котлы сүзенең «бәхетле» төшенчәсен белдергән мәгънәсе тагын да киңәю нәтиҗәсендә, яхшылык, бәхет теләү, тәбрикләү төшенчәсе барлыкка килгән. *Яңа ел котлы булсын! Яңа кием белән котлау, яңа квартира белән котлау, бәбәй котлау* һ. б.

Менә шушы «кот» сүзе катнашлыгында борынгы төрки телдә һәм иске татар телендә Кутлуг (хатын-кыз исеме), Кутлуг тимер (ирләр исеме), Котлыбәк, Котлыбикә, Котлыюл, Юлкотлы, Котлыкач, Котлыкай, Котлычура, Котлызаман, Котлыбай, Котлыяр, Котлы (Котлин, Кутлин фамилияләре шуннан), Котлыказан (баланың бәхетле һәм мул ризыклы булуын теләп кушылган), Котлыиш, Коттаймас (качмас, ягъни озак яшәр ир бала), Котлыҗан, Котык (Котыков, Кутуков фамилияләрендә сакланган; Кутуков фамилиясе русларда да бар), Котый (Кот + -ый — атау-эндәшү кушымчасы; Казан татарларында Котыев, Кутыев, Котаев, Кутаев, татар-мишәрләрдә Кутуев фамилиясе шушы исемнән), Котлыбулат, Котлыбарс, Котлыбикәч, Котлыниса һ. б. ш. кебек исемнәре ясалган.

Татар теленә фарсы теленнән кергән *җан* сүзе байтак кына кушма тамырлы кеше исемнәре составында беренче яки икенче компонент булып килә. Татар антропонимиясенең составында *җан* сүзе булган кушма тамырлы кеше исемнәрен төзелеше һәм чыгышы ягыннан түбәндәгечә классификацияләргә мөмкин:

а) Исемнең беренче компоненты «җан» сүзе+икенче компоненты төрки тамыр: Җанбай (диалекталь вариантлары Янбай, Ченбай, Енбай), Җанбикә, Җанбәк, Җанибәк, Җанчура, Җангол, Җаныш (варианты Яныш), Җанкилде, Җансөяр, Җантуган, Җанъегет, Җанбарс, Җансорыйм (чагыштыр: Янсурин — Апас районындагы керәшен татарлары авылы атамасы), Җанбакты, Җанбарс, Җантаймас, Җантирәк, Җантүрә, Җанураз, Җантуган, Җансылу (хатын-кыз исеме), Еникәй> Еники (*җани* + *-кәй* — иркәләү-кечерәйтү кушымчасы; шушы исемнән Еникиев, Еники фамилияләре ясалган), Җанбак һ. б.

б) Исемнең беренче компоненты төрки тамыр+икенче компоненты «җан» сүзе: Байҗан, Биҗан, Бикҗан, Батырҗан, Тимерҗан, Ирҗан, Акҗан, Төзҗан, Ишҗан, Татлыҗан, Корычҗан, Сылуҗан һ. б.

в) Исемнең беренче компоненты «җан» сүзе+икенче компоненты гарәп тамыры: Җангали (диалекталь вариантлары Йанали, Юнали, Енали), Җанмөхәммәт, Җанәхмәт, Җангәрәй, Җансуфый, Җангази, Җанкуәт, Җансолтан, Җансәет, Җаншәех, Җанәхмәт һ. б.

г) Исемнең беренче компоненты гарәп тамыры+икенче компоненты «җан» сүзе: Ахунҗан, Гарифҗан, Муллаҗан, Сәетҗан, Галимҗан, Рәхимҗан, Сәлимҗан, Таһирҗан, Закирҗан, Шакирҗан, Кәримҗан, Сабирҗан, Салихҗан, Фәезҗан, Хәбибҗан, Хәкимҗан, Нурҗан, Әмирҗан һ. б.

д) Исемнең беренче компоненты «җан» сүзе+икенче компоненты фарсы тамыры: Җанхуҗа, Җанморза, Җанмирза, Җанпакь, Җандус, Җансубай ~ Янсубай (>Янсыбы — Татарстанның Кукмара районындагы болгар-татар авылы атамасы) һ. б.

е) Исемнең беренче компоненты фарсы тамыры+икенче компоненты «җан» сүзе: Морзаҗан, Мирзаҗан, Мирҗан, Дусҗан, Шаһиҗан, Хуҗаҗан һ. б.

Татарларда гарәп теленнән алынган *рух* сүзе белән бәйләнешле берничә генә кеше исеме кулланылышта йөри: Рухулла, Гөлрух, Рухан. «Үлгән кеше җаны» төшенчәсен белдерә торган *әрвах* сүзе исә кеше исемнәре составында бөтенләй урын алмый. Бу сүз *ач әрвах ~ әч әрвах* дигән тотрыклы сүзтезмәдә генә сакланган.

Телебездә «җан» төшенчәсен белдергән сүзләрнең, бер-

бер артлы яки параллель рәвештә кулланылышта йөрүе һәм, кулланылыштан төшеп, бу төшенчәне белдерүче башка сүз белән алмаштырылуы нәтиҗәсендә, татар антропонимиясе тарихында синонимик исемнәр барлыкка килгән: Өрекби ~ Котби; Узбай ~ Котбай ~ Җанбай; Өнбәк ~ Үзбәк ~ Өрәкбәк ~ Котбәк ~ Җанибәк; Үзтимер ~ Өрәктимер ~ Коттимер ~ Җантимер; Өрәккилде ~ Коткилде ~ Җанкилде; Коттаймас ~ Җантаймас һ. б.

Күреп киткәнебезчә, феодализм чорында ислам динен кабул иткәннән соң, телебездә мәҗүси ышанулар һәм йолалар белән бәйле рәвештә, «җан» төшенчәсен белдерә торган төрки чыгышлы сүзләрнең кулланылышы пассивлаша барган, бу төшенчәне белдерү өчен фарсы теленнән алынган *җан* сүзе актив кулланыла башлаган. Составларында шушы сүз булган күп кенә кушма төзелешле кеше исемнәре барлыкка килгән.

## Күк-тәңре, күк җисемнәре культы, җир-су культы белән бәйләнешле борынгы исемнәр

Борынгы заманнарда төрки халыклар, шул исәптән болгар-татарлар, күктәге тәңрегә табынганнар. Тәңрене дөньяны тудыручы илаһи көч, иң зур, баш алла дип санаганнар. Тәңре (тәңгере) күк алласы булганга, күк тәңгересе дип аталган. Ул күк җисемнәрен (кояшны, айны, йолдызларны) һәм җирне яраткан. Шаманизм калдыклары озак сакланган монголларда да *тэнгэри* иң биек күктә яши торган рух, иң югары дәрәҗәле илаһи көч булып санала.

Төрки халыклар шулай ук кояшны, айны, йолдызларны, җир-суны, табигать күренешләрен: таңны, томанны, болытны, карны, буранны, яңгырны, күк күкрәвен, яшенне, салават күперен, җил-давылны, зилзиләне һәм башкаларны да илаһи көчләр дип санаганнар, аларга табынганнар, багышлап корбан чалганнар, моның төрле йолалары һәм ырымнары булган.

Тәңре теонимының (алла исеменең) килеп чыгышын якут телчесе проф. Н. К. Антонов *таң ире* сүзләренә бәйләп аңлата. *Таңирне* (тәңрене) таң аттыручы, кояш чыгаручы ягъни көн тудыручы, тереклек бирүче баш алла итеп саный. Хуннар аны *тангри хан* дип атап йөрткәннәр. Борынгы болгар (Дунай болгарлары.— *Г. С.*) язма ядкарьләрендә *тангра* формасында теркәлгән. Тәңре теонимы Идел-Кама болгарларында XII—XIII йөзләргә караган «Кисекбаш» китабында инде мөселман алласын белдерә.

Хәзерге татар телендә дә *тәңре* алла сүзенең абсолют синонимы булып йөри. Мәсәлән, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең III томында: *тәңре хакы өчен* — алла хакы өчен; *тәңре ярдәм итсен* — алла ярдәм итсен; *тәңре үзе генә белсен* — алла белсен һ. б. ш. тәңгәл фразеологизмнар теркәлгән.

Тәңре теонимының асылында «иксез-чиксез», «гаять зур, олы, бөек» мәгънәсендәге *тәңгер* сүзе ята дигән караш та бар. Борынгы төрки телдә, *р~з* авазлары тәңгәллеге (ротацизм күренеше) җирлегендә *тәңгер* теонимыннан *тәңгез>тиңгез>диңгез* сүзе дә барлыкка килгән. *Диңгез* сүзенә нигезләнеп Диңгез (грузиннарда — Тенгиз), Диңгезбай, Диңгезбикә кебек борынгы кеше исемнәребез ясалган.

Тәңребирде, Тәңребиргән, Тәңрегол һ. б. кебек борынгы кеше исемнәреннән Казан татарларында Тәңребирдиев, Тәңребирдин, Тәңребиргәнов, Тәңрегулов фамилияләре ясалган. Казан ханлыгы чорында Тау ягында Сулча елгасы буенда Тәңребирде дигән татар авылы булганлыгын да әйтеп китик.

Татар теленә, борынгы *тәңре* сүзе кулланылышта йөргән хәлдә, шул ук мәгънәдәге гарәби чыгышлы *алла, мәүла, рахман, рәхим, хак, кәрим* һәм фарсы чыгышлы *ходай, яздан* сүзләренең кулланылышка алынуы һәм бер үк исем компонентларына ялганып кушма төзелешле кеше исемнәре ясаулары нәтиҗәсендә, урта гасырларда синонимдаш ир-ат исемнәре бик күп барлыкка килгән: Тәңрегол ~ Аллагол ~ Рахмангол ~ Рәхимгол ~ Мәүлагол ~ Ходайгол; Тәңребирде ~ Аллабирде ~ Кәримбирде ~ Мәүлабирде ~ Ходайбирде ~ Хакбирде; Тәңребиргән ~ Аллабиргән ~ Хакбиргән ~ Ходайбиргән ~ Кадыйрбиргән; Нурлыхак ~ Нурлыяздан; Аллаһияр ~ Мәүлаяр ~ Ходаяр һ. б.

Төрки телләрдә *күк* сүзе — күп мәгънәле сүз. Менә шуңа составларында *күк* лексемасы булган төрки-татар кеше исемнәренең мәгънәсен төгәл билгеләү шактый кыен.

Баш мәҗүси алла тәңре яши торган *күк* термины күк гөмбәзенең төсенә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Бу терминның асылында *күк* («голубой») сыйфат сүзе ята. Күк — спектрның төп төсләреннән берсе.

Борынгы төрки телдә *күк* сүзе, шушы ике төп мәгънәсеннән башка, зәңгәр, соры, бүз, яшел (төсләр); тамыр, төп, нигез, терәк; нәсел-чыгыш; ирекле, азат; изге, яхшы, асыл, затлы мәгънәләрен дә белдергән.

Татар телендә ат төсенә карата *күк* сүзенең мәгънәсе русча «сивый»га туры килә. *Күк ат* — сивка, серая лошадь.

*кук алаша* — сивый мерин, *кук бия* — сивая кобыла, *тимер-кук* — темно-сивый һ. б.

Татар халкы:

> Минем сөеп җиккән атым
> Җирән белән тимер күк...,

— дип җырлый.

Әйткәнебезчә, иске татар телендә *кук* сүзе «яшел» дигән мәгънәгә дә ия булган. Мәсәлән, *кукташ* — «яшел таш», *икмәк күгәрү* — икмәкнең яшелләнеп чыгуы, *куксу* — яшелләнү, *куксел* ~ күкшел — зәңгәрсу-яшькелт төс һ. б. Казах телендә *күкшә* сүзе әле дә «яшел» дигәнне белдерә. Мәсәлән, Күкчәтау шәһәре исеме «Яшелтау» дигәнне аңлата. Бу шәһәр яшел тау өстенә урнашкан. Татарстанның Сарман районындагы Күктау авылының исеме дә «Яшелтау» дигән төшенчә белдерә. Үзбәкчә *кук чәй* «яшел чәй» дигәнгә туры килә.

Себер татарлары телендә *кук* сүзе «язын яңа тишелеп чыккан яшел үлән» дигән төшенчә белдерә. Күкләү — терлекләрнең яшь үләндә йөрүе, утлавы. Ф. С. Фасеев борынгы «голубые тюрки» атамасының «күк канлы, асылзат, аксөяк төркиләр» мәгънәсен белдермичә, «яшел үлән арасында көтү көтеп, күчеп йөреп көн күрүче төркиләр» мәгънәсенә ия булуы турында сөйли. Борынгы татар фамилиясе Кокляновның нигезендә *коклан* — «тамыр җибәргән, төпләнгән, яшелләнгән» сүзе ята, дип карый ул. Шулай ук борынгыдан килә торган Кукляшев фамилиясенең (мәсәлән, Салихҗан Кукляшев — XIX йөздә яшәгән татар мәгърифәтчесе) асылында «тамырлан, яшәр; яшел, яшь бул», ягъни «бер дә картайма» дигән мәгънәгә ия булган борынгы төрки-татар Күкләш исеме ята.

Күгеш дигән борынгы төрки-татар исеме дә күп мәгънәле. Аның килеп чыгышын: 1) күк иш>күгеш, күк ише, изге җан; 2) ирекле, хөр иш (ярдәмчел бала); 3) яшел иш, яшь иш (бала); 4) *күгү* (аккош)+*иш* (бала) рәвешле карый алабыз. Беренче этимологиясенең изге күккә нисбәтле булуы яхшы аңлашыла. Күгеш исеме болгар-татарлардан мариларга да кергән. Бу исемнән ясалган Кугушев, Кугушин фамилияләре татарларда һәм русларда очрый. Татарстанның Зеленодольск районындагы Күгеш дигән татар авылының Казан ханлыгы чорында булуы документаль мәгълүм.

Күгәй исемендә 1) «күк кебек бөек, югары бул, мәртәбәле бул» яки 2) «яшел бул, яшь бул» мәгънәсе төсмерләнә. Шушы исемнән ясалган Кугаев фамилиясе, сирәк булса да, татарлар һәм руслар арасында очрый. Күгәй —

Татарстанның Зеленодольск районындагы татар авылы атамасы.

Күкбүре исеменең асылында «күк бүре», ягъни «изге бүре» төшенчәсе яки тотемы ята.

Казан ханлыгы чорында Җөри юлында Күкчабак дигән татар авылы булган. Бу атама «изге чабак» мәгънәсенә ия булган төрки-татар Күкчабак исеменнән килеп чыккан.

Идел болгарларында Күкәҗә (*күк* «изге, яхшы, асыл»+*әҗә* «өлкән абый, ир туган») исеме дә кулланылышта йөргән.

Болгар-татарларның Күгәнәк исеме борынгы төрки *күк* сүзе һәм «эт» мәгънәсендәге *әнәк* сүзе кушылып ясалган. «Күк эт», ягъни «изге эт» мәгънәсенә ия. Бу исемдә ир баланы *әнәк* дип тотемлаштыру һәм *күк* белән бәйләп изгеләштерү сиземләнә. Күгәнәк исеме, Башкортстанның Стәрлебаш районындагы татар, Аургазы районындагы рус авыллары атамасына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган.

Күккүз исеме — болгар-татарларда күк төсенә карап бирелгән борынгы йола исем. Казан татарларында Күккүзов (Куккузов) фамилиясендә сакланган. Татарстанның Апас районында Зур Күккүз һәм Кече Күккүз дигән татар авыллары бар. Буа районындагы Күкшем һәм Кукмара районындагы Күкшел авыллары атамасының асылында да борынгы болгар-татар Күкшем һәм Күкшел (күкшем, күкшел, күксем, күксел) исемнәре ята. Болар — күксел зәңгәр күзле булып туган ир балага кушылган йола исемнәр.

«Изге, исән-аман бала» һәм Күкморза (изге, яхшы морза, бала) исемнәренең илаһи көч, изге рух, тәңре белән бәйле булуы яхшы сиземләнә.

Борынгы заманнарда илаһи, изге дип саналган кояш, ай, йолдыз һәм башка күк җисемнәрен белдерүче сүзләрне кертеп тә балага исем кушканнар.

Борынгы төрки телдә кояш астрономик термины *күн* формасында йөргән. «Борынгы төрки сүзлек»тә күн I сүзенең: 1) *кояш*; 2) *көн*; 3) *көн саен* мәгънәләрен белдерүе күрсәтелгән. *Күн*>*күнәштән кояш* әйтелеше барлыкка килгән: *көнбатыш* (кояшбатыш), *көнчыгыш* (кояшчыгыш), *көнбагыш* (кояшбагыш) һ. б. кебек кушма сүзләребездә кояш сүзенең борынгы формасы *көн (күн)* белән очрашабыз. Себер татарлары кояшны хәзер дә *көн*, казахлар, шорлар, хакаслар, кырым татарлары, кыргызлар *күн*, тувалар *хүн* диләр.

Илаһи көчкә ия булган изге күк җисемен белдергән *кун, кунәш кояш* астрономик терминына нигезләнеп, төрки халыкларда бик борынгы заманнарда ук кеше исемнәре барлыкка килгән. «Борынгы төрки сүзлек»тә Күннең кеше исеме, һәм титул булуы да күрсәтелгән.

Татарстанның Питрәч районындагы Күн авылы атамасының асылында Күн дигән борынгы кеше исеме ятуы ихтимал. Күн, Күнәш, Күнәшкол, Күнтугды, Күнтугмыш, Күндәй ~ Күнтәй (Кояштай), Көнбикә, Көнсылу, Көнтимер, Көнчура, Көнбак, Көнбай, Көнбәк һ. б. кебек кеше исемнәре борынгы төрки халыкларда, шул исәптән болгар-татарларда, кулланылышта шактый актив йөргәннәр.

Безнең эраның III—IV гасырларыннан башлап, төрки халыклар яши торган Урта Идел — Урал төбәгендә әлеге борынгы төрки исемнәрнең кайберләренең авыл атамаларына әверелүен җирле топонимнар да раслый. Башкортстанның Балтач районында Күнтугмыш исемле башкорт авылы бар.

Телебездә чагыштырмача соңрак *кояш* (күнәш) сүзе барлыкка килгәч, иске татар телендә *көн* һәм *кояш* сүзләре параллель кулланыла башлаган. Тора-бара *көн* сүзе тәүлекнең якты (кояшлы) вакытын белдерү өчен береккән. *Көн* һәм *кояш* сүзләренең үзара синонимлыгы нәтиҗәсендә, тарихи антропонимиконыбызда Көн ~ Кояш; Көнбикә ~ Кояшбикә; Көнсылу ~ Кояшсылу кебек синонимик исемнәр барлыкка килгән. Кояш, Кояшбикә, Кояшсылу, Кояшҗиһан (иске татар телендә Җиһанкояш исеме дә булган) исемнәре бүгенге көндә дә татар антропонимиконының шактый актив кулланыла торган хатын-кыз исемнәре булып торалар. Телебезгә гарәп теленнән алынган Шәмс («Кояш» — ир-ат һәм хатын-кыз исеме; актив исем компоненты), фарсы теленнән кергән Афтаб («Кояш» — ир-ат һәм хатын-кыз исеме) исемнәре төрки чыгышлы Көн (ир-ат исеме) һәм Кояш (хатын-кыз исеме) исемнәре белән синонимдаш. Көнбикә исеменә Кояшбикә, Шәмсебикә исемнәре, Кояшҗиһан исеменә Шәмсеҗиһан исеме мәгънәдәш.

Мәҗүсилек чорында төрки халыклар айга да табынганнар. Болгар-татарларда шулай ук изге, илаһи дип санала торган күк җисемен белдерүче *ай* астрономик термины, туры мәгънәсеннән тыш, сылу, матур, нәфис, асыл; изге, пакь, саф; ак, якты, нурлы; акыллы, зирәк; кыйммәтле, мул; бәхетле; уңыш һ. б. күчерелмә мәгънәләргә ия.

Борынгы төрки телләрдә үк ир-ат һәм хатын-кыз исемнәрен ясауда *ай* антрополексемасы актив кулланылган. Борынгы төрки телдә Ай, Ай каган, Ай толды һ. б. исем-

нәр булган. XIII гасырга караган иске кыпчак теле ядкарендә: Айбе, Айбек, Айбарс, Айбала, Айдогды, Айдогмыш, Айдегин, Айдемир һ. б. кебек ир-ат; Айсаву, Айсили, Айкине һ. б. кебек хатын-кыз исемнәре теркәлгән.

Болгар-татарларда, бик борынгыдан килә торган гадәт-йола буенча, кичен ай калыкканда яки ай тулысында туган балага *ай* сүзе кергән исем кушылган. Идел болгарларында Айбикә, Айбикәч һәм Айбулат, Айдаш кебек исемнәр кулланылышта йөргән.

Татар антропонимиконында *ай* компонентлы кушма төзелешле ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре шактый күп һәм аларның байтагы хәзер дә кулланыла: Айбарс, Айбаш, Айбәк, Айбикә, Айбикәч, Айбуга, Айбала, Айбүләк, Айгөл, Айтирәк, Аййолдыз, Айкош, Айсылу, Айташ, Айтимер, Айтуган, Айкөн, Айчуак, Айчура, Айчәчәк, Айкап (*ай* сүзенә борынгы төрки телдә «кан кардәш» мәгънәсен белдергән *кап* сүзе кулланылып ясалган исем, ул Татарстанның Балтач районы Балтач авылында яшәүче Гафур Сәгъдетдиновлар нәселе шәҗәрәсендә сакланган: Габдулла⟶Фәйзулла⟶Айкап ⟶ Җангилде⟶Исәнгилде⟶Салих ⟶ Сәгъдетдин⟶Габдрахман⟶Гафур) һ. б.

Татар антропонимиясенә гарәп теленнән «ай» мәгънәсенә ия булган Камәр һәм Бәдер (Бәдри), фарсы теленнән Маһи исемнәре һәм исем компонентлары алынган һәм нәтиҗәдә кушма төзелешле бик күп синоним исемнәр ясалган. Аларның зур күпчелеге хатын-кыз исемнәре: Маһия ~ Камәрия ~ Бәдрия; Айбикә ~ Маһибикә ~ Камәрбикә; Айбәнат ~ Шәмсебәнат ~ Маһибәнат; Айгөл ~ Маһигөл ~ Камәргөл; Айназ ~ Маһиназ ~ Камәрназ; Айнур ~ Бәдринур ~ Маһинур ~ Камәрнур; Айҗамал ~ Бәдриҗамал ~ Маһиҗамал; Айкамал ~ Бәдрикамал ~ Маһикамал; Айниса ~ Маһиниса ~ Бәдерниса; Айсылу ~ Бәдерсылу ~ Камәрсылу ~ Маһисылу; Айбәдәр ~ Маһибәдәр ~ Шәмсебәдәр; Айкамәр ~ Шәмсекамәр ~ Маһикамәр ~ Бәдеркамәр; Аймаһи ~ Шәмсемаһи ~ Бәдәрмаһи һ. б. Камәрҗан ~ Маһиҗан — синонимдаш ир-ат исемнәре.

Антропонимиконыбызда «йолдызлы» исемнәр дә байтак.

*Йолдыз* яктылык, матурлык, гүзәллек, сафлык, омтылыш, бәхетле өлеш, язмыш символы да булып исәпләнгән.

Төрки халыклар, бик борынгы заманнардан алып балаларга «йолдызлы» исемнәр куша башлаганнар. Хива ханы Әбелгази Баһадур хан язган «Шәҗәрәи төрекмән» әсәрендә борынгы төрки исемнәр арасында Йолдызхан исеме дә бар. Болгар-татарларда да «йолдызлы» исемнәр кул-

ланылышта йөргән һәм хәзер дә бездә актив кулланыла торган кеше исемнәре төркемен тәшкил итәләр.

Татарларда Йолдыз һәм Чулпан исемнәре ир балаларга да, кыз балаларга да кушыла. Хатын-кызларга кушыла торган Йолдыз исеменең, фарсылардан шул ук мәгънәдәге Ситарә һәм Әсфирә, рус теле аша латин теленнән Стелла исемнәрен кулланылышка алу нәтиҗәсендә, синонимик оясы барлыкка килгән. Бездә иран-фарсы чыгышлы Эсфир (йолдыз) исеме дә очрый. Аййолдыз — татарларда хатын-кыз, ә төрекләрдә ир-ат исеме. Акйолдыз исә бездә хатын-кыз исеме булып йөри.

Татарлар Чулпан йолдыз дип Таң йолдызын, ягъни Венера планетасын атыйлар. Бу планетаның борынгы төрки телдәге исеме — Ярук (якты). Себер татарларында Ярук, Ярукә исемнәре әле дә кулланылышта. Таң алдыннан яисә кояш батканда күренә торган Чулпан йолдызы атамасының килеп чыгышын *чубан～чабан* «көтүче, куй көтүчесе» сүзе белән бәйләп карыйлар. Белгәнебезчә, искедән калган гадәт буенча, авыл җирендә таң атып килгәндә көтү куалар, ә кичке Чулпан калыкканда көтү каршылыйлар. Икенче төрле Чулпанны «Көтүче йолдызы» дип тә атыйлар.

Чулпан исеме XVI—XVII йөзләрдә Казан татарларында ир-ат исеме булып киң кулланылган. Татарстанның Балтач, Әлмәт, Минзәлә, Чистай районнарында Чулпан дигән татар, Арча районында рус-татар, Октябрь районында рус авыллары бар. Югары Ослан районындагы Чулпаниха авылына, XIII гасыр уртасында Болгар җимерелгәннән соң, Арыслан дигән кешенең Чулпан исемле улы (Чулпан баба) шәһри Болгардан килеп нигез салган (К. Насыйри). Хәзер Чулпаниха — рус авылы.

Хатын-кызларга кушыла торган Чулпан исеменең бездә Чулпания дигән төрдәше бар. Гарәпләрдән шул ук мәгънәдәге Зөһрә, рус теленнән латин чыгышлы Венера исемнәрен кулланылышка алу һәм яңа Таңйолдыз, Таңчулпан исемнәре ясалу нәтиҗәсендә, хәзерге татар антропонимиконында бу исемнең синонимик чылбыры Чулпан～Зөһрә～Венера～Таңйолдыз～Таңчулпан барлыкка килгән.

Котып йолдызының татарча атамасы Тимерказык та бездә ир-ат исеме булып йөргән. Тимерказык йолдызы, хәрәкәтсез бер урында торганга, борынгы заманнарда юлда дөрес юнәлеш тоту, ориентир алу өчен хезмәт иткән һәм аның шушы даимилеген, тотрыклы булуын күздә тотып, татарлар гаиләдә туган ир балалар бер-бер артлы

үлеп барсалар, яңа туган сабый үлмәсен, яшәүчән булсын дигән теләктән чыгып, аңа Тимерказык исемен кушканнар.

Иске татар телендә Тимерказык йолдызы янындагы Акбүзат һәм Күкбүзат йолдызлары атамасы да ир-ат исеме булып кулланылган. Болардан Казан татарларындагы Акбүзатов һәм Күкбүзатов фамилияләре ясалган.

Алынма астрономик терминнарга нигезләнеп ясалган ир-ат исемнәре дә бар. Гарәпләрдән Мөштәри (Юпитер планетасы) Зөхәл (Сатурн планетасы), Сүрия (Сириус йолдызы), фарсы теленнән Бәһрам (Марс планетасы) (ясалмалары Бәһрамбәк, Бәһрамша, Бәһрамҗан — ир-ат исемнәре; Бәһрамхәят, Бәһрамия — хатын-кыз исемнәре), рус теленнән грек чыгышлы Уран (грекча «күк» мәгънәсен белдерә; кояш системасындагы җиденче планета атамасы) һәм латин чыгышлы Марс исемнәре кулланылышка алынган.

Җир-су культына нисбәтле борынгы төрки-татар кеше исемнәре күп түгел. Без төзегән 25 меңнән артык берәмлектән гыйбарәт төрки-татар-болгар исемнәре картотекасы составында җир сүзе булган кеше исеме юк. Безгә таныш булган тарихи чыганакларда да андый исем очрамады.

Җирнең калку, биек географик объектын белдерүче *тау* оронимик терминына нигезләнеп Тау, Таулы, Таулыбай, Таулыбәк, Таубикә, Тауҗамал һ. б. кебек борынгы исемнәребез барлыкка килгән. «Тау кебек биек, зур дәрәҗәле, атаклы, матур» мәгънәсенә ия булган Тауҗамал дигән ирләр исеменә (бу исем хатын-кыз исеме булып та йөргән) нигезләнеп, Удмурт АССРның Кече Пурга районында татарлар яши торган Тауҗамал авылы атамасы барлыкка килгән.

Болгар-татарларда *су* лексемасына һәм *диңгез* гидрографик терминына нигезләнеп: Сусылу, Диңгезбикә (хатын-кыз исемнәре), Диңгез, Диңгезбәк, Диңгезбай (ир-ат исемнәре) антропонимнары ясалган.

Борынгы төрки телдә *талуй* сүзе «диңгез» мәгънәсендә кулланылышта йөргән. Идел-Кама болгарларындагы Талут исеме талуй сүзенең *-т* күплек кушымчасы алып ясалган (Талут — «диңгезләр») формасы булса кирәк. 922 елда Идел-Кама Булгариясенә Багдад хәлифеннән илче булып килгән Әхмәд Ибне Фадланның үзеннән Талут исемле бер болгар кешесе ислам динен кабул итә һәм үзен аның үз исеме белән атавын сорый. Әхмәт Ибне Фадлан аны Габделхак дип атый һәм мәгънәсе белән үз исеме Әхмәдкә

(иң данлы, иң мактаулы) якын булган Мөхәммәт (мактаулы, данлыклы) исемен дә бирә. Талут исеменең тәрдәше — Талуй. (Казан татарларында аннан ясалган Талуев фамилиясе сирәк булса да очрый.)

Татарларга гарәпләрдән кергән Камус исеме «океан» мәгънәсенә ия. Бу исемнән Камусов һәм Камусин фамилияләре ясалган. Гарәпләр телне, аның сүз байлыгын, лексик хәзинәсен океан белән тиңләп, камус дип тә атыйлар. Татарларда кеше исемнәре хәзинәсе тел камусының зур бер диңгезен тәшкил итә дисәк, һич тә арттыру булмас.

## Ата-баба культы һәм туганлык терминнарының борынгы кеше исемнәрендә чагылышы

Болгар-татарларда ата-баба культы киң таралган була. Этнографлар ата-баба культын башлыча мәет күмү һәм үлеләрне искә алу йолаларына таянып анализлыйлар. Этнограф К. И. Козлова «Этнография народов Поволжья» (М., 1964) дигән хезмәтендә ата-баба культына хас ике моментны билгели: беренчесе — үлгән ата-бабадан курку һәм алар әйләнеп кайтмасын өчен һәртөрле йолалар үтәү; икенчесе — ата-бабаны зурлау, искә алу, хөрмәт итү.

Ата-баба культы мәҗүсилек чоры һәм ышанулары белән бәйле. Аның гаять зур географик тирәлеккә таралган булуы да билгеле. Мәсәлән, Кытайда хәзер дә яшь баланы кечкенәдән үк «атаң яки бабаң — синең аллаң» дигән рухта тәрбиялиләр. Көнбатышка таба бу төшенчәләр төрки халыкларда ислам, ә башкаларда христиан дине һ. б. йогынтысында үзгәргән. Башкачарак формада кытай төшенчәләренең чагылышы Себер татарларында һәм кайбер башка төрки халыкларда урын ала.

Вакытлар үтү белән ата-баба культына нисбәтле исемнәр мәгънә төсмерләрен киңәйтәләр. Баштагы чорда ата-баба исемен зурлауга кайтып калса, соңрак ул исем кабилә яки ыруг атамасына (этнонимга) әверелеп сакланырга мөмкин. Бу очракта борынгы бер шәхес, аксакал һәм аның исеме кабилә культына яки нәсел-ыруг культына (этнонимга) әйләнә. Ләкин ата-баба культында беренчел мәгънә югалмый. Исем бирү мотивы ата-бабаның күңелен күрү һәм аны олылау кебек төшенчәләрне үз эченә ала.

Ата-баба культына нисбәтле исемнәрнең берничә үзенчәлеге бар.

Балага исем ата-бабасыныкына авазлаш итеп бирелә. Татарларда гаилә яки бер нәсел эчендә ир балаларга этисе яки бабасы, бабасының этисе һ. б. исеменә рифмадаш исем бирү гадәте шактый киң таралган: Әхмәтша — Җиһанша — Гаделша — Мөбәракша — Дәүләтша; Шиһабетдин — Садретдин — Хәйретдин — Гарәфетдин; Габдулла — Сәмигулла — Хәбибулла — Рәхимулла — Закирулла — Зәкиулла; Гарифҗан — Сәлимҗан — Сәлихҗан — Галиҗан — Рәхимҗан — Нигъмәтҗан; Морат — Тәлгать — Рифгать — Сибгать — Самат — Азат һ. б.

Бер үк компонент кергән исем бирү дә гаилә яки нәсел эчендә авазлаш исемнәр чылбырын барлыкка китергән: Ишбакты — Ишбирде — Ишбулат — Ишбулды — Ишморат; Миңлебай — Миңлеяр — Миңлегали — Миңлеәхмәт— Миңлеәхәт; Байназар — Байбулат — Байморза — Байгали — Байхуҗа — Байчура; Габдрахман — Габдрәхим — Габдерәззак — Габдерәшит — Габдерәүф һ. б. Исемнәр чылбырының бер үк аваздан башлануын (мәсәлән, Ризван — Равил — Рамил — Ренат; Зариф — Закир — Заһир — Зәки — Зәкәрия; Фәез — Фаяз — Фаил — Фәһим — Фәрит һ. б.) ата-баба яки нәсел-ыру культы традициясенең бүгенге көндә дә үзенчәлекле чагылышы дип карый алабыз. Бер гаилә яки нәсел эчендә рифмадаш исемнәр бирү традициясе башка төрки халыкларда да, мәсәлән, алтайлыларда, башкортларда киң кулланылышка ия. Л. И. Ройзензон һәм А. Бобоходжаев үзбәкләрдәге мондый исемнәрне антропонимик серияләр дип атыйлар.

Туганлык терминнарын яңа туган балага исем итеп бирү яки аларның кушма төзелешле исем составында урын алуы да гадәти күренеш. Төрки-татар чыгышлы *ата* һәм *баба* туганлык терминнарына һәм туганлыкны белдерүче башка терминнарга нигезләнеп ясалган кеше исемнәре ата-баба культы тәэсирендә барлыкка килгәннәр исәбенә керә: Атабай (Татарстанның Лаеш һәм Кама Тамагы районнарындагы Атабай дигән татар авыллары атамасында сакланган. Лаеш районындагы Атабай авылының Казан ханлыгы чорында ук булуы документаль мәгълүм), Атай (Татарстанның Зеленодольск районы Мулла иле авылында Атай нәсел-ыру атамасында сакланган), Атакылыч, Атаморат, Атанияз, Атахуҗа, Атакай, Атахан, Атаяр, Атаҗан, Дәүатай, Олата (<Олыата), Картата; Бабай, Бабакай, Бабахан, Бабахуҗа, Бабахәсән, Бабанияз, Газизбаба>Азизбаба>Азбаба (соңгысы Татарстанның Апас районындагы татар авылы атамасында сакланган), Галибаба>Алибаба>Албаба. Соңгы варианты Татарстанның

Зеленодольск районындагы рус авылы һәм тимер юл станциясе атамасында безнең көннәргәчә сакланган. Тау ягындагы Азбаба һәм Албаба авылларының Казан ханлыгы чорында булулары мәгълүм. Бабаҗан, Абышка (*абышка* термины Себер татарлары телендә «баба, карт» мәгънәсендә кулланыла; Пермь татарларында *абышка* туганлык термины «ир» мәгънәсенә ия. Казан татарларында Абышкин фамилиясендә сакланган), Бабыш, Бабаш (Бабай, Бабаш исемнәре мариларга да кергән), Агай, Агый (татар теленең тау ягы сөйләшләрендә «өлкән ир туган» төшенчәсен белдерә торган *агай* туганлык терминын *агый* дип йөртәләр; Агый исеме Зеленодольск районы Мулла иле авылында Агый нәсел-ыру атамасында сакланган), Агабай (Казан татарларында Агабаев фамилиясендә сакланган, бу фамилия русларда да бар), Абай («абый»), Әҗе (борынгы төрки телдә *әҗе* — «өлкән ир туган, абый». Татар һәм руслардагы Азеев, Азиев фамилияләре шушы исемнән ясалган), Әҗебай, Әҗеби, Әҗегол, Абыз (борынгы төрки телдә *абыз* термины «тәҗрибәле, дәрәҗәле өлкән ага; аксакал, ил агасы, нәсел-токым башлыгы; җыен агасы» төшенчәсен белдергән. *Абыз* туганлык терминнарының *абзый, абзи, әбзи* «өлкән ир туган, ага» туганлык терминнары белән бер тамырга кайтып калуы һәм ислам динен кабул итмәгән Алтай төркиләре телендә дә урын алуы чыгышы белән төрки сүз булуын раслый), Абызбай, Абызбакый, Абызгилде, Абызгәрәй, Абызган, Абызмәгъдән, Абаш (борынгы төрки телдә *абаш* — «өлкән ир туган, эти ягыннан абый; Казан татарларында һәм русларда Абашев фамилиясе сакланган), Абзай («абзый, абый»; татар-типтәрләрдә Абзаев фамилиясендә һәм Башкортстанның Борай, Кыйгы, Дүртөйле районнарында Абзай дигән татар-башкорт авыллары атамасында сакланган), Такай ~ Тагай (борынгы төрки телдә *тагай* — «өлкән ир туган, абый»; Такаев, Тагаев фамилияләрендә сакланган), Апанай (борынгы төрки телдәге *аба ~ апа* — «өлкән туган» сүзенә *-най* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган исем. Казан татарларында Апанаев фамилиясендә сакланган). Без бу мисаллардан *агай ~ агый ~ абый ~ абыз ~ абаш ~ абзай ~ әҗе ~ такай ~ апанай* туганлык терминнары һәм алар катнашып ясалган байтак кына кеше исемнәренең синонимдаш булуын ачык күрәбез.

Республикабыздагы һәрбер районда кеше исемнәренә, кушаматларга яки фамилияләргә нигезләнеп ясалган торак пункт атамалары бик күп. Алар Татарстандагы барлык авыл атамаларының яртысыннан артыгын тәшкил итәләр.

Болар турында тулырак мәгълүматны «Татарстан АССР-ның антропотопонимнары» (Казан, КДУ нәшрияты, 1973) дигән китаптан табарга мөмкин. Мисал өчен, Татарстанның Әлмәт районындагы Бохарай, Габдрахман, Нәдер, Әлмәт, Багряж, Чулпан, Бота, Илтән-бота, Колшәрип, Бикморас, Дәүләт, Мәмәт, Миңлебай, Иштирәк, Ямаш һ. б. авыллар беренче килеп утырган, башлап казык каккан кешеләрнең исемнәрен йөртәләр. Антропотопонимик атамаларда ата-баба, нәсел-ыру культы бик ачык гәүдәләнә.

Аерым очракларда хәтта антропонимга нигезләнмәгән авыл атамасын да кеше исеме белән нисбәтле дип карау, ягъни ата-баба культы белән бәйләргә тырышу күзәтелә. Бер мисал китерик. Казан шәһәрендә яшәүче пенсионер Мөхәммәт ага Хәмитовның безгә Апас районындагы Чирмешән авылы исеменең килеп чыгышын ачыклауны сорап язган хатында шул авылдагы бер нәсел шәҗәрәсенең башында торган бабаларның берсе Чирмешән баба булуы турында сүз бара. Чынбарлыкта исә бу авылның исеме шундагы Чирмешән елгасы атамасыннан (гидронимнан) алынган.

## БОЛГАР-ТАТАРЛАРДА БАЛАГА ИСЕМ КУШУГА КАРАГАН ЙОЛА һӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ БӘЙЛӘНЕШЛЕ ИСЕМНӘР

Мондый йола һәм традицияләрнең үзләрен ике зур төркемгә аерып карый алабыз:

1. Ата-ананың, баланың туган-кардәшләренең, нәсел-ыруының теләгенә, хис-кичерешләренә, бу бала шундый сыйфатка, дәрәҗәгә ия булсын иде дигән өметләренә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән кеше исемнәре;
2. Асылларында баланың үзенә нисбәтле төрле ышану-йолалар, гадәт-традицияләр мотив булып яткан кеше исемнәре.

### Ата-ананың, туган-кардәшләрнең теләгенә, хис-кичерешләренә, өметләренә нисбәтле исемнәр

#### Сословие терминнарына нисбәтле кеше исемнәре

Мондый исемнәр берничә лексик-семантик төркем тәшкил итә. Хәзер шуларны карап китик.

Колбиләүчелек һәм феодаль җәмгыятьләрнең сословие титулларына нисбәтле кеше исемнәре татар антропоними-

конының борынгы лексик-семантик төркемнәреннән берсен тәшкил итә.

Татар телендәге сословие титулларын генетик яктан түбәндәге катламнарга аерырга мөмкин:

1) төрки-татар чыгышлы сословие титуллары: *хан, бигәч* (принц, хан улы), *оглан>огул* (Чыңгыз хан нәселенең хан тәхетенә утырмаган членнарының титулы), *бәк~бик~би* (князь), *инал* (аксөяк токымы, затлы нәсел), *карача* (атабек), *бай* (хуҗа, мал-мөлкәтле кеше), *тархан* (ханга буйсынучы, ләкин аңа ясак түләми торган вассал), *чура* (хезмәтче, игенче, дружина члены, батыр сугышчы), *кол, әлчи~илчи* (бикә, байбикә, байбичә) һ. б.

2) гарәп теленнән алынган сословие титуллары: *солтан* (патша, хөкемдар), *мәлик* (патша, солтан, хөкемдар), *мәликә* (патша хатыны, ханбикә, хатын патша), *мәүлана~мәүла* (әфәнде, хуҗа, хөкемдар; алла — галим һәм руханиларның почетлы титулы), *сәет~сәед* (башлык, җитәкче, хуҗа, әфәнде, аксөяк — Мөхәммәтнең кызы Фатыйма балаларыннан килгән аксөяк нәселгә бирелгән титул), *әмир* (хәрби башлык, әмер бирүче, боеручы, берәр өлкә яки дәүләт башлыгы), *хаҗи* (Мәккә шәһәрендәге изге урын Кәгъбәгә барып хаҗ кылган кешегә бирелгән рухани дәрәҗә, исем), *имам* (кешеләрне үзенә ияртеп, иң алга басып намаз укытучы мәхәллә башлыгы, өлкән мулла), *мулла~мелла* (укымышлы кеше, укытучы, остаз; дин әһеле, мәхәлләдә дин башлыгы) һ. б.

3) фарсы теленнән алынган сословие титуллары: *шаһ* (патша, хөкемдар, монарх), *морза* яки *мирза (әмир задә* — әмир баласы; аксөяк, затлы токым — өстен катлау вәкиленең титулы), *хуҗа* (әфәнде, хуҗа; өйрәтүче, укытучы; милек иясе), *ахун* (остаз, туры юлга күндерүче; мөселманнарда өлкән рухани) һ. б.

Болгар-татарларда бу титул-терминнар җәмгыять үсешенең төрле баскычларына карый.

Югарыда телгә алынган сословие титулларына нигезләнеп гади төзелешле байтак кына кеше исемнәре барлыкка килгән: Хан, Чура, Кол (шуннан Колов, Кулов фамилияләре), Тархан, Бай (шуннан Баев фамилиясе), Бәк (шуннан Биков фамилиясе), Морза, Мирза, Әмир, Мәлик, Мәүла, Сәет, Шәех, Имам, Хуҗа, Солтан, Мулла, Ахун, Бигәч — ир-ат исемнәре; Хаҗия, Хуҗия, Шаһия, Солтания, Мәүлия, Мәликә, Ханәкә — хатын-кыз исемнәре. Алар, исем компоненты сыйфатында, кушма төзелешле байтак кына антропонимнар составында урын алганнар.

Билгеле булганча, Идел-Кама болгар йортында һәм Казан ханлыгында дәүләт белән хан идарә иткән.

*Хан* сүзенең генезисы борынгы төрки *каган* «баш идарәче, баш хан» терминына барып тоташа. Борынгы төрки кабиләләр дәүләте — Төрки каганлыгы, төрки хазарлар дәүләте Хазар каганлыгы исемен йөрткән.

Каган һәм кан (хан) титуллары борынгы төрки телдә ук кеше исемнәре составында урын алганнар: Ай каган, Алтын каган, Инәл каган, Билге каган, Кара кан, Тавгач кара бугра-хан һ. б.

Идел-Кама болгарларының X гасырда яшәгән ханнарыннан берсе Алмасхан исемле булган.

«Хан» антрокомпоненты кушма төзелешле болгар-татар исемнәрендә беренче компонент булып та, икенче компонент булып та килә. Мәсәлән, Ханбакты, Ханбарс, Ханбирде, Ханбулат, Хангали, Хангилде; Морзахан, Тимерхан, Айхан, Акхан, Алтынхан, Ишхан, Гәрәйхан, Сәлимхан, Әҗмехан, Галихан, Әхмәтхан, Әшрәфхан һ. б.

«Хан» компонентлы исемнәр баланың хан кебек дәрәҗәле, абруйлы, бай булуын теләп кушылганнар. Н. А. Белгородский фарсыларга алынган төрки хан титулының мәгънәсе тараюына кызыклы күзәтү ясый. *Хан* сүзе, аның исбатлавынча, фарсыларда «патша, хөкемдар» мәгънәсеннән тыш, хәрби хезмәткәрләрдә, соңрак гади чиновникларда һәм иң ахырда сакалын кырып, мыек калдыручы кешеләрдә генә исемгә өстәлеп йөртелә башлаган.

Идел-Кама болгарларында *мир* (<*әмир*), *бәк*~*бик*~*би* титуллары башлыча феодаль җәмгыятьнең югары катлау вәкилләренең исемнәрендә урын алган. Болгар кабер-таш язмаларында мондый исемнәргә мисаллар шактый күп: Әмир, Мир-Ибраһим, Мир-Мәхмүт, Мир-Хөсәен; Бәктимер, Хөсәен-бәк, Гомәр-бәк, Хаҗи-бәк, Муса-бәк, Кутлуг-бәк, Салман-би һ. б.

Татарларда Әмирҗан, Әмирарслан, Әмиргали, Әмиргани, Әмирулла, Мирвәли, Миргази, Миргазиз, Миргазизҗан, Мирәхмәт, Мирхуҗа кебек *мир* (*әмир*) компонентлы ир-ат исемнәренең саны йөзгә якын. *Бәк*~*бик*~*би* (князь) компонентлы ир-ат исемнәре тагын да күбрәк: Биарслан, Бибарс, Бигилде, Бигиш, Бикбау, Бииш, Биморза, Бигали, Бикҗан, Биҗан, Биәхмәт, Тимербәк, Айбәк, Илбәк, Уразбәк, Рөстәмбәк, Тимбәк, Әнвәрбәк, Әминбәк һ. б.

Шунысы игътибарга лаек: Г. Әхмәров Казан татарларының кушма төзелешле исемнәрендә *бәк* сословие титулының алдан, ягъни беренче компонент булып, ә мишәрләрдә ахырдан, ягъни икенче компонент булып килүен

(мәсәлән, Бикбау, Бикмулла, Биктимер — Казан татарларында, Үзбәк, Байбәк, Ханбәк — мишәрләрдә) искәртеп уза.

*Бай* компоненты болгар-татар кеше исемнәрендә аеруча киң таралышка ия. Ул югары катлау һәм түбән катлау вәкилләре исемнәрендә дә урын алган. Борынгы төрки телдә үк Бай апа, Бай буга, Бай темүр, Түзбай исемнәре булган. Болгар каберташ язмаларында Байыш, Байкара исемнәре бар. Боларга өстәп Байарслан, Байбакты, Байбирде, Байбул, Байбулды, Байбура, Байкылыч, Байназар, Байсары, Байәхмәт; Арсланбай, Алтынбай, Тимербай, Ишбай, Миңлебай, Балтабай, Исәнбай, Иделбай, Толымбай, Әхмәтбай һ. б. кушма төзелешле исемнәрне күрсәтергә мөмкин.

Электә төрки халыкларда хан сарайларында «ханзадәләрне тәрбияләүче, караучы, укытучы, атабек» мәгънәсенә ия булган *карача* сословие титулыннан Карача исеме ясалган. Бу исем Татарстанның Мамадыш районы Берсут-Сукачы авылы зиратында 1539/40 нчы елларда куелган кабер ташында бар. Карача — Төмән өлкәсе Табул районындагы татар авылы атамасы.

*Тархан* титулы (монголча *дархан*) «тимерче, оста, һөнәр иясе» дигән мәгънә белдерә. Тархан — феодаль җәмгыятьтә ханнар тарафыннан аерым хезмәтләре өчен ясак түләүдән азат ителгән һәм башка өстенлекләр бирелгән феодал титулы. «Татарстан АССР тарихы»нда (Казан, 1970): «Казан ханлыгында тарханнар җир биләве киң колач җәя, бу феодалларның, шәхси иминлегеннән тыш, суд җаваплылыгыннан шәхси иреге һәм башка өстенлекләре була»,— диелә.

Тархан сословие титулы, Урта Идел һәм Урал буе җирлегендә Тархан авыллары атамасына күчкән. Мәсәлән, Татарстанның Тәтеш районында Олы Тархан, Кече Тархан, Югары Тархан һәм Кызыл Тархан дигән татар авыллары бар. Пенза өлкәсендә бер рус авылы Тарханы исемен йөртә, ул М. Ю. Лермонтовның әнисе ягыннан әбисенең имениесе булган. Башкортстанның Шаран районында Тархан исемле татар авылы бар һ. б. Бездә Тарханов фамилиясе дә очрый (мәсәлән, күренекле татар артисты Барый Тарханов, Чистай районы Яуширмә авылында Тарханов фамилиясен йөртүче гаиләләр бар).

Астрахань шәһәре атамасыннан килеп чыгышын борынгы төрки-татар Хаҗитархан (*хаҗи+тархан*) исеменә бәйләп аңлаталар. Хаҗитархан исеме татарлар әйтелешендә Хаҗитархан>Әҗитархан>Әстерхан рәвешле фонетик үз-

гәреш кичергән. Татарлар грек чикләвеген «әстерхан чикләвеге» диләр, тиз кызып китүчән кешегә «әчтерхан әтәче» кушаматын ябыштыралар.

Иске татар телендә актив кулланылышта йөргән *чура* 1) кол; 2) игенче, сабанчы, крестьян, крепостной; 3) сугышчы, дружинник, гаскәри сүзенә антропонимик иркәләүкечерәйтү кушымчалары ялгану юлы белән һәм бу сүзгә башка исем компонентлары кушылу нәтиҗәсендә, байтак кына ир-ат исемнәре барлыкка килгән. Мәсәлән:

Чура
ман — Чураман
ай — Чурай
аш — Чураш
ак — Чурак
кай — Чуракай
чык — Чурачык.

Чурабай, Чураби, Чуракилде, Чураиш, Акчура, Карачура, Айчура, Байчура, Бакчура, Таңчура, Ханчура, Колчура, Исәнчура, Ишчура, Илчура, Тиңчура — кушма исемнәр.

Татар антропонимиясендә кушма төзелешле кеше исемнәрен ясауда катнашучы сословие титуллары структур яктан төрле типтагы төзелмәләр барлыкка китергән. Иң киң таралган модель «сословие титулы+сословие титулы» (ягъни «исем сүз+исем сүз»). Төрки, гарәп һәм фарсы телендәге титуллар катнашлыгында барысы 9 төрле антропонимик модель булырга мөмкин:

а) «төрки сословие титулы+төрки сословие титулы»: Байбәк, Байбикә, Байчура, Бикчура, Чурабай, Ханбикә, Ханчура, Чурахан, Колчура, Чуракол, Байгол, Биктархан, Бикбай, Биккол, Колбай, Колбәк, Колбикә, Ялчыбай, Ялчыгол, Бичура, Чурабай, Чураби, Бибәк, Бихан һ. б.

б) «гарәп сословие титулы+гарәп сословие титулы»: Солтаншәех, Шәехсолтан, Әмирсәет, Мирсәет, Сәетәмир, Әмирсолтан, Солтанәмир, Муллахаҗи, Хаҗимулла, Хаҗисолтан, Солтанхаҗи, Хаҗиәмир, Имаммәлик һ. б.

в) «фарсы сословие титулы+фарсы сословие титулы»: Шаһиморза, Шаһихуҗа, Хуҗашаһ, Морзахуҗа, Хуҗаморза һ. б.

г) «төрки сословие титулы+гарәп сословие титулы»: Бикмулла, Байсәет, Колсәет, Хатынсолтан, Байсолтан, Баймулла, Хансәет һ. б.

д) «гарәп сословие титулы+төрки сословие титулы»: Муллабай, Мәүлабай, Сәетхан, Солтанбәк, Әмирхан, Әмирбай, Сәеткол, Сәетбәк, Сәетбай, Имамбай, Имамбәк, Имамкол, Хаҗибәк, Хаҗиби, Хаҗитархан һ. б.

е) «төрки сословие титулы+фарсы сословие титулы»: Байморза, Бикморза, Байхуҗа, Бикхуҗа, Угланхуҗа, Чуразморза, Чурашаһ һ. б.

ж) «фарсы сословие титулы+төрки сословие титулы: Ахунбай, Морзахан, Морзабай, Морзагол, Хуҗабай, Хуҗабәк, Хуҗахан, Морзаби, Шаһичура һ. б.

ж) «фарсы сословие титулы+төрки сословие титулы»: Солтанша(һ), Әмирхуҗа, Сәетхуҗа, Сәетша(һ), Сәетморза, Солтанморза һ. б.

и) «фарсы сословие титулы+гарәп сословие титулы»: Хуҗасәет, Хуҗашәех, Шаһисолтан, Морзасәет, Хуҗаәмир һ. б.

Татар антропонимиясендә сословие терминнарының кеше исемнәребезнең башка төркемнәре белән тыгыз мөнәсәбәткә керүләре нәтиҗәсендә дә, кушма төзелешле күп кенә ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре ясалган: Атабай, Атабәк, Аталияз, Бабахан, Балабәй ~ Бәләбәй (шуннан Бәләбәй шәһәре атамасы), Ирморза, Ирбай, Тимербикә, Байтимер, Хантимер, Тимерхан, Айхан, Аюхан, Байкилде, Ханкилде, Уразбай, Казанбай, Акчура, Карачура, Сарыбай, Карабай, Батырхан, Карахан, Колшәрип, Коләхмәт, Колгали, Рөстәмбәк, Мөхәммәтшаһбәк һ. б.

## Саклау (профилактик) исемнәр

Мондый исемнәргә сүзнең сихри көченә ышанып, бала яныннан усал көчләрне куркытып качыру нияте белән кушылган борынгы исемнәр керә.

Профилактик исемнәрнең биришесе тискәре мәгънәле сүзләргә нигезләнеп барлыкка килгән.

Борынгы төрки халыкларда яңа туган бала янына явыз көчләрне, җен-пәриләрне китермәү, аларны куркыту максатыннан чыгып, аңа «начар» мәгънәсенә ия булган Яман исеме яки яман компонентлы берәр кушма исем бирү йоласы булган. Яман, Яманай, Яманбикә, Яманғол, Яманчура, Ямантай һ. б. исемнәр әнә шул йола нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән. Татар гаиләләрендә *яман* компонентлы исемнәрне хәзер балаларга кушмыйлар. Алар Яманов (бу фамилия русларда да бар), Яманбаев, Яманголов, Мансаров, Ямантаев һ. б. кебек фамилияләребездә генә саклanганнар.

«Явыз көчләрне алдар» мәгънәсенә ия булган борынгы төрки-татар Алдар һәм Алдархан исемнәре дә — яңа туган ир баланы явыз көчләрдән саклау исемнәре. Алдар — татар халык әкиятләре персонажы.

Борынгы заманнарда төрки халыклар ир балаларга Ачи (Ачы) исеме биргәннәр. Бу исемнең Идел-Кама болгарларында һәм Казан татарларында кулланылышта йөрүен нәсел-ыру кушаматлары һәм Казан артындагы авыл атамалары раслый. Татарстанның Зеленодольск районы Норлат авылында бер нәсел Ачи кушаматын йөртә. Республикабызның Саба районында Ачы, Югары Ачы, Түбән Кама районында Ачи дигән рус авыллары бар. Казан артында Ачы дигән татар авылының (хәзерге Саба районындагы Ачы дигән рус авылы) Казан ханлыгы дәверендә булуы мәгълүм. XVIII гасырда чувашларда мәҗүси Ачи исемнең кулланылышта йөрүе билгеле (Магницкий В. К., 1905). Үзбәкләрдә Ачи исеме бүгенге көндә дә кулланылышта.

*«Ачы»* төшенчәсен белдерә торган исемнәр башка халыкларда да бар. Гарәпләрдәге Хамиз, Хәмзә, руслардагы Кислый, Кисляй, Кисляк, Кислята (Веселовский С. Б., 1974) исемнәре шундыйлардан. Безгә гарәпләрдән кергән Хәмзә исеме төрки-татар чыгышлы Ачы (Әче) исеме белән мәгънәдәш булып йөргән.

Борынгы төрки халыклар зәһәр исле әче үсемлек *сарымсак* атамасын бала янына явыз көчләр һәм авырулар килмәсен, алар, сарымсак исеннән һәм әчелегеннән куркып, бала яныннан качсын дигән теләктән чыгып, ир балага исем итеп биргәннәр. Суган һәм сарымсакның организм өчен файдалы булуы, авырулардан саклавы медицинада бик күптәннән билгеле. Борынгы сугышчылар күбә киемнәр эчендә суган яки сарымсактан ясалган ырым әйберләре йөрткәннәр. Аларның фикеренчә, суган һәм сарымсак төрле чирләрдән генә түгел, ук һәм кылычтан да саклаган. Татарларда Сарымсак исеме (русларда — Чеснок, шуннан Чесноков фамилиясе ясалган) безнең көннәргәчә сакланган. Сарымсаков фамилиясе үзбәкләрдә һәм каракалпакларда да бар.

Профилактик исемнәрнең бер төрен инкарь төшенчәсен белдерүче Атсыз (Исемсез) һәм Йомак, Йомгалак исемнәре тәшкил итә.

Борынгы заманнарда ир балага Атсыз исеме аны явыз көчләрнең эзләп тапмавын теләп, яман көчләрне алдау, эз яздыру өчен кушылган. Атсыз исемен югары катлау, хәтта хан, патша балаларына бирүдән дә тайчанмаганнар. Мәсәлән, Атсыз бине Мөхәммәт бине Апуш тегин 1127 елда этисе үлгәннән соң Хәрәзм тәхетенә утырган. Атсыз исемнең капма-каршысы (антонимы) — Атлы, Атлыкач.

Атлы, Атлыкач исемнәре ир бала үсеп җитеп, батыр-

лык күрсәткәннән соң кушылган. Борынгы төрки халыкларда кешегә үз гомерендә берничә мәртәбә исем кушу гадәте булган. Кешегә башта балалык исеме кушылса, үсеп буйга җиткәч (яуда, бәйгеләрдә катнашып сынаулар үткәч), аңа яңа исем — егетлек, батырлык символы булган «ир аты» бирелгән. Күренекле тюрколог С. Е. Малов бастырып чыгарган борынгы төрки каберташ язма ядкарьләрендә: «Ир атым — Удун», «Ир атым — яшь Аңбаш», «Ир атым — Ярук Тигин», «Ир атым — Ирән Улуг, ирдәмле батырмын». «Ир атым — Буга» һ. б. кебек ир-ат исемнәре бар.

Атлыкач — *атлы* (исемле) сүзенә *-кач* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы кушылып ясалган болгар-татар исеме. Бу исем Биектау районындагы Чуваш иле авылы зиратына XVI йөздә куелган кабер ташына язылган. Анда: Атлыкач улы Җәккәү (Якуб исеменең җирле әйтелеше. Керәшен татарлары әле дә Яков, Якуб исемен Җәкәү диләр.— *Г. С.*), Хафиз, Тәүкәл, Көҗәк, Татлыби исемнәре бар.

Йомак һәм Йомгалак исемнәре «йому, яшерү, очын югалту», «табышмак» мәгънәсенә ия. Себер татарлары һәм башкортлар табышмакны хәзер дә *йомак* диләр. Башкорт теленең сакмар сөйләшендә *йомалак* (<йомгалак) сүзе «табышмак» мәгънәсендә кулланыла. Борынгы заманнарда кешенең төп, чын исеме билгеле булса, исемен әйтеп, аңа авыру, зыян-зарәт китерергә мөмкин дигән мәҗүси ышану булган. Бу ышану кешенең чын исемен яшерү, табулаштыру күренешен тудырган. «Табышмак» төшенчәсен белдергән (ягъни чын исеме билгеле түгел, ул — табышмак) борынгы Йомак, Йомгалак исемнәре шушы йола тәэсирендә барлыкка килгәннәр. Татарстанның Саба районындагы бер татар авылы Йомгалак исемен йөртә. Татарлар арасында, сирәк булса да, Юмгалаков фамилиясе очрый.

«Төргәк», «йомгак» (ягъни «җеп очы яшерелгән әйбер») яки «яман» мәгънәсенә ия булган Черкен исеме дә — борынгы йола, серле-тылсымлы исемнәребезнең берсе. Черкен исеме, шул әйтелештә яки Черки рәвешен алып, Буа районындагы Черки-Килдураз, Черки-Бәбки, Черки-Ишмәк, Черки-Кощак, Черки-Дүртиле, Күл Черкене, Апас районындагы Табар-Черкен һәм Төбәк Черкене кебек болгар бабаларыбыз тарафыннан нигезләнгән борынгы авыллар атамасы составында урын ала.

Борынгы чувашларда Пелтер (Былтыр), болгар-татарларда Былтыр (Узган ел) профилактик исемнәре кулла-

нылышта йөргән. Мәҗүси чувашлар, болгарлар һәм башка төрки халыклар усал көчләрне, җен-пәриләрне алдау өчен, ир балага Пелтер (Былтыр) исемен кушканнар. Шулай эшләгәч, усал көчләр бу балага яманлык, усаллык эшли алмыйлар, аның яңа гына туyын белми калалар, саташалар, имеш. Г. Тукайның «Шүрәле» әкиятендәге Былтыр исемен исебезгә төшерик.

Болгар-татарларда бу балага усал көчләр, җен-пәриләр тимәсен, аннан өрексен, аны читләтеп үтсен дигән теләктән чыгып барлыкка килгән һәм асылларында *өрку, курку* сүзләре яткан саклау исемнәре дә кулланылышта йөргән. Шундый исемнәрдән Өркәш исеме «куркыныч, куркыта торган» дигән мәгънәгә ия. Татарстанның Кукмара районындагы Өркәш авылының атамасы Өркәш дигән борынгы татар кешесе исеменнән алынган.

Борынгы телебездә Өркенде (Курыкты) исеме дә кулланылышта булган (шушы исемнән, сирәк булса да, татарлар арасында очрый торган Өркендиев фамилиясе ясалган). *Өркен* (кайтым юнәлешендәге фигыль) һәм *бай* сүзләре кушылу юлы белән Өркенбай исеме ясалган, Өркенбаев фамилиясе шул исемнән килә.

## «Киленне аклау» исемнәре

Борынгы заманнарда татарларда озак вакыт бала тапмаган киленгә Кысыр кушаматы тагылган. Әгәр шундый килен тора-бара бала тапса, баласына «киленне аклау» исеме кушканнар. Борынгы төрки-татар Акланыш, Агарыш исемнәре әнә шундыйлардан. Башкорт язучысы Йосыф Гәрәй Акланыш∼Актаныш исеменең асылында *аклану* (өстән гаеп төшү) сүзе ята дип саный. Агарыш исеме «агару, аклану» мәгънәсенә ия.

Акланыш исеме, *л∼т* тартыклары күчеше нәтиҗәсендә, Актаныш формасын алып, Татарстандагы Актаныш авылы (район үзәге) һәм район атамасында сакланган. Агарыш исеменнән русларда Агарышев фамилиясе барлыкка килгән.

Татарларга гарәпләрдән кергән Бәйинә∼Бәйнә (дәлил, факт), Бәяз (аклау, аклык), Дәлил — Дәлилә (дәлил, исбат итү, танык), Борһан (дәлил, исбатлаучы), Хөҗҗәт (дәлил, факт, ышандыргыч аргумент) кебек исемнәр дә кайчандыр кулланылышта «киленне аклау» исемнәре булып йөргәннәр.

## Баланың сау-сәламәт булуын теләү исемнәре

Баланың ата-анасы, туганнары, нәсел-ыруы теләгенә нисбәтле кеше исемнәренең бер төрен баланың сау-сәламәт булып үсүен теләү исемнәре тәшкил итә.

Металл атамалары һәм алардан ясалган хезмәт һәм сугыш кораллары исеменә нигезләнгән Тимер, Тимербай, Тимербәк, Тимербикә, Тимербаш, Балта, Балтабай, Кылыч, Байкылыч һ. б. кебек исемнәрнең баланың таза һәм сау-сәламәт булып үсүен һәм яшәвен теләү исемнәре булуы турында сөйләгән идек инде.

Төрки-татар чыгышлы *исән, сау, тере* компонентлары кергән исемнәр дә баланың сау-сәламәт булып тууын, үсүен һәм яшәвен теләү исемнәре төркеменә карыйлар.

Тарихи антропонимиконыбызда *исән* компоненты катнашып ясалган исемнәребез шактый күп: Исән, Исәнаман, Исәнбай, Исәнбакты, Исәнбирде, Исәнбул, Исәнбулат, Исәнбуга, Исәнбулды, Исәнгол, Исәнмөхәммәт (диалекталь вариантлары: Исәнмәмәт, Исәнмәт, Исәмәт), Исәнсәйф, Исәнтәй, Исәнтимер, Исәнтор, Исәнчура, Исәньюл, Исәньяр; Исәнбикә, Исәнбану, Исәнбәнат, Исәнгөл һ. б.

*Сау* компонентлы исемнәр: Саубура, Саугилде, Сауман, Сауләт, Сайморза, Саучура (Саучурин, Саучуров фамилиясендә сакланган), Сауҗан; Саубикә, Саубәнат, Саубану, Саугөл һ. б.

*Тере* компонентлы исемнәр: Теребай, Теребак, Теребирде («Себер татарларында Теребирдеев фамилиясендә сакланган), Терекол, Теремөхәммәт, Терехан (шушы исемнән русларда Тюрюханов фамилиясе ясалган), Тереҗан; Теребикә, Терекамал, Теребәнат, Теребану, Терегөл һ. б.

Татарларга гарәпләрдән кергән Хәят (тереклек, яшәеш, тормыш), Гайшә (тере, яшәп торучы), Сәлим-Сәлимә (исән-сау, сәламәт), Сәлим (исәнлек, саулык), Сәламәт (исән-сау) исемнәре һәм шул исем компонентлары катнашып ясалган: Бибихәят, Бәдерхәят, Бибигайшә, Гөлгайшә, Гайшәбикә, Гайшәбану, Сәлимәбану, Бибисәлимә, Сәлимәбикә, Сәлимзәвәр, Сәлимҗәүһәр, Сәлимгәүһәр; Сәлимбай, Сәлимбәк, Сәлимҗан, Сәлимхуҗа, Сәлимгәрәй, Сәлимзадә, Сәлимкүрде, Сәлимулла, Сәлимхан, Сәлимша(һ), Сәлимьяр, Сәлимьюл, Сәлимҗан һ. б. исемнәр шулай ук баланың сау-сәламәт булып үсүен, яшәвен теләп кушылганнар.

## Баланың авырудан терелүен теләү исемнәре

Бу төр борынгы исемнәрнең асылларында ата-ананың авыру, чирләшкә булып туган сабыйның авырудан терелүен, сәламәтләнүен теләүне белдерүче фигыль сүзләр ята.

Борынгы төрки-татар Ачыл исеме ир баланың авырулардан арынуын, котылуын, ачылуын теләп кушылган. Төрдәше Очил үзбәкләрдә, бурятларда, монголларда һәм калмыкларда хәзер дә кулланылышта йөри. Кушма төрләре Ачылбай, Ачылбәк, Ачылҗан һ. б. Ачылгөл — «ачыл гөл; терелер, сәламәтләнер гөл». Авыру булып туган кыз баланың авырулардан арынуын, ачылуын, сәламәтләнүен теләү исеме.

*Төкәнәй* — «төкәнәй; бөтәй, сәламәтлән, тазар». Җиде айдан ук, ягъни җитлекмичә туган ир балаларга кушыла торган борынгы йола исем. Төрдәше Тәкәнәй. Казан татарларында Тәкәнәев (Таканаев) фамилиясендә сакланган.

*Тор* (яшә, гомер ит) боерык фигыленә нигезләнеп ясалган борынгы төрки-татар кеше исемнәре дә баланың авырудан терелүен, дөньяда торуын теләп кушылган: Торбай, Торбатыр, Торбәк, Торбикә, Торгын (татар-мишәрләрдә Тургунов фамилиясендә сакланган), Торсын, Торсынбай, Торсынбәк, Торсынбикә, Торсынгали, Торсынгол, Исәнтор, Амантор һ. б.

Сауык (Савык), Саулат, Сауит һәм уртак Саурыш (Саврыш), Сауыш (Савыш) исемнәре дә авыру ир баланың савыгуын, авырулардан арынуын, сәламәтләнүен теләп кушылганнар.

В. К. Магницкий хезмәтендә (1905) күрсәтелгән Саурыш һәм Сауыш исемнәре икесе дә «савыгырга булыш, ярдәм итеш» мәгънәсен белдерәләр. Алар ябык, бик зәгыйфь, авыру булып туган ир баланы савыктырырга теләп, илаһи көчне ярдәмгә чакырып кушылган. Бу исемнәр республикабызның Саба районындагы Сауыш, Олы Саврыш, Түбән Саврыш дигән татар авыллары атамаларына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган. Аксубай районында Савруш, Иске Савруш, Түбән Сауруш дигән чуваш авыллары да барлыгын искәреп китик.

Киләчәк заман хикәя фигыльнең юклык формасын ясаучы *-мас, -мәс* кушымчасы алган фигыльләргә нигезләнеп тә баланың авырулардан терелүен, сәламәтләнүен теләү исемнәре барлыкка килгән: Коттаймас, Җантаймас, Таймас, Атмас, Алмас, Бетмәс, Бетсәмәс һ. б.

Коттаймас һәм Җантаймас исемнәре, синтаксик яктан

караганда, ия белән хәбәрдән торган җыйнак җөмлә тәшкил итәләр. Коттаймас исеменең янәшә килгән «тт» тартыкларының берсе төшеп калган Котаймас варианты электә Кышлау авылының (хәзерге Арча районында) параллель атамасы булып йөргән.

Коттаймас яки Җантаймас исемнәренең кыскарган варианты Таймас исеменә нигезләнеп татарларда һәм башкортларда Таймасов фамилиясе һәм авыл атамалары ясалган. Башкортстан АССРның Күмертау районында Таймас исемле — башкорт, Яңа Таймас дигән рус авыллары бар.

Бетсәмәс — Әгерҗе районындагы татар авылы атамасы. Бу атаманың нигезендә яткан борынгы төрки-татар Бетсәмәс исеме «бетмәс, үлмәс» дигән мәгънәгә ия. Бу исемнең тамырын тәшкил иткән бетү сүзе борынгы телебездә «үлү» төшенчәсен дә белдергән.

Мәҗүси исемнәребездән Атмасны «җан атмас» ягъни «җанын атмас, ташламас, үлмәс», Алмасны «үлем алмас» мәгънәсендәге авырудан терелүне теләү исемнәре дип карый алабыз. Яшәр, Торыр, Терелер кебек борынгы исемнәрне исә Яшәр бала, Торыр угыл, Терелер бала рәвешле тулыландырып карарга мөмкин.

## Баланың көчле, батыр булуын теләү исемнәре

Борынгы ыруглык, колбиләүчелек һәм феодаль җәмгыятьләрдә ярыш-бәйгеләрдә, сугышларда өстен чыккан, батырлык күрсәткән ир-ат хөрмәт-абруйга ирешкән, дәрәҗәгә ия булган. Менә шуңа элек-электән ир баланың көчле, гайрәтле һәм батыр булып үсүен теләгәннәр һәм бу теләк кеше исемнәрендә дә чагылыш тапкан.

Ир баланың көчле һәм батыр булуын теләүнең, метафорик рәвештә, кыргый һәм йорт хайваннары (арыслан, каплан, барс, сыртлан, ягуар, буга һ. б.), ау кошлары (лачын, бөркет, карчыга һ. б.) атамаларына нигезләнгән исемнәрдә чагылыш табуына алда тукталдык. Мондый исемнәрнең байтагы *алып, пәһлеван, баһадир, батыр, каһарман, көч, куәт, гайрәт, мөңке ~ бөкә* сүзләренә нигезләнеп яки шул сүзләр катнашып ясалган.

*Көч* сүзе борынгы төрки телдә үк антропоним һәм антрополексема булып кулланылган: *Күч, Күч барслык, Күч күл тутук* һ. б.

Болгар кабер ташы язмаларының берсендә Йөркүч (*йөри* дружинник»+*күч* «көч»), ягъни хәрби чин+кеше исеменнән гыйбарәт антропоним бар (Хакимзянов Ф. С.,

1978). Иске татар телендә (XV—XVIII йөзләр) составларына *көч* компоненты урын алган Көчбатыр, Көчбай, Көчбәк, Көчкилде, Көчкуәт (Әстерхан татарларында Кучкуатов фамилиясендә сакланган), Көчморза, Көчтирәк исемнәре кулланылышта йөргән. Күргәнебезчә, *көч* антропонимик берәмлеге борынгы төрки телдән болгар теленә, болгар теленнән татар теленә килеп керә. Монда Идел-Кама болгарлары этносы, теле һәм атропонимиясе белән татар этносы, теле һәм антропонимиясе арасындагы тарихи күчемлелек һәм дәвамчанлык бик ачык чагыла.

Борынгы төрки⟶болгар⟶татар антопонимик күчемлелеге *алып* (әзмәвер, гадәттән тыш зур гәүдәле кеше, великан, герой, баһадир) компонентлы кеше исемнәрендә дә чагылыш таба.

«Борынгы төрки сүзлек»тә *алп* сүзенең 1. мәргән; 2. батыр, баһадир, витязь; 3. кыю һәм 4. батырлык, ирдарлык мәгънәләрен белдерүе күрсәтелгән. Шушы сүзгә нигезләнеп байтак кына борынгы төрки кеше исемнәре ясалган: Алп айа, Алп кутлуг, Алп тархан, Алп тутук, Алп таш һ. б.

Идел-Кама болгарлары арасында ифрат зур гәүдәле, көчле әзмәверләр — алыплар яшәве турында Болгарга X йөздә сәяхәт иткән Әхмәт ибне Фадлан, XII гасырда Болгарда ике мәртәбә булган Әбү Хәмид әл-Гарнати язып калдырганнар. Татар халкының борынгы риваятьләрендә Алып бабай гаять зур гәүдәле, көчле кеше итеп сурәтләнә: «Алып — батыр кеше иде, әгәр дә ул эшкә чынлап тотынса, кечкенәрәк тауларны аудара һәм бер кулы белән атларны яки сыерларны күтәрә ала иде» (Борынгы татар әдәбияты.— Казан, 1963).

Татарлар арасында еш кына калку урыннарны, зур булмаган тауларны «Алып бабай чабатасын каккан җир» дип йөртәләр. Татар теленең Минзәлә сөйләшендә бүгенге көндә дә *алпамыш* сүзе «алып, зур гәүдәле кеше, көчле, батыр», *алапа* сүзе «зур, таза гәүдәле, озын буйлы кеше» мәгънәсендә кулланыла.

Идел-Кама болгарларында Алып, Алыпхуҗа, Алыптай, Урум Алып кебек кеше исемнәре булган. Болгар эпитафикасы белгече Ф. С. Хәкимҗанов Урум Алып тезмәсен топоним (Урум) һәм кеше исеменнән (Алып) гыйбарәт псевдоним — тәхәллүс дип карый һәм «Алп из Урюма» төшенчәсен белдерә дип саный. Хәлбуки, Урум — «озын» мәгънәсенә ия булган шәхси кушамат, ә Алып — кеше исеме. Безнең фикеребезчә, Алып исемле шәхескә зур гәүдәле, озын буйлы булганга Урум (Озын) кушаматы тагылган. Болгар каберташ язмасында очраган Урум Мөхәммәд

тезмәсе дә, Ф. С. Хәкимҗанов язганча, Мухаммед из Урюма төшенчәсен белдерми, бәлки «Озын Мөхәммәд» дигәнне, ягъни Озын кушаматлы Мөхәммәд дигән шәхесне аңлата.

*Урум* сүзенең килеп чыгышын чувашча *варам* (озын, сузынкы), татарча *озын,* башкортча *озон* сүзләренә һ. б. бәйләп карый алабыз.

Татарстанның Саба районында Орымширмә (Озын чокыр), Каралширмә (Кара чокыр), Икширмә (Ике чокыр) дигән татар авыллары, Тәтеш районында Урюм дип аталучы мордва авылы (ул Урюм елгасы буена утырган), Апас районында Орым Тәрбите («Орым» дип аталган елга янында) дигән керәшен татарлары авылы бар. Удмуртиянең Алнаш районында «Урум» дип аталган озын чокыр кырыена утырган удмурт авылы Урум исемен йөртә. Күргәнебезчә, әлеге авыл атамаларында *урум*~*орым*~*урюм* (озын) сүзе, бу авыллар я озын чокыр, я булмаса Орым~Урюм исемен йөртүче озын елга буенда утырганга, урын алган.

Татарларда XV—XIX йөзләрдә Алыпарслан, Алыпбай, Алыпбәк, Алыпкол, Алпар, Алапай исемнәре кулланылышта булган. Боларның кайберләре авыл исемнәренә һәм фамилияләргә әверелгән. Алапай исеменнән Алапаев фамилиясе ясалган. Татарстанның Әлки районында Иске Алпар һәм Яңа Алпар дигән татар авыллары бар. Әлеге ойконимнар Алпар дигән төрки-татар кеше исеменә нигезләнеп ясалганнар. Сирәк булса да, татарлар арасында очрый торган Алпаров фамилиясенең (мәсәлән, күренекле татар тел белгече Гыйбад Алпаров) асылында шушы исем ята.

С. Е. Малов «Памятники древнетюркской письменности» (М.-Л., 1951) дигән хезмәтендә *алп* (герой) сүзенә Күл-Тәгин ядкарендәге Алп әр исемен мисал итеп китерә. Борынгы төрки телдә *әр* «ир» мәгънәсен белдерүен исәпкә алсак, Алпар исеме «батыр ир» мәгънәсенә ия булып чыга.

Борынгы төрки телдә үк урын алган *батур* (герой, богатырь) сүзе һәм Батур исеме асылда борынгы фарсы чыгышлы *баһадир* сүзенә барып тоташа.

«Борынгы төрки сүзлек»тә *багатур* сүзенең кеше исеме һәм титул булып йөрүе күрсәтелгән. Алтын Урда дәүләтендә *баһадир* дигән хәрби титул булган: «Ак-Тимур-баһадир, Казанчы-баһадир, Каранчи-баһадир, Колынчак-баһадир, Мөхәммәд-Солтан-баһадир, Мөхәммәд-Җүки-баһадир (Идел-Кама болгарларында Җикү дигән ир-ат исеме

булган. Казан татарларында Җикмәргән), Омар-шәех-баһадир һ. б. Татар антропонимиконында баһадир сүзенә нигезләнеп Баһадир исеме барлыкка килгән.

Татарларда *батыр* сүзе катнашып байтак кына кеше исемнәре ясалган: Батыр (шуннан татарлардагы Батыров, руслардагы Батырев фамилиясе. Чувашстан АССРда Батыр дигән район һәм район үзәге булган зур авыл бар. Бу районда күбесенчә татар-мишәрләр яши), Батырай (шуннан Батыраев, Батраев фамилияләре), Батырбай, Батырбәк, Батырбулат, Батыргали, Батыргәрәй, Батыркай, Батырхан, Батырхуҗа, Батырша(һ), Батырҗан, Илбатыр, Ишбатыр, Көчбатыр, Байбатыр, Ташбатыр, Тимербатыр, Яубатыр һ. б.

Ир баланың көчле һәм батыр булуын теләп кушылган исемнәр төркеменә борынгы төрки-татар Кощак исеме дә карый. Бу исемнең этимологиясе төрек, чыгтай, кырым татарлары телендә сакланган *кочак* (кыю, батыр егет, герой) сүзенә нисбәтле. Хәзерге кумык телендә дә *къоччакъ* сүзенең мәгънәсе шуңа тәңгәл.

Татарстанның Питрәч районындагы Кощаково дигән рус авылы атамасы борынгы төрки-татар Кощак исеме белән мөнәсәбәтле. Казан ханлыгы чорында бу җирләр Кощак исемле татар князенең биләмәләре булган, бу авылга шул князьнең исеме бирелгән. «Татарстан АССР тарихы» китабында (Казан, 1970) Казан ханбикәсе Сөембикәнең ире Сафагәрәй үлгәннән соң, Кырым хәрби отрядлары яубашы Кощак-Уланны үзенә якынайтуы һәм вакытлы идарә итү вәкаләтләрен аңа тапшыруы турында әйтелә. Республикабызның Буа районындагы Казма дигән татар авылы русча Черки-Кощаково дип атала.

Татар антропонимиконында фарсы чыгышлы *каһарман* һәм *пәһлеван* сүзләренә нигезләнеп Каһарман (диалекталь вариантлары Карман, Караманай, Караманый) һәм Пәһлеван исемнәре ясалган. Фарси Дилавәр исеме «йөрәкле, батыр, курку белмәс» мәгънәсенә ия. Гарәби чыгышлы *гайрәт* һәм *куәт* сүзләреннән Гайрәт, Гайрәтбәк, Гайрәтулла; Куәт, Куәтбай, Куәтбәк, Куәтбирде, Куәткилде, Көчкуәт, Байкуәт, Исәнкуәт, Ишкуәт исемнәре барлыкка килгән.

Татарлар кулланылышка алган гарәби чыгышлы Җәсим-Җәсимә, Шоҗаг исемнәре дә «батыр, кыю, гайрәтле, йөрәкле» дигән мәгънәгә ия. Гарәби Азамат исеме шулай ук «рыцарь, баһадир, герой» мәгънәсен белдерә. Диалекталь вариантлары Азай, Азук. Болардан Азаматов, Азаев, Азуков фамилияләре ясалган.

## Баланың бәхетле, мул тормышлы, мал-мөлкәтле булуын теләү исемнәре

Иске татар телендә «бәхет», «бәхетле», «хәерле», «уңыш», «шатлык» мәгънәсенә ия булган *ураз (араз, рыс), теләй, кот, котлы* сүзләре катнашында баланың бәхетле булуын теләгән гади, ясалма һәм кушма төзелешле исемнәр барлыкка килгән. Мәсәлән: Араз, Ураз, Теләй; Уразлы ~ Котлы; Котлыбак ~ Уразбак, Котлыбай ~ Уразбай, Котлыбәк ~ Уразбәк, Котлыбикә ~ Уразбикә; Котлыбану, Котлыбикәч, Котлыниса, Котлыгөл; Уразбану, Уразгөл; Котлыбарс, Котлыби, Котлыбуга, Котлыбулат, Котлывафа, Котлывәли, Котлыгилде, Котлыгәрәй, Котлыдәүләт, Котлызаман, Котлыиш, Котлыкадәм; Уразай, Уразбага, Уразбакты, Уразбирде, Уразгали ~ Уразали, Уразгол, Уразгуҗа, Уразман, Уразмөхәммәт (диалекталь вариантлары: Уразмәт, Размәт, Үрәзмәт, Уразик, Үрмәт, Урмат), Уразтимер, Уразхан, Уразҗан һ. б.

Исемнәребез хәзинәсенә тора-бара Котлы, Ураз, Уразлы кебек төрки-татар чыгышлы синонимик исемнәр рәтенә шул ук мәгънәдәге гарәби чыгышлы Бәхет, Сәгадәт (Сәгъдәт), Мөбарәк исемнәре өстәлгән.

Татар антропонимиконында 150 дән артык кушма төзелешле ир-ат һәм хатын-кыз исеме *миңле* (әйтелеше *миңне ~ миң*) антрополексемасы кушылу юлы белән ясалган. Борынгы заманнарда миңле бала бәхетле була дип ышанганнар һәм яңа туган сабыйга тәнендә миң булса яки соңрак миң чыкса, баштагы исемен алмаштырып, аңа *миңле (миңне)* сүзе кергән исем биргәннәр. *Миң, миңле* сүзе матурлык, чибәрлек, күркәмлек, символы булып та саналган. Фарсы-таҗик телендә «миң, миңле» мәгънәсендә йөри торган *хол ~ хал* сүзенең (татарча әйтелештә *кал)* татар антропонимиясенең бер үк исем компонентларына кушылуы нәтиҗәсендә, татар телендә байтак кына кушма төзелешле синонимик пар тәшкил итүче ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре барлыкка килгән: а) Калбай ~ Миңлебай; Калбәк ~ Миңлебәк; Калморза ~ Миңлеморза; Калмөхәммәт ~ Миңлемөхәммәт; Калгали ~ Миңлегали; Калхуҗа ~ Миңлехуҗа һ. б.; б) Калбану ~ Миңлебану; Калбәян ~ Миңлебәян; Калбикә ~ Миңлебикә; Калзадә ~ Миңлезадә; Калзөһрә ~ Миңлезөһрә; Калчәр ~ Миңлейөз ~ Миңлеруй; Калниса ~ Миңлениса > (Миңниса); Калсылу ~ Миңлесылу > (Миңсылу) һ. б.

Татарларда баланың бәхетле, мул тормышлы, мал-мөлкәтле булуын теләү исемнәре гарәп теленнән кергән

*дәүләт* (1. байлык; мәмләкәт, ил; 2. бәхет; хәзинә), *нигъмәт* (1. бәхет, байлык; 2. ашамлык-эчемлек; 3. ләззәт), *нәгыйм* (1. бәхет, мул тормыш; 2. татлы тәм, ләззәт; нигъмәт; 3 .бәхетле) антрополексемаларына нигезләнеп тә барлыкка килгәннәр: Дәүләт, Дәүләтбай, Дәүләтбакты, Дәүләтбирде, Дәүләтнур, Нурдәүләт (Норлат — Татарстандагы шәһәр һәм берничә татар авылы атамасы), Байдәүләт, Дәүләтсолтан, Дәүләтхан, Дәүләтхуҗа, Дәүләтчура, Дәүләтша(h), Дәүләтьяр, Дәүләтҗан, Дәүләтҗиһан, Дәүләтҗыйган; Дәүләтбану, Дәүләтбикә, Дәүләтгөл, Дәүләтниса; Хәзинә, Хәзинәбану; Нигъмәт, Нигъмәтулла, Нигъмәтхан, Нигъмәтҗан, Нәгыйм, Нәгыймә, Нәгыйметдин, Нәгыймулла, Нәгыймхан, Нәгыймҗан һ. б.

## Баланың озын гомерле булуын теләү исемнәре

Баланың озын гомерле булуын теләү башлыча «озын гомер», «озак яшәү» төшенчәсен белдерүче *өркет* (озын, даими), *озак, үлмәс, бүз* (ак, чал, чаларган), *мәңгүш* (мәңге иш), *ашмас* (үлмәс) сүзләре һәм *җитмеш, сиксән, туксан, йөз, мең, төмән* (ун мең) кебек сан атамаларына нигезләнеп ясалган исемнәр белән белдерелә.

Өркет исеме кушылган ир бала озын гомерле була, озак яши дип ышанганнар. Бу исемнең диалекталь вариантлары: Өркәт, Әркәт (шуннан Зеленодольск районы Мулла иле авылындагы Әркәт нәселе атамасы), Өркәй, Өрки. Болар Казан татарларында Өркетов (Уркутов), Әркәтов (Аркатов), Өркиев (Ркиев) фамилияләрендә саклanган.

Төрки халыкларда *озак* сүзе катнашып Байозак, Торозак, Җанузак, Гаетозак (>Аитзак), Гомерозак кебек ир-ат исемнәре барлыкка килгән. Татарларда ир балага озын гомер теләп кушылган Гомерозак исеме XX йөз башларына кадәр кулланылышта йөргән. Диалекталь варианты Умырзак. Казан татарларында Гомерзаков, Умырзаков фамилияләрендә (мәсәлән, Татарстанның Әлмәт районы Нәдер авылында) сакланган. Җанузак исеменнән казахларда — Җанузаков, Өмүрзак (Өмүрүзак) исеменнән кыргызларда Өмүрзаков (Умурзаков) фамилиясе ясалган.

Фарсы чыгышлы Дираз исеме дә «озын, озак, дәвамлы (гомер)» мәгънәсенә ия.

Үлмәс (ир-ат һәм хатын-кыз исеме), Үлмәсбай, Үлмәсбәк, Үлмәсбикә, Үлмәскамал, Үлмәскол, Үлмәсҗамал һ. б. кебек исемнәр дә бу бала үлмәсен, озак яшәсен, озын гомерле булсын дигән теләктән чыгып кушылганнар. Борын-

гы төрки телдә «үлмәс» мәгънәсенә ия булган Ашмас исеме дә кулланылышта йөргән. Бу исем Казан татарларында Ашмасов фамилиясендә сакланган.

Болгар-татарларда *буз* (1. аксыл, чал, чаларган, картайган; 2) буй җиткән, зур үскән) компонентлы Бүзьегет, Бүзтимер, Бүзтирәк, Бүзәргән, Бүздәк (Башкортстандагы район һәм район үзәге атамасында сакланган), Бүзәк (Казан татарларында һәм татар-мишәрләрдә Бүзәков, Бузяков фамилияләрендә сакланган) һ. б. кебек кеше исемнәре шулай ук баланың буй җитүен, озын гомерле булып, чәчләренә чал кереп картайганчы яшәвен теләп бирелгәннәр.

Төрки халыкларда Сиксәнбай, Сиксәнбәк, Сиксәнбикә, Туксанбай, Туксанбак, Туксанбәк, Туксанбикә һ. б. кебек составларында *сиксән, туксан* саннары булган кеше исемнәре дә бар. Мондый исем бала сиксәнгә яки туксанга җитсен, ягъни озак яшәсен дигән теләктән чыгып, яисә әтисе сиксән яки туксан яшькә җиткәч туган балага кушылган. Урал татарларында Сиксәнбаев фамилиясе, татар-мишәрләрдә Туксанбаев фамилиясе бар. Казахларда, кыргызларда, нугайларда һәм үзбәкләрдә Сиксәнбай, Туксанбай, Сиксәнбикә, Туксанбикә исемнәре хәзер дә кулланылышта йөри.

Борынгы заманнарда *йөз* һәм *мең* кебек «түшәм саннары»на нигезләнеп тә баланың озын гомерле булуын теләү исемнәре барлыкка килгән: Йөзмөхәммәт —«йөз яшәр Мөхәммәт» (диалекталь вариантлары Йөзмәт, Йөзмәй, Йөзмәмәт, Йөзмөхәм, Йөзмүк, Йөзми), Йөзьяшәр —«йөзәй, ягъни йөзгә җит» (Йөзәй ~ Йүзәй ~ Йүзи), Меңьяшәр, Меңҗитәр исемнәре әнә шундыйлардан.

Борынгы төрки халыкларда *төмән* (ун мең, чиксез күп, бик күп) саны түшәм сан булып йөргән һәм антропонимиядә балага озын гомер теләү исемнәре ясауда катнашкан. Мәсәлән, Төмән (Төмәнов, Тюменов фамилиясендә һәм Көнбатыш Себердәге шәһәр атамасында сакланган), Төмәнбай, Төмәнби, Төмәнбикә, Төмәнкилде, Төмәнтимер, Төмәнче («ун меңче»— Тюменцев фамилиясендә сакланган), Төмәншәех, Төмәнгил һ. б. Соңгы исемгә кинрәк тукталып китәсе килә. Төмәнгил исеме —«бик озак, ун мең ел яшәр бала кил («ту») дигән мәгънәгә ия. Шушы исемнән ясалган Тумангелов фамилиясен Болгария Халык Республикасында яшәүче берничә татар гаиләсе йөртә. Бу якларга XVI гасырның икенче яртысында, Казан һәм Әстерхан ханлыклары җимерелгәннән соң, татарларның көчеп килеп утырулары мәгълүм.

Болгар-татарлар ислам дине кабул иткәннән соң (X йөз)

баланың озын гомерле булуын теләп кушыла торган төрки чыгышлы исемнәр төркеменә шул ук мәгънәләргә ия булган гарәби һәм катнаш чыгышлы Гомәр ( гомер, гомерле, яшәү, яшәүчән), Гомәрбай, Гомәрбәк, Гомәргали, Гомәрхан, Гомәрҗан; Гомәрә, Гомәрбикә, Мөгаммәр (озын гомерле); Даим, Даимә, Даимия (даими, һәрвакыт булып тора торган); Бакый (мәңгелек, мәңге яшәүче), Бакыя, Бакыйбай, Бакыйхан, Бакыйҗан, Бакай, Самат (мәңгелек, мәңге яшәүче); Каюм (мәңге яшәр), Халит (мәңге яшәр, үлемсез, даими), Халидә; Лаим, Лаимә (үлемсез), Сәрмәт, Сәрмәдия (мәңге дәвамлы, мәңгелек, үлмәс); Әлфин, Әлфинә (мең яшәр; мең асыллы), Әлфия (мең яшәр), Җавид — Җавидә (мәңге, мәңгелек; үлемсез), Әзәл — Әзәлия (мәңгелек, чиксез; бетмәс-төкәнмәс) һ. б. исемнәр өстәлгән һәм киң таралыш алган.

### Баланың булуын, тууын теләү исемнәре

Борынгы заманнарда төрки халыкларда гаиләдә, нәселдә озак вакыт бала булмый торса, яки туган балалар үлеп барса, тәңредән бала сорау, баланың үлмәвен, яшәвен теләү, үтенү, ялвару йоласы башкарылган. Бу йола «Бала келәве» дип аталган. Бала келәве Келәү (Теләү) йоласының бер төрен тәшкил иткән.

Келәү йоласы, илаһи көчкә — тәңрегә яки тотемга табынып, аннан кешенең күп төрле теләкләре үтәлүен сорап, аерым бер урында, күбесенчә, су, елга, чишмә буенда башкарылган. Ритуал өчен корбан чалынган терлек яки кош-корт исеме белән: *каз келәве, үрдәк келәве, тавык келәве, сарык келәве, сыер келәве* дип аталган келәүләр булган. Тарихи-этнографик әдәбиятта бу төр келәүләрнең керәшен татарлары арасында саклануы күрсәтелә. И. А. Износков элек Лаеш өязенә кергән Ташкирмән авылында яшәүче керәшен татарларының Казанның беренче архиепископы Гурий заманында ук (1555 еллар) православие диненә көчләренә карамастан, мәҗүси йолаларны тотуы, һәр елны язын һәм җәен авыл уртасында сарык келәү һәм сыер келәү, ә чокырда ике елга бер мәртәбә көзен тавык келәү үткәрүләре турында яза.

Келәү йоласын үтәгәндә, сәдака итеп, борынгы акчаларны суга салу яки җиргә (йорт нигезенә) күмү гадәте дә булган. *«Келәү акчасы», «келәү акчасы тигән», «келәү тигән»* һ. б. кебек тәгъбирләр нәкъ менә шул турыда сөйлиләр.

Тагын шунысы игътибарга лаек: электә болгар-татарларда кулланылышта йөргән Кояш-Ай календаренда унберенче ай *келәү ае* дип аталган. Мәҗүси бабаларыбыз келәү аенда туган ир балаларга Келәш исеме кушкан булсалар кирәк.

Татар антропонимиконында баланың булуын, дөньяга килүен теләү-үтенү исемнәре, башлыча, тәңредән бала сорау белән мөнәсәбәтле рәвештә, «бала тууны теләү, сорау, үтенү» төшенчәсен турыдан-туры яки күчерелмә мәгънәдә белдерә торган боеру яки теләк тәгъбирлегендәге фигыльләр ярдәмендә формалашкан. Исемнәрнең әлеге лексик-семантик төркемен барлыкка китерүдә «ният-теләкне», «сорау-үтенүне», «кушу-чакыруны» белдерә торган *телә (келә), сора, истә, кесә, бир, бирче, бак, кара, кил, ту (туг)* кебек боерык яки теләк фигыль нигезле антроплексемалардан тыш, гарәби чыгышлы *морат* (теләк, максат, теләгән әйбер), *ният* (теләк, максат), фарсы генезислы *арзу* (теләк, омтылыш), *нияз* (ихтыяҗ; үтенү, ялвару, теләү) исем компонентлары да актив катнашкан.

*Телә* антрополексемасы яки аның төрләре катнашып ясалган «бала келәве»нә нисбәте исемнәрнең саны ике дистәдән артык: Теләбай, Теләбәк, Теләбикә, Теләгол, Теләк, Теләкәй, Теләч, Теләнче, Теләҗе, Теләгән, Теләнгән, Теләкбай, Теләкбирде, Телимбай, Теләш, Делиш, Деләш, Теләүбай, Телбәукәй, Теләүбирде, Теләүгилде, Теләүгол, Теләүкабул, Теләүле, Теләүмөхәммәт (Теләүмәт, Теләүмәмәт), Теләүшә (Теләүшаһтан), Келәш, Келәүле, Келәнче, Келәүшә, Келәвеш, Теләмеш (соңгысы кыргызларда әле дә кулланылышта йөри) һ. б.

Бу исемнәрнең кайберләре Казан татарларында Теләвлиев фамилиясендә (Казан шәһәренең 1565—1568 һәм 1646 елларда төзелгән сан алу кенәгәләрендә Тлевлеев фамилиясе бар), Себер татарларында Телимбаев, Урал татарларында Тляшев, Телешев (Телешев фамилиясе русларда да бар), татар-мишәрләрдә Делишев, Делешев, Кляшев һ. б. кебек фамилияләргә һәм Урта Идел-Урал регионында Келәш (Татарстанның Тәтеш, Башкортстанның Чишмә районнарындагы), Теләкәй (Татарстанның Актаныш, Башкортстанның Бүздәк һәм Илеш районнарындагы), Келәнче (Югары Ослан һәм Кама Тамагы районнарындагы), Келәвеш (Мамадыш районындагы), Теләнче (Сарман районындагы), Теләче һәм Теләҗе (Саба районындагы), Теләш (Башкорстанның Әбҗәлил һәм Мәчетле районнарындагы), Теләбай (Башкортстанның Күгәрчен райо-

нындагы), Келәүле (Куйбышев өлкәсе Келәүле районындагы) авыллары атамаларына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган.

Борынгы заманнарда тәңредән бала сорап ялваруга нисбәтле рәвештә турыдан-туры теләк-боерыкны белдерә торган *сора, үтә, үтен, истә, кесә, бир, бирче, бул, кил, ту* (*туг*) фигыльләренә нигезләнеп байтак кеше исемнәре ясалган: Соран (Суранов фамилиясендә сакланган), Сорачык (Югары Сорачык — Татарстанның Мөслим районындагы татар авылы атамасы), Соранбәк, Соранбай (Соранбаев, Суранбаев фамилиясе шушы исемнән. Кыргызларда Соорон, Сооранбек, Сооронбай исемнәре хәзер дә кулланылышта йөри), Җансорыйм (Апас районында Янсорыйм дигән керәшен авылы бар), Сорачык (Сорачыков ~ Сурачиков фамилиясендә сакланган), Сорапкол, Сораган (Себер татарлары һәм казахлар арасында әле хәзер дә Сораган дигән кеше исемнәре очрый. Башкорт шәҗәрәләрендә Сораган-бий, Сорак, Теләнчебай, Теләүкәй исемнәре урын ала). Үтәгелкәй исеме тәңредән бала сорап «бала келәве» башкарылганнан соң туган ир балага кушылган (бу исем Казанның 1565—1568 елларда төзелгән сан алу кенәгәсендә сакланган). Үтәмеш, Үтәморат, Үтәнияз, Үтенечтимер (кыскартылып әйтелеше Үтүч. Шуннан Казан татарларындагы Утучев фамилиясе ясалган), Бириш (Бирюшев фамилиясендә сакланган), Алпанбир (*алпан* «таза, баһадир, алып гәүдәле»+*бир;* Казан татарларында, мәсәлән, Татарстанның Балтач районында, Алпанбиров фамилиясендә сакланган), Бирчебай, Бирдебай, Бирдиеш, Ишбирде (Бирдишев, Ишбирдиев, Ишбирдин фамилияләрендә сакланган), Бирдеморат, Моратбирде, Бирдехан, Ханбирде, Бирдехуҗа, Хуҗабирде, Бирдеяр, Ярбирде (Бирдеяров, Ярбирдиев, Ярбирдин фамилияләрендә сакланган), Бирәхмәт (шуннан Бирәхмәтов фамилиясе ясалган), Бирмөхәммәт (Бирмөхәмматов фамилиясендә сакланган), Бирсенбай, Бирсенбәк, Бирсенхуҗа, Birҗан (Бирҗанов фамилиясендә сакланган. Бирҗанов фамилиясе русларда да бар); Тубай, Байту ~ Байтуг (Байтуков фамилиясендә сакланган), Тубикә, Тубәк, Туиш (татар-мишәрләрдә Туишев фамилиясендә сакланган. Туиш — хәзер Кукмарага кушылган татар авылы атамасы), Туган, Тугуш (татар-мишәрләрдә Тугашев, Тугушев фамилияләрендә сакланган, Исәнту ~ Исәнтуг; Тутулы, Тулыту, Байбул, Ишбул, Байбулды, Байбылсын, Ишбулды, Булдыиш (Булдыишев фамилиясендә сакланган), Ишбулсын, Тиңбул һ. б.

Борынгы төрки телдә *истә* сүзе «эзлә, телә» һәм *кусә* сүзе: 1. «телә»; 2. «сагын» мәгънәләрен белдерү өчен кулланылган. Әлеге боерык-теләк фигыльләргә нигезләнеп: Истәк, Иштәк (Башкортстанның Яңаул һәм Түбән өлкәсенең Вагай районында Иштәк дигән татар авыллары бар), Иштәкбай; Көсәмәк, Көсәмеш, Көсәбай, Көсәбәк, Көсәбикә, Көсәпкол, Көсәнәк һ. б. кебек борынгы исемнәребез барлыкка килгән.

Татар теленең урта диалектына караган Тау ягы сөйләшләрендә очрый торган «сине генә көсеп (теләп, көтеп) тора идек» тәгъбире, шул ук сөйләшләрдәге *көсәмче* — «йорттан-йортка йөрүче, үз өенә кайтып кермәүче, тәмле аш-су теләп, өмет итеп йөрүче кеше» һәм Минзәлә сөйләшендәге *көсәмәй* —«соранырга яратучы кеше» диалектизмнары борынгы төрки телдәге *кусә* (телә), *кусәмәк* (теләмәк) сүзләре белән бәйләнешле. Мәҗүси чуваш исемнәре арасында борынгы төрки *көсә* (телә) фигыленә мөнәсәбәтле: Көсә, Көсәкә, Көсәмәк, Көсәморза, Көсәнчек кебек исемнәрнең урын алуы да игътибарга лаек (Магницкий В. К., 1905). Татарларга гарәп теленнән кергән Саил, Саилә (сорaнучы) кебек кеше исемнәре дә — бала сорау, ходайдан бала көтү белән бәйләнешле йола исемнәр.

Составларында *кил* һәм *килде* антрополексемалары булган борынгы төрки кеше исемнәре шактый күп. Мәсәлән, В. К. Магницкий төзегән чуваш мәҗүси исемнәре тезмәсендә: Килбай, Килбарс, Килдаш, Килбей, Килсеней, Киләбей, Килбаш, Килдебәк, Килдеган (Килдехан.— *Г. С.*), Килдимир, Килдер, Килдерәк, Килдөрес, Килдеяр, Килдекәй, Килдиш, Килмурза, Килсарат, Килтияр, Килтуга, Килчебай, Килчей, Килша (Килшаһ.— *Г. С.*) һ. б. исемнәр бар.

Бу исемнәрдәге *кил* һәм *килде* компонентлары «ту, дөньяга кил; туды, дөньяга килде» дигән мәгънәләрне белдерә. Болар — ир баланың дөньяга килүен теләүгә (Байкил, Җанкил, Төзкил һ. б.) яки дөньяга килгәнлеген раслауга (Килдеураз, Ишкилде, Килдеиш, Килдеяр, Килдебәк, Килдебай, Таңкилде, Байкилде, Килдегол, Килдекуш, Килдемөхәммәт, Ханкилде, Уразкилде, Дәүләткилде, Сәеткилде, Теләүкилде һ. б.) мөнәсәбәтле йола исемнәр. Бу исемнәрнең кайберләренә нигезләнеп Байгилдиев, Байгильдин, Уразкилдиев, Уразкилдин, Хангилдин, Дәүләткилдиев, Килдеяров, Килдебеков, Килмурзаев, Килмурзин, Ишкилдиев, Ишкилдин, Килмәков (Килмяков, удмуртларда Кельмаков) һ. б. кебек фамилияләр ясалган.

Татарстан ойконимиясендә (торак пункт атамаларын-

да) *килде* компонентлы кеше исемнәре белән бә тәнешле: Гилдеево (Питрәч районы), Килдеево (Югары Ослан районы), Килдебәк (Саба районы), Килдеиш (Тәтеш районы), Килдураз (Буа районы) һ. б. авыл атамалары бар.

Борынгы төрки-татар кеше исемнәрендә *бак* һәм *кара* синонимдаш компонентлар —«бала бак», «бала кара», ә күчерелмә мәгънәдә «ту, дөньяга кил, пәйда бул», дигән боерыкны, кушуны таләп итүне, сорауны белдерү өчен хезмәт иткән. Мәсәлән, Алтын кара, Баш кара, Кулун кара, Кутадмыш кара, Түкәл кара исемнәре («Борынгы төрки сүзлек»); Алыпкара, Байкара, Җанкара (Сәгадәтгәрәй хан ярлыгы, 1504 ел), Ишкара, Кылычкара, Калкара (ягъни Миңлекара), Төзкара, Сөемкара, Кашкара (Татарстанның Кукмара районында Кашкара исемле рус, ә Төмән өлкәсе Төмән районында Каскара дигән татар авыллары бар) һ. б.

*Кара* фигыленең абсолют синонимы булган *бак* фигыле хәзерге вакытта да татар теленең көнбатыш диалекты сөйләшләрендә актив кулланылышта йөри. *Бак* сүзе иске татар телендә тагы да активрак булган булса кирәк. Байбак, Ишбак, Ишбага, Ишбакты, Төзбак, Төгәлбак, Уразбак, Уразбага (Урысбага — Татарстанның Зеленодольск районындагы татар авылы атамасы), Уразбакты, Айбак, Айбага, Айбакты, Ханбакты, Тиңбак һ. б. кебек тарихи-традицион исемнәребез шулай дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Ислам дине кабул ителгәннән соң, гарәби чыгышлы *морат, максат* һәм *ният*, фарсы чыгышлы *арзу, нияз* һәм *өмет* антрополексемаларына нигезләнеп ясалган һәм баланың дөньяга килүен, тууын теләүне белдерә торган байтак кына кеше исемнәре кулланылышка алынган. Шушы алынма антрополексемалар төрки-татар чыгышлы исем компонентлары белән кушылу нәтиҗәсендә, катнаш төзелешле кеше исемнәребез барлыкка килгән. Мәсәлән:

*морат* (теләк, максат, теләгән әйбер) антрополексемасы белән — Морат, Моратбай, Моратбакый, Моратбирде, Моратбәк, Моратгали, Моратнәби, Моратхан, Моратхуҗа, Моратша, Акморат, Байморат, Бикморат, Исәнморат, Ирморат, Ишморат, Нурморат, Хаҗиморат, Солтанморат, Шаһморат һ. б.;

*максат* (максат, теләк, омтылыш) антрополексемасы белән — Максат, Максуд;

*ният* (теләк, максат) антрополексемасы белән — Ният, Ниятбакый, Ниятбай, Ниятназар, Ниятша, Ишният һ. б.;

*арзу* (теләк, омтылыш) антрополексемасы белән — Ар-

зу (сирәк булса да, кыз балаларга да кушыла. Урал татарларында Арзуев, Арзыев фамилияләрендә сакланган), Арзубай, Арзубак, Арзубаш (руслардагы Арцыбашев фамилиясенең асылында, Н. А. Баскаков уйлаганча, Арты (к) баш кушаматы түгел, бәлки Арзубаш исеме ята), Арзубикә, Арзубәк, Арзудан, Арзухан, Арзуҗан һ. б.;

*нияз* (1. ихтыяҗ, үтенү, теләү; 2. бүләк) антропалексемасы белән: Нияз, Ниязия, Ниязбай, Ниязбәк, Ниязбикә, Ниязгол, Ниязгөл, Ниязгали, Ниязмөхәммәт, Ниязсолтан, Солтаннияз, Ātанияз, Ишнияз, Әхмәтнияз һ. б.;

*өмет* (өмид, теләк, омтылыш; бер нәрсәнең булуын көтеп тору) антрополексемасы белән: Өмет, Өметбай, Өметгәрәй, Өметгали, Өметкол, Өметхуҗа, Өметҗан; Өметбану, Өметбикә, Өметсылу һ. б.

## Баланың нәсел-ыруны дәвам иттерүче, ишәйтүче булуын теләү исемнәре

«Ише барның — ашы бар» ди татар халык мәкале. Ишле, үрчемле булу борынгы заманнарда нәсел-ыруның, кабиләнең көчле булуын, яшәүчәнлеген тәэмин иткән. Менә шуңа күрә яңа туган сабыйны нәсел чылбырының яңа бер буынын барлыкка китерүче итеп карау — бик табигый. Бу төр теләк исемнәр күп үрчем бирә торган хайван, кошкорт, үсемлек атамаларына һәм *күч, токым, нәсел, бау* (күчерелмә мәгънәдә «нәсел җебен дәвам иттерүче») кебек сүзләргә нигезләнеп ясалганнар.

Элекке заманнарда татарларда ир баланың ишле нәсел атасы булуын теләп Тәкә һәм аңа мәгънәдәш Кучкар (төрдәшләре Кучкарбай, Байкучкар, Кучкарбәк) исемнәре кушылган. Бу исемнәргә, монгол теленнән кергән Кусай, гарәп теленнән алынган Кәбиш (сарык, куй тәкәсе) исемнәре өстәлеп, синонимик исемнәр рәте барлыкка килгән. Бу рәтне төзүче кеше исемнәре хәзерге антропонимиконыбызда урын алмый, алар архаик исемнәргә әйләнгәннәр. Тәкәев (Такаев), Такин (Тякин), Кучкарев (Себер татарларында Качкуров), Байкучкаров, Кучкарбаев, Кучкарбеков, Кусаев, Кәбишев (Кабишев, Кябишев) кебек фамилияләребез әлеге исемнәрдән ясалган.

Татар-мишәрләрдә ир балага, ишле гаилә атасы булуын, нәсел чылбырын өзмичә дәвам иттерүен теләп, Кучат (татар теленең мишәр диалектында *кучат* —«әтәч»), Байкучат, Кучатбай, Кучатбәк исемнәре бирү гадәте булган. Бу исемнәр Кучатов, Байкучатов, Байгучатов, Кучатбаев, Кучатбеков фамилияләрендә сакланган.

Асылында ботаник термин яткан Кузак∼Куҗак (кузак, борчак кузагы) исеме дә ир баланың борчак кузагы эчендәге бөртекләр кебек ишле гаилә башлыгы булуын теләп кушылган. Татар-типтәрләрнең һәм Казан татарларының Кужак дигән авыл атамалары (Сарман районында Кужак атамасын йөртүче татар авылы бар), Кузаков, Кужаков фамилияләре шушы исемгә нисбәтле рәвештә барлыкка килгәннәр.

Борынгы төрки телдә *куч* сүзе «ил, гаилә, йорт, нәселыру, халык, төркем» мәгънәләрен белдергән, ә иске татар телендә «күченеп баручы ил, авыл (кабилә, төркем)» мәгънәсендә кулланылган. Ир балаларга ишле гаилә, күч атасы булуларын теләп, Күчбай, Күчбәк, Күчкилде, Күчбирде кебек исемнәр кушканнар. Күчбикә — ишле гаилә, күч анасы булуын теләп кызларга кушылган йола исем.

Иске татар телендә кулланылышта йөргән монгол чыгышлы Багатай исеме «балалы» (күчерелмә мәгънәдә «ир балалары күп булачак, ягъни «нәсел-ыруны ишле итәчәк») дигән төшенчә белдерә. Бу исем татар-мишәрләрдә Багатаев, Богатиев, Багатиев фамилияләрендә сакланган.

Электә татарлар төрки-татар чыгышлы Токым, Токымбай, Токымбәк, Токымбикә, гарәби чыгышлы Нәсел, Нәселбай, Нәсилә, фарсы чыгышлы Тәбар (Нәсел), Тәбәрле исемнәрен гаиләнең нәселне дәвам иттерергә тиешле бердәнбер ир яки кыз баласына биргәннәр. Болардан Токымов (Тукумов), Токымбаев, Токымбеков, Насилов (Насилов фамилиясе русларда да бар) фамилияләре ясалган. Гарәби Вәлид (Вәлит) исеме «нәсел-токымны дәвам иттерүче ир бала», Зөррия дигән хатын-кыз исеме «буын, нәсел-ыру, нәсел-токым» төшенчәсен белдерә.

Тарихи антропонимиконыбызда, ир баланың нәсел-ыру буыннарын бәйләүче булуын теләп, составларында *бау* сүзе булган Баубәк, Бауҗан, Бикбау, Бикбаулы исемнәре барлыкка килгән. Баубәк, Бауҗан исемнәре Себер татарларында Баубеков һәм Баучанов фамилияләрендә сакланган. Казан татарларында Бикбау исеменнән ясалган Бикбау, Бикбауов, Бикбов, Бикбаулов фамилияләре бар. Татарстанның Минзәлә районындагы бер татар авылы Бикбау исемен йөртә.

Бездә гарәпләрдән кергән Хәбил һәм Хәбилә исемнәре дә «бау» (күчерелмә мәгънәдә «нәсел җебен дәвам иттерүче») мәгънәсенә ия.

## Баланың матур булуын теләү исемнәре

Баланың матур, нурлы йөзле һәм якты күңелле булуын теләү — һәр халык өчен универсаль күренеш. Яңа туган сабыйга исем сайлаганда, шул теләкне мотив итеп алып, аны чибәрлекне, пакьлек-сафлыкны, яктылыкны белдерүче сүзләргә (антрополексемаларга) нигезләнеп ясалган исемнәр аша чагылдырганнар. Болгар-татар антропонимиясендә бу функцияне төрки чыгышлы *күрекле, күркәм, чибәр, матур, сылу, гүзәл, чута* (нур, якты), *йарык* (якты), *багду* (яктылык, нур), *айдын* (якты), *балкыш, ямь* антрополексемалары, гарәби чыгышлы *зариф* (чибәр), *җамал* (матурлык), *нур, һалә* (нурлы таж, балкыш), *нәфис* (күркәм, чибәр), фарсы чыгышлы *рушан* (нурлы, якты, яктыртучы), *фруз*~*фруза*( яктыртучы, нурландыручы, балкытучы), *зифа* һ. б. исем компонентлары башкарган.

Болгар-татарларда Күркәм (бик асыл, чибәр, гүзәл), Күреклебәнат (кызларның күреклесе), Күреклебикә кебек хатын-кыз исемнәре кулланылышта йөргән. Күреклебикә исеме Татарстанның Арча районы Иске Мәңгәр авылы зиратында XVI гасырда куелган болгар-татар кабер ташында бар. Казан губернасы буенча 1834 елда уздырылган Ревизские сказки материалларында бу исем элекке Лаеш өязенә караган Шәле авылында теркәлгән.

Урта гасырларда татарларда Матур, Матуркай, Чибәр, Чибәркәй кебек ир-ат исемнәре булган. Болардан Матуров, Матуркаев, Чибәрев, Чибәркәев кебек фамилияләр барлыкка килгән. Чибәр исеме, сирәк булса да, хәзер дә кыз балаларга кушыла.

Тарихи антропонимиконыбызда «сөйкемле, матур, көяз» мәгънәсенә ия булган Челеби дигән ир-ат исеме дә урын алган. Аның диалекталь варианты Чиләбедән Чиләбе шәһәре атамасы барлыкка килгән.

Болгар-татарларда *сылу* сүзе элек-электән хатын-кыз исеме (Сылу) булып йөргән һәм кушма төзелешле ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре ясаучы исем компоненты сыйфатында кулланылган: Сылубай, Сылубәк, Сылухан — ир-ат исемнәре; Айсылу, Байсылу, Миңсылу, Таңсылу, Тиңсылу, Сылубикә, Сылугөл, Гөлсылу, Шәмсесылу (Шәмсылу), Сылуйөз, Сылуназ, Сылуниса, Сылуханә, Сылуҗиһан, Җансылу — хатын-кыз исемнәре.

Тел галиме Ф. С. Фасеев «чибәр, күркәм, нәфис, асыл, бик матур, күзнең явын алырлык чибәр» мәгънәсенә ия булган *гүзәл* сүзе «күзнең (көньяк төрки телләрдә *гөз*~*гүз*) явын алырлык» дигән тәгъбирнең *көз алу*>*гөз алу*>

*гөзал>гөзәл>гүзәл* рәвешле кыскару-кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән, дип саный. Бу сүзгә нигезләнеп, шактый борынгы заманнарда ук Гүзәлбай, Гүзәлкәй, Гүзәлбәй, Гүзәлҗан кебек ир-ат, Гүзәл, Гүзәлбану, Гүзәлбикә, Гүзәлбәнат, Гүзәлгөл, Гүзәлия кебек хатын-кыз исемнәре ясалган. Гүзәл, Гүзәлия исемнәре — хәзер дә татарларда кыз балаларга бик еш кушыла торган исемнәр. Бу исемнәр гарәби чыгышлы Фирая, Бәдигъ-Бәдига, фарсы чыгышлы Рәгънә, Нәгыйзь — Нәгыйзә исемнәре белән синонимдаш.

Идел-Кама болгарларында «нур», «якты» мәгънәсенә ия булган Чутай дигән ир-ат исеме кулланылышта йөргән. Болгар каберташ язмаларында да Чутай исеме очрый (Хакимзянов Ф. С., 1978).

Бу мәҗүси болгар-татар исеме Татарстанның Балтач районында, Чутай дигән татар авылы атамасына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган. Республикабызның Апас һәм Лениногорск районнарында Чути (Чутай исеменең төрдәше) дигән татар авыллары бар. Карачай-балкарларда Чотай, Чоту (нур) исемнәре хәзер дә кулланылышта йөри. Казан өязенең 1602—1603 елларда төзелгән сан алу кенәгәсендә Четай Сюнчалиев исем-фамилиясе белән очрашабыз. Казан татарларында болгар-татарларның Чутай, Чутей, Чута исемнәреннән Чутаев, Четаев, Чутиев, Чутеев (соңгысы башкортларда да бар), Чутин фамилияләре ясалган. Четаев фамилиясе русларга да кергән.

Борынгы төрки телдә *йарык* сүзе «якты, балку, ялтырау, нур» мәгънәсен белдергән. Йарук тегин дигән исем һәм титулның кулланылышта йөрүе билгеле. Мәҗүси борынгы чуваш исемнәре Ярук, Ярука (Магницкий В. К., 1905) шул ук тамырдан. Себер татарлары телендә *йарык* сүзе хәзер дә «якты», «нур» мәгънәсендә кулланыла. Себер татарларының борынгы җырларында урын алган Ярука дигән хатын-кыз исеменең асылында да әлеге сүз ята. Болгар-татарларда Аййарык (ай яктысы), Аййар (ай нуры) дигән хатын-кыз исемнәре булган. Аййар исеме сирәк кенә хәзер дә очрый.

Борынгы төрки телдә *багду* сүзе дә «яктылык», «нур» төшенчәсен белдерү өчен хезмәт иткән. Шушы антрополексема катнашып Багдасар (яктылык, нур җыелмасы) дигән ир-ат исеме ясалган (бу исем Багдасаров фамилиясендә сакланган). Багдагөл (яктылык сибүче гөл, балкып утыручы чәчәк), Багданур (яктылык сибүче нур, балкып торучы нур), Нурбагда (нурлы яктылык сибүче) кебек хатын-кыз исемнәребез барлыкка килгән.

Борынгы төркиләрдә *айдын* сүзе «якты» төшенчәсен белдергән һәм шушы лексик берәмлеккә нигезләнеп Айдын дигән ир-ат исеме (бу исем Себер татарларында һәм русларда Айдинов фамилиясендә сакланган) һәм «ай нурына коендырылган бикә», «ай кебек балкучы бикә» мәгънәсенә ия булган хатын-кыз исеме Айдынбикә барлыкка килгән. Казахларда Айдын, Айжаркын (ай кебек якты нур чәчүче) дигән ир-ат Айдынбикә, Айкын (якты, ачык) кебек хатын-кыз исемнәре хәзер дә актив кулланылышта.

Болгар-татарларда Балкыш дигән хатын-кыз исеме борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Бу «якты», һәм «нурлы» исем бүгенге көндә дә актив кулланылыш алу өчен кирәкле булган барлык асыл сыйфатларга ия. Балкыш исеме безгә гарәпләрдән кергән Һалә һәм Ләмига исемнәре белән мәгънәдәш.

Болгар-татар телендә «матурлык, чибәрлек, хозурлык» мәгънәсенә ия булган *ямь* (диалекталь варианты *иләм)* сүзенә нигезләнеп: Ямьбакты (бу исемнән Ямбактин, Ямбахтин, Ямбухтин кебек фамилия ясалган. Ямьбакты — Татарстанның Куйбышев районындагы татар, Тәтеш районындагы рус авылы атамасы), Иләмбай (Иләмбаев, Илимбаев фамилияләрендә сакланган), Ямьбарс (татар-мишәрләрдә Ямбарсав фамилиясендә сакланган), Ямьбәк (Ямбиков, Ямбеков фамилиясендә сакланган), Ямькәй, Ямьморза (диалекталь варианты Яморза — Татарстанның Әгерҗе районындагы татар авылы атамасы), Ямьсубай, Ямьураз, Ямьшәех кебек ир-ат, Ямьзәвык, Ямьлихә (Ямь бирүче) дигән хатын-кыз исемнәребез барлыкка килгән.

Гарәби чыгышлы *зариф, зыя, җамал, вәсим, нәфис, җәмил, әҗме* һәм *нур* антрополексемалары катнашлыгында байтак кына ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре ясалган:

*зариф* (ягымлы, нәзакәтле, чибәр) антрополексемасы белән: Зариф — Зарифа; Зарифетдин, Зарифхан, Зарифҗан, Мөхәммәтзариф, Миңлезариф — Миңлезарифа (диалекталь вариантлары Минзариф — Минзарифа), Әхмәтзариф, Зарифулла һ. б.;

*зыя* (яктылык, белем яктысы) антрополексемасы белән: Зыя, Зыякамал, Зыямөхәммәт, Зыятдин — Зыятдинә, Зыяхан, Зыяәхмәт, Әхмәтзыя, Нурзыя, Мирзыя, Миңлезыя, Гөлзыя һ. б.;

*җамал* (матурлык, чибәрлек, гүзәллек, күркәмлек) антрополекмасы белән: Җамал — Җамалия; Җамалетдин (диалекталь вариантлары: Җамалый, Җамали, Җамай, Ямай, Ямаш, Ямал, Ямакай, Ямук һ. б.). Җамал компонентлы исемнәребезнең зур күпчелеген хатын-кыз исемнә-

ре тәшкил итүе бик табигый. Мәсәлән, Җамалниса, Айҗамал, Бибиҗамал, Бәдриҗамал, Гөлҗамал, Гайниҗамал, Маһиҗамал, Миңлеҗамал, Мәхбүбҗамал (диалекталь варианты Хупҗамал), Мәүлиҗамал, Нурҗамал, Сәхипҗамал, Хөсниҗамал, Әшрәфҗамал һ. б.;

*вәсим* (бик чибәр, сөйкемле, гүзәл) антрополексемасы белән: Вәсим — Вәсимә, Вәсимхан, Вәсимҗан, Вәсимбану, Бибивәсимә, Миңлевәсимә, Өммевәсимә һ. б.

*нәфис* (күркәм, чибәр) антрополексемасы белән: *Нәфис* — Нәфисә; Гөлнәфис, Гөлнәфисә, Бибинәфисә, Айнәфисә, Айнәфис һ. б.;

*җәмил —җәмилә* (матур, гүзәл, чибәр) антрополексемасы белән: Җәмил, Габделҗәмил, Мөхәммәтҗәмил; Җәмилә, Җәмиләбану, Җәмиләбикә, Бибиҗәмилә, Гөлҗәмилә һ. б.

*әҗме — әҗмал* (бик матур, бик чәбәр, бик күркәм) антрополекмасы белән: Әҗмегол (Әҗмеголов, Азмагулов фамилиясендә сакланган), Әҗмекәй (Тукай районында Әҗмекәй дигән татар авылы бар), Әҗмемөхәммәт (диалекталь вариантлары Әҗмәмәт, Әҗмәт, Әҗембәт. Болардан Әҗмемөхәммәтов, Әҗмәмәтов, Азмаматов, Әҗмәтов, Азматов, Азметов, Азмитов, Әҗембәтов — Азембетов фамилияләре ясалган. Әҗмәт — Татарстанның Актаныш районындагы татар авылы атамасы), Әҗмехан, Әҗмебикә һ. б.

Гарәби чыгышлы Баһир — Баһирә, Бәһия һәм башка күп кенә исемнәр «якты, нурлы; матур, асыл, гүзәл» мәгънәсенә ия.

Гарәп телендә «матур, гүзәл, күркәм» төшенчәсен белдерү өчен хезмәт итә торган сүзләр аеруча күп. Бер үк тамырга кайтып кала торган Хәсән, Хөсәен, Хөсни, Әхсән исемнәре һәм исем компонентлары да шул ук мәгънәгә ия.

*Нур* (яктылык нуры) һәм *нурлы* антрополексемалары катнашып ясалган ир-ат һәм хатын-кыз исемнәребез бик күп. Алар арасында: 1. Нур — Нура, Нургиз — Нургизә, Нургалим — Нургалимә, Нурсәгыйть — Нурсәгыйдә, Нурсәлим — Нурсәлимә, Нурсәет — Нурсәйдә, Нурхәниф — Нурхәнифә, Зиннур — Зиннура, Илнур — Илнура кебек парлы мәгънәдәш ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре дә; 2. Нуравшан, Нурвафа, Нурзадә, Нурсафа, Нуршат, Шаһинур, Хөснинур, Айнур, Җиһаннур кебек һәм ир-ат, һәм хатын-кыз исемнәре булып йөрүче исемнәр дә; 3. Нурбай, Нурбак, Нурбулат, Нурвил, Нурвәли, Нургази, Нургазиз, Нургафур, Нургата, Нургани, Нургали, Нурлыгали, Нур-

гаяз, Нуретдин, Нурулла, Галинур, Дәүләтнур, Фәннур, Исламнур, Хаҗинур, Әхмәтнур кебек ир-ат һәм 4. Нурбану, Нурбикә, Нурбиби, Бибинур, Шәмсенур, Нурзифа, Әлфинур, Нурия, Нурсылу, Нурлыбаян, Нурлыруй, Нурхәят, Нурчирә, Нурчәчәк, Нурбәнат, Чәчәкнур, Нуржиһан, Гөлнур, Фәүкънур (өстен нур) һ. б. кебек хатын-кыз исемнәребез дә бар.

Гарәп телендә *нур* тамырыннан Әннур — Әннүрә, Мөнәвәр — Мөнәвәрә (нурлы, якты; нур чәчеп торучы), Мөнәвәрбану, Мөнәвир («нурландыручы, яктыртучы»), Мөнир — Мөнирә (яктыртучы, якты йөзле, нурлы), Тәнвир — Тәнвирә («яктыру, нурландыру»), Әнвәр — Әнвәрә, Әнвәрия (бик нурлы, бик якты), Әнвәрбану, Әнвәргали, Әнвәредтин, Әнвәрулла, Әнвәрҗан һ. б. кебек исемнәр дә ясалган һәм урта гасырларда болгар-татарлар тарафыннан кулланылышка алынган.

Гарәби чыгышлы Шогаеп исеме дә «нурлы»! мәгънәсенә ия.

Фарсы чыгышлы *раушан*~*рушан* һәм *фруз*~*фруза* антрополексемалары катнашып түбәндәге ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре ясалган:

*раушан*~*рушан* (нур сибүче, нурлы, яктыртучы, якты) антрополекмасы белән: Раушан, Раушанә, Раушания, Рушания, Раушанелбәнат, Гөлраушан, Гөлрушан, Рушангөл, Миңлераушан — хатын-кыз исемнәре; Рушан — ир-ат һәм хатын-кыз исеме; Раушанбәк — ир-ат исеме һ. б.;

*фруз*~*фруза* (яктыртучы, нурландыручы, балкытучы) антрополекмасы белән: Фруз — Фруза, Илфруз — Илфруза; Фируз, Фирузшаһ, Фөрүзан (ир-ат исемнәре), Гөлфируз, Гөлфруз; Мәгъфируз, Диләфруз, Маһифруз (хатын-кыз исемнәре) һ. б.;

«Нур» һәм «яктылык» төшенчәсенә нисбәтле булган кеше исемнәре башка халыкларда да бар. Мәсәлән, рус телендә *луч* (нур) һәм *свет* (якты) антрополексемалары катнашып Лучезар, Светозар, Светислав, Светислава, Светлан, Светлана (соңгысы Бөек Октябрьдән соң татар исемнәре хәзинәсенә дә кабул ителгән) һ. б.— ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре; латин телендә Lux (иялек килешендә Lucis) — «яктылык», «нур чәчүче» антрополексемасына нигезләнеп, Лука, Лукий, Лукина, Лукия, Лукьян, Люций, Люция, Люцина һ. б. кебек ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре барлыкка килгәннәр.

## Баланың эти-әнисенә һәм туганнарына кадерле булуын белдерүче исемнәр

Ата-ана өчен баланың аерата кадерле, якын, үтә газиз, бик татлы, ләззәтле булуы «кадерлелек», «якынлык», «татлы-ләззәтлелек» төшенчәләрен туры яки күчерелмә мәгънәсендә белдерә торган сүзләрнең борынгы заманнарда ук төрле халыкларда кеше исеме итеп кулланылуына китергән.

Борынгы заманнарда ук ата-ана өчен баланың кадерле, татлы-ләззәтле, бик якын булуын белдерә торган Татлы һәм Тәмле исемнәре барлыкка килгән. Болгар-татарларда Татык (татык; татлы-тәмле), Татый (татый, татлы-тәмле) исемнәре дә кулланылышта йөргән. Тәмле исеменең Тәмте формасы (биредә төрки телләр өчен хас булган *л*~*т* тартыклары күчеше белән очрашабыз) Идел-Кама болгарларында шактый киң таралыш алган булган. Татарстанның Тау ягындагы борынгы татар авылларыннан берсе булган Мулла иле авылына (хәзерге Зеленодольск районында) Болгардан килеп нигез салучы Муллагол белән бергә Шәехби исемле кеше дә булган. Шәехбинең атасы Тәмте дигән кеше Хытаи-Әлболгари тәхәллүсен йөрткән (Насыйри К., 1975). Болгарларның Тәмте исеме, республикабызның Саба районында Тәмте-Мәтәскә, Төрек-Тәмте дигән татар авыллары атамасына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган. С. М. Шпилевский әлеге авыллар атамасының килеп чыгышы болгарларның *тәмтез* этнонимына (тәмтез кабиләсе исеменә) нисбәтле дип карый. Шулай булганда да, тәмтез кабиләсе исеменең асылында Тәмте (тәмле) дигән борынгы төрки-болгар кеше исеме ята. Бу этноним Тәмте исеменә күплек кушымчасы -*з* кушылу юлы белән ясалган: *тәмтез*, ягъни «тәмтеләр», «тәмтенекеләр» дигән мәгънәгә ия.

Борынгы болгар-татар исеме Мәмил дә «тәмле-татлы» исемнәр рәтенә керә. Бу исем «мәмиле», ягъни тәмле, татлы мәгънәсендә. XIII йөздә куелган бер болгар кабер ташында Мәмил исеме бар. Ф. С. Хәкимҗанов бу исемне Мәмли (туп-тулы, күчерелмә мәгънәдә, тулы бәхетле) рәвешле укый. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында (поэма XIII йөз башында язылган) Йосыфның төпчек улы Мәмил исемен йөртә.

Борынгы төрки һәм Идел-Кама болгарлары телендә *сөчүг* сүзе «баллы ширбәт; «баллы су» дигән татлы эчемлек атамасы булып йөргән. Шушы сүзгә нигезләнеп Сө-

чүг (татлы бала) дигән ир-ат исеме ясалган. Бу исем Казан татарларында Сычугов фамилиясендә сакланган.

Борынгы исемнәребездән берсе — Тәмче (тәмле; тәм бирүче). Бу исемнең төрдәше Дәмши. Тәмче исеме Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар кузгалышы белән бәйләнешле татарча документларда бар. Дәмши формасыннан ясалган Дәмшиев фамилиясе Казан татарларында (мәсәлән, Питрәч районы Шәле авылында) очрый.

Борынгы төрки-татар Азалык исеме «өзелеп ярата торган кадерле (бала)» дигән мәгънәгә ия. Ул Татарстанның Сарман районында Азалак дигән татар авылы атамасында безнең көннәргәчә сакланган. Ардак исеме дә «кадер, кадерле» мәгънәсенә ия. Бу исем татар-мишәрләрдә Ардаков фамилиясендә урын ала.

«Каймак» дигән мәгънә белдерә торган сүзләр, күчерелмә мәгънәдә «ләззәтле бала» төшенчәсен аңлаткан хәлдә, борынгы заманнарда ук төрле халыкларда кеше исеме итеп кулланылган. Борынгы болгар һәм аргу телләрендә «каймак», «сөт өсте» мәгънәсендә йөргән *канак* сүзеннән Идел-Кама болгарларында Канак исеме барлыкка килгән. Бу сүз М. Кашгари сүзлегендә (XI йөз) теркәлгән. Исем буларак ул Татарстаннның Зеленодольск районы Мулла иле авылында унбиш семьяны үз эченә алган Канак нәсел-ыру кушаматына әверелгән. Әлеге нәсел вәкилләренең күбесе Канаков фамилиясен йөртә. Мулла иленең Канак нәселе семьялары күп булып утырган урамнарыннан берсе Канак җыены яки Канак урамы дип атала. Алабуга районында Канак дигән татар-рус авылы бар.

Удмуртча «каймак», «сөт өсте» мәгънәсен белдерә торган *нокы* сүзеннән борынгы удмурт исеме Нокы ясалган. Славяннарда Сметана дигән исем булган. Шуннан руслардагы Сметанин, чехлардагы Сметана фамилияләре барлыкка килгән. Азәрбайҗаннарда Гаймак (каймак) хатын-кыз исеме булып хәзер дә кулланыла, ә гагаузларда Каймакчы фамилиясе бар. Канак исеме Идел-Кама болгарларыннан удмурт теленә дә кулланылышка алынган.

Татар антропонимиконында ата-ана өчен баланың татлы, тәмле-ләззәтле булуын белдерүче *бал, баллы* компонентлы кеше исемнәре дә аз түгел: Балбәк (татар-мишәрләрдә Балбәков ~ Балбеков фамилиясендә сакланган), Балбикә (бу исем мариларга да кергән), Балкай (Казан татарларында Балкаев фамилиясе бар), Баллыбай, Баллыбикә, Баллыбәк һ. б.

Татарларга гарәплярдән алынган Әсал (бал), фарсы

теленнән кергән Кандар (шикәрле; татлы), Шәкәр (шикәр), Ширин («баллы; татлы-ләззәтле») кебек ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре, Ширинбану, Ширинзадә дигән хатын-кыз исемнәре әлеге антропонимик төркемне тагын да баета төшкән.

Кыпчакларның Казан татарлары составына кергән бер кабиләсе ширин кабиләсе дип аталган. Касыйм татарларында Ширинский фамилиясе дә Ширин исеменнән ясалган. Ширинский фамилиясе русларда да бар (Баскаков Н. А., 1979).

Баланың эти-әнисенә, туганнарына татлы-ләззәтле, кадерле һәм якын булуын белдерүче исемнәр төркеменә урта гасырларда гарәплардән кергән Ләзиз — Ләзизә (татлы, ләззәтле), Ләззәт (тәм, татлылык, ләззәт), Ләззәтелбәнат, Ләззәтелниса, Ләззәтелдөнья, Шәһия, Дания (якын), Талия (якын, зәвыклы), Кариб-Карибә (якын, кардәш), фарсы чыгышлы Нәзил-Нәзилә, Һуд (якын, үз), Яния (кадерле, сөйкемле), Әнгам — Әнгамә (нигъмәт, ләззәт) исемнәре дә өстәлгән.

Гарәби чыгышлы *кадер* (кадер-хөрмәт, бәя-дәрәҗә), *газиз* (бик кадерле, кыйммәтле; хөрмәтле, данлы), *гыйззәт* (кадер-хөрмәт, күңелгә якынлык), *гыйззел* (хөрмәт, дан), *хөрмәт* (кадерләү, кадер; ихтирам, хөрмәт), *шәриф* (хөрмәтле), *шәрәф* (кадер, хөрмәт, дан) антрополексемалары катнашында байтак кына ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре барлыкка килгән. Мәсәлән, Кадер (синонимнары Газиз, Гыйззәт, Хөрмәт, Шәрәф ~ Шәрәп), Кадербай (синонимы Гыйззәтбай, Хөрмәтбай), Кадербирде, Кадербәк (синонимы Газизбәк), Кадергали (диалекталь варианты Кадерали; синонимнары Хөрмәтгали, Шәрәфгали), Кадергол (синонимнары Шәрифкол, Шәрәфкол), Кадерниса (синонимнары Гыйззелниса, Шәрифниса), Кадриҗиһан, Гыйззелхәят, Бибигазизә, Бибишәрифә, Бибишәрәф, Өммегазизә, Өммешәрифә һ. б.

### Бала тууга эти-әнисенең һәм кардәшләренең сөенү-шатлану хисләрен белдерүче исемнәр

Татар антропонимиконында бала тууга ата-ананың һәм туган-кардәшләренең сөенү-шатлану хисләрен белдергән исемнәр шактый күп һәм алар, барысы бергә, аерым бер антропонимик-семантик төркем тәшкил итәләр.

Гаиләдә ир бала тууга ата-ананың һәм кардәшләренең сөенү-шатлану хисләрен чагылдырган Сөендек, Шатландык, Багыныч ~ Багыныш, Куаныч, Сөенеч, Юаныч, Йо-

гыныч кебек синонимдаш исемнәребез борынгы заманнардан ук барлыкка килгәннәр. *Куаныч* сүзе катнашып Куанычбай, Куанычбәк, Куанычбикә, Куанычсылу дигән кушма төзелешле кеше исемнәре ясалган. Гарәплардән кергән Тәгъзия дигән хатын-кыз исеме дә «юаныч» мәгънәсенә ия.

Бу төркемгә кергән кеше исемнәренең зур күпчелеге *сөенеч, сөен (сөенү),* фарсы чыгышлы *шат* (шат булу, шатлану, сөенү) һәм гарәби чыгышлы *фарих~фәрхе~фәрхи* (шат, шат күңелле, шатлык; шатлыклы, куанычлы, сөенечле), сорур (шатлык, куаныч, сөенеч) антрополексемалары катнашып ясалган:

*сөен (сөенү), сөенеч* антрополексемалары белән — Сөен, Сөем, Сөембай, Сөембикә, Сөенгол, Сөенәй (татар-мишәрләрдә Суюняев, Суняев, Сунаев фамилияләрендә сакланган), Сөеч (Сөечев, Суючев фамилияләрендә сакланган), Сөенечбай, Сөенечлебай (Себер татарларында Сөенечлебаев фамилиясендә сакланган), Сөенечбәк, Сөенечгали (диалекталь вариантлары Сөенечали, Сүнчәләй, Сүнчәли; Сүнчәләй — Татарстанның Зеленодольск районындагы татар, Сүнчәле — Аксубай районындагы чуваш авыллары атамасы), Сөенечкәй, Сөенечтимер; Сөенечбикә, Сөенечбану, Сөенечҗамал, Сөенечсылу һ. б.;

*шат (шатлык)* антрополексемасы белән — Шади — Шадия( шатлык, сөенеч), Шат (ата-ананың яки баланың үзенең шат булуы); Бикшат, Шатгали, Шатлык, Шатморат, Шатморза, Шатрух, Рухшат, Рушат; Шатсолтан (бу исем XIX гасырда Казан татарларында һәм ир-ат, һәм хатын-кыз исеме булып кулланылган), Шатҗан, Дилшат, Зөлшат, Илшат (ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре); Айшат, Гөлшат, Шатгөл, Гәүһәршат, Исмешат, Чәчкәшат (хатын-кыз исемнәре) һ. б.;

*фарих~фәрхе~фәрхи* антрополексемалары белән — Фарих, Фәррах, Фәррахетдин, Фәрух, Фәрхезадә, Фәрхерахман, Фәрхетдин, Фәрхи, Фәрхирәхим, Фәрхиулла~Фәрхулла, Фәрхиәхмәт, Фәрәхшат~Фәршат, Фәрәхи, Фәрәхетдин, Фәргать; Фариха~Фәриха, Фәрхениса, Фәрхеруй, Фәрхия, Фәрхизоха, Фәрхизә, Фәрхикамал, Фәрхиназ, Фәрхинур, Фәрхисорур, Фәрхисылу, Фәрхиәсма, Фәрхиҗамал, Фәрхиҗиһан, Фәрхунә, Фәрәнгиз һ. б.;

*сорур* антрополексемасы белән — Сорур, Сорурбәнат, Сорурвафа, Сорурҗиһан, Сoруретдин, Сорурҗан һ. б.

Бөек Октябрьдән соң татар антропонимиконының әлеге төркеменә рус теленнән кергән Рада, Радана, Радан, Радик, Радил исемнәре өстәлде.

## Гаиләдә баланың көтеп алынуын яки көтеп алынмавын белдерүче исемнәр

Татар исемнәре хәзинәсендә гаиләдә баланың көтеп алынуын яки, киресенчә, көтеп алынмавын чагылдырган кеше исемнәре артык күп түгел. Шулай да алар, этнографик-лингвистик яссылыктан караганда, үзләренә аерым бер семантик төркем тәшкил итәләр.

Болгар-татарларда гаиләдә баланың көтеп алынуын белдерүче исемнәр *көсә* (көт), *көсәп* (көтеп), *көт, көтеп, сагын, сагындык, тансык* сүзләре катнашып формалашканнар.

Борынгы төрки телдә *күсә* сүзенең «теләү», «сагын» мәгънәләрен белдерүе һәм шул мәгънәләргә нигезләнеп ясалган кеше исемнәре турында сүз алып барган идек инде. Иске татар телендә *көсә* сүзе «көт», *көсәп* фигыле «көтеп», *көсәгән* сүзе «көткән» мәгънәләрен дә белдергән. Бу сүзләрнең шушы мәгънәләренә нигезләнеп Көсәбай, Көсәбәк, Көсәбикә, Көсәмеш, Көсәкәй, Көсәпкол, Көсәгән һ. б. кебек исемнәр барлыкка килгән. Башкортларда Көсәпкол, Көсәмеш исемнәре хәзер дә кулланылышта йөри (Кусимова Т. Х., 1982).

*Көт, көтеп* сүзләренә нигезләнеп Көтек (көтеп алынган ир бала; диалекталь вариантлары Көти, Көтеш. Көтек — Татарстанның Арча районындагы татар авылы атамасы), Көтем (көтем, көтеп алынган ир бала; Себер һәм Урал татарларында Кутумов фамилиясендә сакланган), Көтепалдык, Көтепалдым, Көтепбай, Көтепбәк, Көтепбикә исемнәре барлыкка килгән.

*Сагын* (сагыну, көтеп алу) сүзе катнашып Сагынбай, Сагынбәк, Сагынбикә, Сагындык (Сагындыков фамилиясендә сакланган), Сагынтай кебек кеше исемнәре ясалган.

*Тансык* (тансыклау; теләп-көтеп алу) антрополексемасына нигезләнеп Тансык, Тансыкбай (Тансыкбаев фамилиясендә сакланган), Тансыкбәк, Тансыкхуҗа кебек ир-ат; Тансыкбикә, Тансыкбану, Тансыкбиби, Тансыксылу һ. б. дигән хатын-кыз исемнәре барлыкка килгән. Гарәби чыгышлы Интизар исеме дә «зарыгып көтеп алынган» дигән мәгънәгә ия.

Төрки халыкларда, шул исәптән татарларда, гаиләдә баланың көтеп алынмавын, кирәксез һәм артык булуын белдерүче борынгы кеше исемнәрендә *артык* сүзе катнаша. Артык (артык, кирәксез ир бала), Артыкбай, Артыккай (татар-мишәрләрдә Артукаев фамилиясендә сакланган), Артыкбәк, Артукач (татар-мишәрләрдә Артукачев

фамилиясендә сакланган), Артыкбикә (кирәксез, артык кыз бала). Мирсәй Әмирнең «Агыйдел» повестеның төп героинясы башкорт кызы Артыкбикә исеменең асылында әнә шушы мотив ята.

Төрки телләрдә *артык* антрополексемасының күп мәгънәле булуын да әйтеп китү урынлы булыр. Бу сүзнең, әлеге мәгънәсеннән тыш, казах телендә «бар нәрсәдән дә артык, кадерле» мәгънәсе дә бар. Т. Җанузаков казах телендәге Артык исеме «бар нәрсәдән дә артык, кадерле» мәгънәсенә ия дип аңлата. Үзбәкләр Артык, Артыкбай исемнәрен берәр әгъзасы артык булып туган (күбесенчә кулы яки аягында алты бармак булган) ир балага кушалар.

## Баланың укымышлы, галим булуын теләү исемнәре

Кешенең белемле, укымышлы, галим булуы элек-электән үк күркәм сыйфат, дан-дәрәҗә булып саналган. «Белемле», «хәким» мәгънәләрен белдерү өчен — *билге*, «белем», «акыл», «аң» төшенчәләрен аңлату өчен *билиг* сүзләре кулланылышта йөргән һәм бу сүзләр катнашып Билге бег, Билге чикшән, Билге каган һ. б. кебек ир-ат һәм Илбилге дигән хатын-кыз (Билге каганның әнисе) исемнәре ясалган.

Борынгы төрки телдә *бадак* сүзе «зур белемле» төшенчәсен белдергән һәм, шул сүзгә нигезләнеп, Бадак, Бадакша(һ), Бадакшан (зур белемле, шанлы, мактаулы) исемнәре ясалган. Болардан Бадаков, Бадакшин, Бадакшинов, Бадакшанов фамилияләре барлыкка килгән.

Иске татар телендә *белем, белек* сүзләре катнашында Белем, Белембай (бу исем Свердловск өлкәсе Беренче май районындагы поселок атамасында сакланган), Белембәк, Белек (бу исем XVI—XVII йөзләрдә Казан татарларында актив кулланылышка ия булган) исемнәре барлыкка килгән. Белем сүзенә *-чәк* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган Белемчәк исеме болгар каберташ язмаларында бар.

Татар антропонимиконында баланың укымышлы, галим булуын теләү исемнәренең күбесе гарәби чыгышлы *галим* (белемле, укымышлы, галим), *гыйлем* (аң-белем, гыйлем), *галләм* (зур укымышлы, бөтенесен белүче; атаклы белгеч, галим), *гариф* (белүче, танучы, хәбәрдар; укымышлы, акыл иясе), *фазыл* (белемле, галим, талант иясе), *фән, хәким*

(белем, фикер иясе) антополексемаларына нигезләнеп барлыкка килгәннәр:

*галим* антрополексемасы белән — Галим, Галимбай, Галимбәк (Алимбәк), Галимдар, Галимнур, Галимулла, Галимхан, Галимхуҗа, Муллагалим, Миңлегалим, Мөхәммәтгалим, Миргалим, Нургалим, Шәмсегалим, Әхмәтгалим; Галимә, Галимәбану, Галимәбикә, Галимәнур, Бибигалимә, Нургалимә, Шәмсегалимә, Өммегалимә һ. б.;

*гыйлем* антрополексемасы белән — Гыйлем (синонимнары Белем, Фән), Гыйлембай, Гыйлембәк, Гыйлемгали, Гыйлемгәрәй, Гыйлемдар, Гыйлемзат, Гыйлемхан, Гыйлемша, Гыйлемьяр, Гыйлемҗан, Гыйльми, Гыйльмегали, Гыйльмезаһит, Гыйльметдин; Гыйльмия, Гыйльмебаян, Гыйльмевафа, Гыйльмегаян, Гыйльмезадә, Гыйльмезаһидә, Гыйльмикамал, Гыйльминаза, Гыйльменаһар, Гыйльмениса, Гыйльминур, Гыйльменәфис, Гыйльмеруй, Гыйльмесафа, Гыйльмесылу, Гыйльмехәят, Гыйльминаз, Гыйльмисара, Гыйльмисорур, Гыйльмиәсма, Гыйльмиҗамал, Гыйльмиҗиһан һ. б.;

*галләм* антрополексемасы белән — Галләм, Галләметдин, Галләмхан, Галләмша, Миргаллләм, Миңлегалләм, Муллагалләм, Мирзагалләм, Муллагалләм, Мирзагалләм, Нургалләм, Садрыйгалләм, Фазылгалләм, Хөснегалләм, Шәмсегалләм, Шәйхегалләм; Галләмә, Галләмия, Өммегалләмә һ. б.;

*гариф* антрополексемасы белән — Гариф, Гарифбай, Гарифбәк (Арифбәк), Гарифетдин, Гарифулла, Гарифхан, Гарифҗан, Мөхәммәтгариф, Сәетгариф, Шәмсегариф, Әхмәтгариф; Гарифә, Гарифәбану, Гарифәбикә, Бибигарифә, Өммегарифә һ. б.;

*фазыл* антрополексемасы белән — Фазыл, Фазылбай, Фазылбәк, Фазылгәрәй, Фазылнәкый, Фазылхан, Фазылъяр, Фазылҗан, Мирзафазыл, Миңлефазыл, Мөхәммәтфазыл, Әхмәтфазыл; Фазилә, Бибифазилә, Миңлефазилә, Өммефазилә һ. б.;

*фән* антрополексемасы белән — фән (синонимнары Белем, Гыйлем), Фәнгиз, Фәнгыйль, Фәндар, Фәндил, Фәндүс, Фәндәм, Фәнзаман, Фәнзил, Фәнзур (зур фән), Фәнзирәк (тордәше Фәнзир), Фәнил, Зуфөнүн (фәннәр иясе), Фәнир, Фәнит, Фәнияр, Фәнияз, Фәннур, Фәньяз, Фәнәви, Фәнәвил, Фәнгизә, Фәндария, Фәндидә, Фәндилә, Фәндүсә, Фәндәсә, Фәнзилә, Фәнзия, Фәнзә, Фәнзура, Фәнилә, Фәнисә, Фәния, Фәннура, Фәнсөя һ. б.

*хәким* антрополексемасы белән — Хәким, Хәкимбай, Хәкимбәк, Хәкиметдин, Хәкимзадә, Хәкимулла, Хәкимхан,

Хәкимъяр, Хәкимҗан, Миңлехәким, Мөхәммәтхәким, Нурхәким, Әхмәтхәким; Хәкимә, Хәкимәбану, Хәкимәбикә, Бибихәкимә, Шәмсехәкимә, Өммехәкимә һ. б.

Фарсы чыгышлы Даниш~Даныш исеме дә «белем, фән» мәгънәсенә ия һәм ул татар антропонимиконында Белем, Гыйлем, Фән исемнәре белән бер синонимик рәт төзи. Даниш исеменең ясалганнары Данис, Данисә. Бу исемнәр Урал татарларында, Татарстанның көнчыгыш һәм Казан арты районнарында шактый киң таралышка ия. Даныш — Татарстанның Кама Тамагы районындагы татар авылы атамасы.

Фарсылардан кергән Дана, Фәрзанә, Фәрзания дигән хатын-кыз исемнәре дә «галим, белемле, укымышлы» мәгънәсен белдерәләр.

## Баланың һөнәр иясе булуын теләү исемнәре

Баланың үскәч берәр төрле кәсеп-һөнәр иясе булуын теләү мотивыннан чыгып кушылган исемнәр дөньядагы барлык халыкларның тарихи антропонимиконына да хас.

Төрки халыкларда кәсеп-һөнәргә нисбәтле кеше исемнәре төркеме, кешелек җәмгыятенең үсеш-эволюциясенә мөнәсәбәтле рәвештә, борынгы һөнәр атамаларыннан башланып, тарих дәвамында бер-берсен алмаштырган икътисади формацияләрдә туган яңа кәсеп-һөнәр атамаларына нигезләнгән исемнәр белән даими тулылана барган.

Билгеле булганча, иң борынгы кәсепләр — аучылык, терлекчелек һәм балыкчылык. Кәсеп-һөнәргә нисбәтле борынгы төрки-татар кеше исемнәре кәсеп-һөнәр атамаларына *-чы, -че* кушымчалары кушылып ясалганнар.

Иске татар телендә *ау (аң)* сүзенең синонимы булып *сунар* сүзе йөргән. Сунар сүзенә *-чы* кушымчасы ялганып, кешенең борынгы һөнәрен белдерүче Сунарчы исеме барлыкка килгән. Бу исем Аңчы (аучы) исеме белән синонимдаш. Бездә Сунарчин, Сунарчиев кебек фамилияләр очрый. Сунар сүзенә, кол һәм шаһ титуллары ялганып, Сунаргол (аучы кол), Сунарша (сунар, ау шаһы, хуҗасы) дигән борынгы исемнәребез ясалган. Бу исемнәр Сунарголов, Сунаршин, Сунаршиев фамилияләрендә сакланганнар. Башкортларда Сунаргол исеме хәзер дә кулланылышта йөри (Кусимова Т. Х., 1982.).

Борынгы төрки телдә *эгэр* сүзе «ау эте, бурзай» мәгънәсендә кулланылган. Хәзерге төрки телләрдән татар телендә *әгәр, әкәр, икәр,* кумык телендә *әгәр* — «бурзай», шор телендә *агар* — «ау эте», бараба татарлары телендә

*игәр* — «ау эте», чуваш телендә *акар йытти* — «бурзай, ау эте», мадьяр телендә *агар* — «бурзай, ау эте» һ. б. *Әгер* сүзенә профессия белдерүче *-җе (-че)* кушымчасы ялгану юлы белән «ау этен өйрәтүче, ау этләре белән эш итүче» дигән мәгънәгә ия булган борынгы Әгерҗе исеме ясалган. Татарстандагы Әгерҗе шәһәре атамасының мәгънәсен өлкән яшьтәгеләр: «Безнең Әгерҗе шәһәре атамасының килеп чыгышы монда килеп утырган ике бертуганның берсе Әгерҗе исеме булудан»,— дип аңлаталар. Әгерҗе авылының (хәзерге Әгерҗе шәһәре.— *Г. С.*) Казан ханлыгы чорында да булуы мәгълүм. Азнакай районында да Әгерҗе дигән татар авылы бар.

Иске татар телендә кулланылышта йөргән Аючы исеменең асылында *аючы* (аю аулаучы яки аю өйрәтүче, биетүче) дигән кәсеп атамасы ята. Аючы исеме татар-мишәрләрдә Аючин фамилиясендә сакланган. Башкортларда аючы дигән ыруг бар.

Тарихи антропонимиконыбызда терлекчелеккә нисбәтле рәвештә Елкычы (ат асраучы, ат караучы), Куйчы (куй сарыклары асраучы), Куйчыбай (бу исем казахларда әле дә кулланылышта йөри), Тайчы (тайлар караучы, Башкортларда тайчы ыругы бар. Омск өлкәсе Тевриз районындагы бер Себер татарлары авылы Тайчы исемен йөртә. Шушы исемнән Казан татарларында һәм татар-мишәрләрдә Тайчин, Тайсин, Тайсинов фамилияләре ясалган) һ. б. кебек борынгы исемнәр урын алган. Печәнче исеме дә ир баланың терлекчелек белән бәйләнешле кәсеп-һөнәр иясе булуын теләүгә нигезләнә. Башкортларда бу исемнән Песәншин фамилиясе ясалган.

Балыкчылык кәсебенә нисбәтле рәвештә борынгы заманнарда ук Балыкчы исеме барлыкка килгән. Татарстанның Апас районында Болын-Балыкчы һәм Шәм-Балыкчы дигән татар авыллары бар. Казан ханлыгында Нугай юлы өстендә Балыкчы дигән татар авылы булган. Башкортларның бер ыругы балыкчы исемен йөртә.

Игенчелек һөнәренә нисбәтле рәвештә, Сабанчы, Сукачы, Уракчы (урак уручы), Ындырчы (болгарларның бәрәдҗ ыруг шәҗәрәсендә Ындырчы исеме бар) һ. б. кебек борынгы исемнәребез барлыкка килгәннәр. Сабанчы исеме Казан татарларында һәм керәшеннәрдә Сабанчин һәм Сабанчиев фамилиясендә сакланган. Русларда да шушы исемнән ясалган Сабанчеев фамилиясе бар. Уракчы исеменнән татарларда — Уракчин, Уракчаев, Уракчиев, башкортларда — Ураксин, русларда Уракчиев, Аракчиев, Аракчеев фамилияләре ясалган. Уракчы — Татарстанның

Чистай районындагы татар авылы атамасы. Казанның Киров районына карый торган Аракчино поселогының атамасы да Уракчы дигән борынгы болгар-татар исеменнән барлыкка килгән. Казан ханлыгында Нугай юлында Уракчы (Урахчы) дигән татар авылы булган. Сукачы исеме Сукачин, Сукачиев фамилияләрендә сакланган. Татарстанның Апас районында асылларында борынгы болгар-татар кеше исемнәре яткан Югары Ындырчы дигән татар авылы һәм Рус Ындырчысы авылы бар.

Болгар-татарларда урманчылык шөгыленә мөнәсәбәтле рәвештә Урманчы, Юкәче, Карамачы һ. б. кебек кеше исемнәре ясалган. Болардан Урманче, Урманчиев, Юкачиев, Юкачев (соңгысы керәшен татарларында), Карамачиев кебек фамилияләребез барлыкка килгән.

Хәрби хезмәткә караган Чирүче (иске татар телендә *чирү* — «гаскәр»), Тупчи (туп атучы, артиллерист), Тупчибаш (тупчылар башлыгы) һ. б. кебек кеше исемнәре мәйданга килгән. Болгар-татарларның Чирүче исеме республикабызның Зеленодольск районында, Чирүче дигән татар авылы атамасына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган. Тупчи һәм Тупчибаш исемнәре татарларда һәм азәрбайҗаннарда Тупчиев, Тупчибашев, Топчибашев фамилияләрендә сакланган. Топчий, Топчиев фамилияләре русларда да бар.

Илчелек хезмәтен белдерүче *илче* термины катнашында Илче, Илчебай, Илчебәк, Илчегол; Илчебикә, Илчегөл исемнәре ясалган.

Идел буе болгарларында тимерчелек, алтын-көмешчелек (ювелирлык) эшләре шактый алга киткән булган. Тимерчеләр сөңгеләр, уклар, кистәннәр, балта-пычаклар, кольчугалар (көбә күлмәкләр) һ. б. хәрби һәм хуҗалык кораллары җитештергәннәр. Металл эшкәртү, металлардан төрле әйберләр ясау һөнәре атамаларына (профессионализмнарга) нигезләнеп, болгар-татарларда Алтынчы (алтынчы), Көмешче (көмешче), Бакырчы, Көбәче( кольчугалар — тимер киемнәр ясаучы һ. б.) кебек кеше исемнәре ясалган.

Бакырчы исеме монголларның XIII гасырда язылган «Алтын белек» китабында Бахарчжи рәвешле бирелгән. Казан шәһәренең XVI—XVII йөзләрдә төзелгән сан алу кенәгәләрендә Бакырчы исеме бар. Бакырчы — Татарстанның Апас, Зеленодольск һәм Тәтеш районнарындагы татар авыллары атамасы.

Республикабызның Питрәч районындагы Кибәче, Саба районындагы Олы Кибәче һәм Кече Кибәче дигән татар

авыллары атамаларының асылында кибәче (тимер күлмәкләр ясаучы) профессиясен белдерүче Кибәче исеме ята. Н. И. Золотницкий Казан татарлары телендә *көбә* сүзенең «вак боҗралардан эшләнгән тимер кием, күлмәк, кольчуга» мәгънәсендә кулланылуын әйтә. Чуваш телендә *кепе* сүзе «күлмәк», «кием-салым» мәгънәсендә йөри

*Чулпычы — чулпы* (хатын-кызның чәч толымына кушып үреләторган, бауга яки тасмага тагылган тәңкәләр) ясаучы һөнәрен белдерүче атамадан Чулпычы дигән ир-ат исеме ясалган. Бу исем Татарстанның Саба районындагы Чулпыч (<Чулпычы) дигән татар авылы атамасында сакланган.

Төзелеш эше, йорт-каралтылар салу остасы *балтачы* (балта остасы) һөнәре атамасына нигезләнеп Балтач, Балтачы кебек кеше исемнәре барлыкка килгән. Балтач исеме болгар-татар кабер ташы язмаларында да байтак очрый. Татарстанда, Чувашстанда, Башкортстанда һ. б. урыннарда шушы исемдәге татар авыллары бар. Казан татарлары һәм татар-мишәрләрнең Балтачев фамилиясенең асылында да Балтач (Балтачы) исеме ята. Украиннарда Балтача фамилиясе бар. Гарәби чыгышлы Наҗар исеме Балтач белән синонимдаш.

Кешенең кәсеп-һөнәрен белдерүче борынгы исемнәребез арасында Сатучы исеме дә бар. Алтайлыларда Сатучы исеме әле дә кулланылышта йөри. Бу исем татар-мишәрләрдә Сатучы, Сатушин, Сатучев фамилияләрендә сакланган. Безгә гарәпләрдән кергән Таҗир — Таҗирә (сәүдәгәр, сатучы) исемнәре дә сәүдәгәр кесәбенә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән.

Пешекче профессиясенә нисбәтле рәвештә Казанчы, Ашбаз, Ашман (иске татар телендә *ашбаз* һәм *ашман* сүзләре «пешекче, аш-су остасы» мәгънәсен белдергән), Калаччы кебек борынгы исемнәребез туган. Казанчы исеме Татарстанның Саба районындагы Казанчы, Казанчы-Бигәнәй дигән татар авыллары исемнәрендә һәм Казанчин, Казанчиев фамилияләрендә сакланган. Ашбаз исеменнән Казан татарларындагы Ашбазов, ә Ашман исеменнән Себер татарларында Ашманов фамилиясе ясалган. Калаччы исеменнән республикабызның Арча районындагы Кылачы (Калаччы) дигән татар авылы атамасы, татар-мишәрләрдә Калачников, Калашников фамилияләре барлыкка килгән.

Электә елга аша көймә-салга утыртып кичерү эше белән шөгыльләнүче кешене *кичү башы* (яки *бае*) дип атаганнар. Шушы кәсепкә нисбәтле рәвештә Кичүбаш, Кичүбай исемнәре туган. Казан татарларында бу исемнәрдән Кичүбашев, Кичүбаев фамилияләре ясалган.

## Баланың акыллы, тәүфыйклы, ата-анасына таяныч-ярдәмче булуын теләү исемнәре

Табигый ки, һәрбер ата-ана баланың акыллы, тәүфыйклы булып үсүен, үзләренә таяныч, ярдәмче, картайган көннәрендә караучы булуын тели. Татар антропонимиконында менә шушы теләк-мотив нигез булып яткан кеше исемнәре дә бар һәм алар үзләренә бер «оя» тәшкил итәләр. Юзык (борынгы төрки телдә *юзык* сүзе «акыл, юнь, мән, тәртип» төшенчәсен белдергән), Юзыкбай (акыллы бай), Юзыккай ~ Юзыкай (Казан татарларында Юзыкаев фамилиясендә сакланган), Гакыйль — Гакыйлә, Акылбай, Данияр (акыллы, белемле), Зирәк (үткен акыллы), Айзирәк, Зирәкгөл, Зиһения (зиһен, акыл иясе), Зиһеникамал, Зиһениҗамал, Тәүфыйк — Тәүфыйкә (тәүфыйклы, әдәпле), Әдип-Әдибә (әдәпле, тәрбияле, тәүфыйклы), Фәһим — Фәһимә (аңлы, зирәк, фәһемле, диалекталь вариантлары Фәим—Фәимә), Фәһиметдин, Фәһимҗан, Фәһми—Фәһмия, Фәһмулла, Фәһһәм, Һушияр (акыллы, аңлы) һ. б. кебек төрки-татар, гарәби *(гакыл, акыл, зиһен, тәүфыйк, фәһим фәһем, әдәп)*, фарсы чыгышлы *(данияр, зирәк, һушияр)* сүзләр катнашып ясалган исемнәр әнә шул ояга карыйлар.

Тарихи антропонимиконыбызда асылларында ир баланың эти-әнисенең таянычы, ярдәмчесе булуын теләү мотивы яткан кеше исемнәре шул теләкне чагылдырган төрле лексик-грамматик чаралар белән белдерелгән. Иске татар телендә мондый чаралар булып *йорт, багыш* (караш), *карамыш, әлем* (кулым), *терсәк, тирәк, таган* кебек сүзләр хезмәт иткән.

Составларында *йорт* (өй; биләмә; торак; ил-җир) антрополексемасы булган кеше исемнәренең күбесе күчерелмә мәгънәдә «йорт җанлы, йорт өчен тырышучан; төп йортны (ата-ана йортын) караучы, төп йортта калучы (төпчек) ир бала» дигән төшенчә аңлаталар.

*Йорт* антрополексемасына *-ай*, *-ый, -кай, -лы* кебек кушымчалар ялгау юлы белән Йортай, Йортый, Йортыкай, Йорткай, Йортлы исемнәре барлыкка килгән. Казан татарларында алар Юртаев, Юртыев, Юртеев, Юртыкаеев, Юртлин фамилияләрендә сакланганнар. Бу фамилияләр Казан губернасының 1834 елда үткәрелгән Ревизские сказки материалларында бар.

*Йорт* антрополексемасы телебезнең башка исем компонентларына кушылу юлы белән Йортаман (йортны исәнимин итүче бала; татар-типтәрләрдә Йортаманов ~ Юртаманов фамилиясендә сакланган), Йортбагыш (йортны ба-

гучы, караучы; Бу исем Казан шәһәренең 1565/68 һәм 1646 еллардагы сан алу кенәгәләрендә һәм Татарстанның Актаныш районындагы Зөбәер авылы шәҗәрәсендә очрый. Казан татарларында Юртбагушев фамилиясендә сакланган), Йортбак (йортны багучы, караучы (төпчек) ир бала), Йорткол (йорт колы, төп йортка хезмәт итүче ир бала, Казан ханлыгында Нугай юлында Йорткол дигән татар авылы булган. Татарстанның Куйбышев районында Урманасты Йорткол, Урта Йорткол һәм Кырый Йорткол дигән татар авыллары бар), Йортлыбай (йортлы бай; йорт-җире, гаиләсе бар бай; Себер татарларында Юртлубаев фамилиясендә сакланган), Йортмөхәммәт (диалекталь варианты Йортмәмәт; шуннан Юртмаметов фамилиясе ясалган. Бу фамилия Казан губернасының 1834 елгы Ревизские сказки материалларында Казан артындагы Олы Бәрәзә авылында теркәлгән), Йортыш (йорт ише, йорт дусты, йорты җанлы ир бала; Татарстанның Биектау районындагы Йортыш дигән татар авылы атамасында сакланган) һ. б. кебек кушма төзелешле кеше исемнәре барлыкка килгән.

Уртаклык юнәлешендәге *багыш (бак+ -ыш,* ягъни «караш») фигыленә нигезләнеп Багыш (ата-ананың ир баладан картаймыш көннәрендә үзләрен багышуны-карашуны теләү исеме. Багыш — Апас районындагы татар авылы атамасы), Малбагыш (Малбагыш — Азнакай районындагы татар авылы атамасы), Колбагыш (Колбагыш — Саба районындагы Иске Карабаян авылының җирле халык телендәге исеме), Куйбагыш (куйлар багыш, караш; Себер татарларында һәм татар-мишәрләрдә Куйбагышев фамилиясендә сакланган. Казахларда Куйбагыш исеме әле хәзер дә кулланылышта йөри) исемнәре ясалган.

*Булыш* (ягъни «ярдәм итеш») фигыленә нигезләнеп Булыш (әти-әнисенә булышучы ир бала) исеме барлыкка килгән. Бу исем татар-мишәрләрдә Булышев, Булушев фамилияләрендә сакланган. Булушев фамилиясе русларда да бар (Баскаков Н. А., 1979).

Иске татар телендә *карамыш* сыйфат фигыленә нигезләнеп Карамыш ∼ Кармыш (әти-әнисен карамыш бала) исем барлыкка килгән. Бу исем Карамыш, Кармыш дигән авыл атамаларында һәм Карамышев (Татарстанның Зеленодольск районы Мулла иле авылында Карамышев фамилиясен йөртүче гаиләләр булган), Кармышев фамилияләрендә сакланган. Бу фамилияләр русларда да бар (Баскаков Н. А., 1979).

Борынгы төрки телдә «кул» төшенчәсен белдерү өчен

йөргән *әл* сүзенә тартым кушымчасы *-ем* кушылу юлы белән Әлем дигән борынгы исем ясалган. Бу исем күчерелмә мәгънәдә «таяныч», ягьни «таянырдай кулым, ярдәмчем, ышанычым» дигәнне аңлата. Татарстанның Актаныш районында Иске Әлем һәм Яңа Әлем дигән татар авыллары бар. Әлем исеменең кушма төрләре: Әлембай (кулым, таянычым, ярдәмчем, булыр ир бала), Әлемгол (кулым, таянычым, ярдәмчем булыр кол, ягъни, ир бала), ясалма төре — Әлемкәй. Әлемкәй исеменең диалекталь вариантлары: Әлкәй, Әлки. Әлкәй — Татарстанның Азнакай, Әлки — Буа районнарындагы татар авылы. Республикабызның Әлки районында Югары Әлки, Урта Әлки һәм Түбән Әлки дигән татар-мишәр авыллары бар. Тарихи документларга Казан ханлыгы чорында Кама аръягы Нугай юлы өстендә урнашкан Әлки исемле авыл булуы теркәлгән.

Борынгы төрки-татар чыгышлы Юлыш исеме «гомер юлы ише, тормыш көткәндә эти-әнисенә булышучы, ярдәм итүче ир бала» дигән мәгънәгә ия. Бу исем татар-мишәрләрдә Юлышев фамилиясендә сакланган.

*Таган* (өчаяк, таяныч) сүзенә *-ай* чакыру-эндәшү кушымчасы ялганып ясалган борынгы төрки Таганай исеме ир баланың эти-әнисе өчен ныклы терәк, таяныч булуын теләп кушылган. Бу исем Казан татарларында Тәгәнәев, татар-мишәрләрдә Тәкәнәев, Себер татарларында Таканаев фамилияләрендә сакланган. *Таган* сүзенә *-чык* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы кушылып ясалган Таганчык исеменең мотивы да шундый ук дип уйларга кирәк. Бу исем Себер татарларында Таканчиков фамилиясендә сакланган. Төрекмәннәрдә Таганбиби (таяныч бикә) дигән хатын-кыз исеме бүген дә актив кулланылышка ия.

Татарларга гарәпләрдән кергән Мөгыйн — Мөгыйнә, Рәфит — Рәфидә, фарсылардан алынган Явар (Яваров фамилиясендә сакланган) исемнәре дә «ярдәм итүче, булышчы» мәгънәсенә ия. Гарәби чыгышлы Локман — Локмания исемнәре «караучы, туйдыручы» төшенчәсен белдерә.

## Гаиләдә балаларның үлемен яки тууын туктатырга теләү исемнәре

Нәрсәне дә булса туктатырга тырышу, боеру, кушу, теләү кебек субъектив мөнәсәбәт иске татар телендә башлыча *тукта, туктасын, бикლә, чиклә* фигыльләре ярдәмендә белдерелгән. Шушы җирлектә тарихи антропонимиконыбызда гаиләдә балаларның үлемен яки тууын тукта-

тырга теләү исемнәре боеру-теләкне чагылдырган фигыль формаларына нигезләнеп барлыкка килгәннәр.

Гаиләдә туган бер ир яки кыз бала үлеп барса, үлемне туктату максаты белән яки, киресенчә, бала күп булса, тууны туктату теләгеннән чыгып, *тукта, туктасын, туктар, туктаган, туктамыш* компонентлы исемнәр кушылган: Тукта, Туктабай, Туктабәк, Туктабикә, Туктагол (Татарстанның Балтач районы Чепья авылында шушы исемне йөртүче ир балалар бар; Казан татарларында Туктагулов фамилиясендә сакланган), Туктаган, Туктамыш (бу исем татар-мишәрләрдә Туктамышев фамилиясендә сакланган; Татарстанның Биектау һәм Саба районнарында Туктамыш дигән татар авыллары бар. Казан ханлыгында Тау ягында Кушлавыч елгасы буенда Туктамыш иле дигән татар авылы булган), Туктамышгәрәй, Туктар (бу исем Туктаров фамилиясендә, Татарстанның Саба һәм Әлмәт районнарындагы Туктар, Лениногорск районындагы Туктар Урдалысы дигән татар авыллары атамасында сакланган, Туктар исеме хәзер дә очрый), Туктаргали (шушы исемнән Туктаргалиев һәм Туктаргалин фамилияләре ясалган), Туктаргалим (диалекталь варианты Туктаралим), Туктариш, Туктархан, Туктарша(һ) һ. б.

Борынгы төрки-татар Биклән исеме кайтым юнәлешендәге *биклән* (ягъни «йозаклан, бик-йозак сал») фигыленнән ясалган. Бу исемдә процессның субъектка кайтуы, эшне үзе үтәргә тиешлеге белдерелә. М. Кашгариның «Девану луғатит турк» китабының беренче томында (Ташкент, 1960), «Беклән — ирләр исеме»,— дип күрсәтелгән. Безнең регионда Биклән исеме Татарстанның Тукай районындагы татар авылы атамасына әверелеп сакланган.

Асылында нәтиҗәле үткән заман *бикләмеш* хикәя фигыле (балаларның үлемен яки тууын бикләмеш) яткан борынгы төрки-татар Бикләмеш исеме гаиләдә бер-бер артлы туган ир балалар үлеп барса, үлем бикләнсен, туктасын дигән теләктән чыгып, яки, киресенчә, бала күп булып, бу баладан соң яңадан бала тумасын, ягъни гаиләдә бала туу туктасын (бикләнсен) дигән теләк-максат күздә тотылып, сүзнең тылсым көченә ышанып кушылган. Татар һәм русларда ул Бикләмешев, Беклемишев фамилияләрендә сакланган.

*Чикләмеш* хикәя фигыленә нигезләнеп барлыкка килгән борынгы Чикләвеш исеме дә «ходай баланың үлемен яки тууын чикләмеш» дигән төшенчәне белдерә. Бу исем Казанның 1565/68 елларда төзелгән сан алу кенәгәләрен-

дә бар. Казан татарларында Чикләмешев фамилиясендә сакланган.

Борынгы заманнарда гаиләдә балаларның үлемен яки тууын туктатырга теләп кушылган Биклән, Бикләмеш дигән йола исемнәре нәрсәне дә булса (бу очракта, үлемне яки тууны) бикли, йозаклый торган предметны белдерүче Йозак, Бик, Тозак, Мәскәү (кыл тозак) кебек борынгы кеше исемнәре белән мәгънәдәш.

Йозак — шулай ук гаиләдә баланың үлеме яки тууы тукталсын дигән теләктән чыгып кушылган борынгы теләк йола исеме. Синонимы Бик. Тозак исеме дә — үлемгә яки туугa чик кую, тозак кору дигән мәгънәгә ия булган борынгы теләк-йола исеме. Бу исем гаиләнең башта туган ир балалары бер-бер артлы үлеп барсалар яки, киресенчә, гаиләдә балалар кирәгеннән артык күп булса, яңа туган ир балага кушылган.

Мәскәү — «ат аягын тышаулый торган кыл аркан, кыл тозак». Шушы сүзгә нигезләнеп барлыкка килгән борынгы төрки-болгар-татар Мәскәү исеме гаиләнең бу баласы үлмәсен яки башка бала тумасын, аның үлеменә яки тууына мәскәү (тозак) куелсын дигән теләктән чыгып кушылган. Шәрәфетдин бине Хисаметдин Мөслими Мәскәү исеменең болгар-татарларда кулланылышта йөрүен «Тәварихы Болгария» дип аталган хезмәтендә әйтеп үтә. Атаклы татар галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең Көнчыгыш бүлегендә саклана торган кулъязмалары арасында 1757/58 елларга караган кулъязмадан күчерелгән татар шәҗәрәсе бар. Бу шәҗәрәне Риза Фәхретдинов 1914 елда «Шура» журналының 7 нче санының тышлыгында бастырып чыгара. Анда Болгар шәһәреннән Тау ягындагы Әрә елгачыгы буена килеп утырган Шәех-бинең (Мулла иле авылына нигез салган болгарларның берсе.— *Г. С.*) нәсел җебе бәян ителә. Шәех-бинең этисе Тәмти-Хытаи Болгар шәһәреннән (Әлболгари) булган. Тәмти-Хытаи Әлболгариның уникенче буын варисларыннан берсенең исеме Мәскәү (Мәмәт улы Мәскәү) була. Мәҗүси чуваш исемнәре тупламында да Москау, Москай исемнәре бар (Магницкий В. К., 1905). Мәскәү исеме Москва шәһәре атамасының татарча әйтелеше Мәскәү белән омонимдаш. Башкорт язучысы Йосыф Гәрәй башкорт телендә хәзер дә «балык мәскәүләү» дигән сүз булуын һәм аның «кыл тозак белән балык тоту» төшенчәсен белдерүен күрсәтеп китә. Ул Башкортстанның берничә районында Мәскәү (русча Москова) исемен йөртүче авыллар булуын хәбәр итә һәм бу авыллар-

ның атамасы Мәскәү («кыл тозак») дигән кеше исеменнән алынган дип саный (Гәрәй И., 1971).

Борынгы төрки чыгышлы Бик, Йозак, Тозак, Мәскәү кебек синонимик исемнәребез рәтенә беркадәр соңрак гарәплардән кергәнВаккас (тозак), Фак (тозак, кыл тозак), Нурфак — Нурфага (нур тозагы), Әкъфал (йозаклар, бикләр), Тәкъфил-Тәкъфилә (йозак салу, йозаклау, бикләү) һәм фарсылардан алынган Дамил (тозак; аутозак кую) исемнәре өстәлгән.

Гарәби чыгышлы Манигъ — Манига исемнәре дә «тыючы, тоткарлаучы; киртә» (күчерелмә мәгънәсе — тууга яки үлемгә киртә) мәгънәсен белдерә. Манигъ исеменнән татар-мишәрләрдәге Манеков фамилиясе ясалган.

## Баланың тугрылыклы, гадел булуын теләү исемнәре

Табигый, ата-ана дөньяга килгән баланың тугрылыклы, гадел, ышанычлы һәм керсез, саф булуын тели. Шушы теләкне төп мотив итеп алып кушылган исемнәр дә байтак.

Иске татар телендә тугры (тугры, гадел, хак) сүзе кергән Тугры, Тугрыбай>Турыбай, Тугрыбәк>Турыбәк, Тугрыбикә>Турыбикә, Тугрыкол>Турыкол (Себер татарларында Тугрыголов∼Турыгулов фамилиясендә сакланган), Тугрыиш∼Турыиш∼Туриш (Себер татарларында һәм татар-мишәрләрдә Туришев фамилиясендә сакланган), Тугрыхан∼Турыхан (Казан татарларында Турыханов фамилиясендә сакланган), Тугрул исемнәре кулланылышта йөргән. Урта гасырларда гарәби чыгышлы гадел (тугры, тугрылыклы, намуслы) антрополексемасы катнашып: Гадел (төрдәше Адел), Гаделбай, Гаделбану, Гаделбәк, Гаделбикә, Гаделбәнат, Гаделгәрәй, Гаделша, Гаделәхмәт, Гаделҗан, Гаделҗиһан, Гадил — Гадилә) диалекталь вариантлары Адил — Адилә, Адыл, Әдил-Әдилә), Гадилгәрәй, Гаделморат, Гадлия һ. б. кебек исемнәр гамәлгә алынган.

Гарәп теленнән «тугрылыклы, ышанычлы, намуслы» мәгънәсендәге Вафа — Вафия, Инабәт, Мөбин — Мөбинә, Мәстүрә, Саддин, Сәвия, Фазаил, Әгъдәл-Әгъдәлия, Әдип-Әдибә, Әмин — Әминә, һ. б. кебек исемнәр кулланылышка алынган. «Саф, пакь, керсез» мәгънәсенә ия булган Зиһат, Инсаф — Инсафия, Әнсаф, Нәкый — Нәкыя, Самим — Самимә, Сафа, Сафия, Тәзкия, Халис — Халисә, Мөхлис — Мөхлисә һ. б. исемнәр кабул ителгән. Фарсылардан Дада (турылык, гаделлек), Пакизә (саф, керсез, пакь), Илфак, Илпакь (ил пагы, саф кешесе), Җанфак — Җанпакь (пакь җан) һ. б. исемнәр кергән.

## Ата-ана һәм туган-кардәшләренең баланың үзләренә иптәш, дус, юлдаш булуын теләү исемнәре

Татар исемнәре хәзинәсендә ата-ана һәм туган-кардәшләрнең баланың үзләренә иптәш, дус, юлдаш булуын теләү мотивы яткан исемнәр аерым бер семантик төркем хасил итәләр. Болгар-татарларда «кулай; төс, тиң, дус, иптәш» мәгънәсенә ия булган *иб~ип* сүзе кулланылышта йөргән. Шул сүз катнашып: Иббирде, Ибиш (Казан татарларында Ибишев фамилиясендә сакланган. Төрдәше Ибуш. Шуннан керәшен татарларындагы Ибушев фамилиясе барлыкка килгән), Ибкилгән, Ибекәй (керәшен татарларында Ибкиев, Ибкин фамилияләрендә сакланган) кебек исемнәр ясалган.

«Гомер юлдашы, иптәше» төшенчәсен белдерә торган Юлдаш исеме татарларда XV—XIX йөзләрдә шактый актив кулланылышка ия булган. Юлдаш, Юлдашбай, Юлдашбәк, Юлдашбикә исемнәре башкортларда, кыргызларда, үзбәкләрдә әле дә кулланыла. Төрки Юлдаш исеменә фарсы чыгышлы Һәмраһ исеме синонимдаш.

Фарсы теленнән кергән *дус* сүзенә нигезләнеп байтак кына кеше исемнәре ясалган: Дус (синонимы — гарәби чыгышлы Садыйк), Дусай (бу исем XVI—XVIII йөзләрдә Казан татарларында актив кулланылышка ия булган. Дусаев фамилиясендә сакланган), Дусак (керәшен татарларында Дусаков фамилиясендә сакланган), Дусабәк (Казан татарларында Дусабеков, Дусакбетов фамилияләрендә сакланган), Дусби (шушы исемнән Дусбиев, Дуспиев фамилияләре ясалган), Дусбиргән (татар-мишәрләрдә Дусбиргәнов фамилиясендә сакланган), Дусгали (диалекталь варианты Дусали. Болардан Дусгалиев, Дусгалин, Дусалиев, Дусалин фамилияләре ясалган), Дусгалим, Дусморат, Дусмөхәммәт (диалекталь вариантлары Тусмөхәммәт, Дусмәт, Тусмәт, Дусми, Дуси. Болардан Дусмөхәммәтов, Тусмөхәммәтов, Дусметов, Тусметов, Дусмиев, Дусиев фамилияләре ясалган. Дусмәт — Татарстанның Мамадыш районындагы татар авылы атамасы), Дуссадыйк (фарсыча *дус* һәм гарәпчә *садыйк* — «дус» сүзләре кушылып ясалган исем. «Икеләтә дус» дигән мәгънәгә ия. Казан татарларында (мәсәлән, Татарстанның Мөслим районында Дуссадыйков (Дусадыков) фамилиясендә сакланган), Дусым (Татарстанның Арча районында Дусым, Сарман районында Дүсем дигән татар авыллары бар) һ. б.

Төрки-фарсы чыгышлы Илфат һәм Илдус исемнәре «ил дусты» дигән мәгънәгә ия.

Гарәби Нажия, Сәхиб — Сәхибә, Сәхби — Сәхбия, Сәхәп исемнәре дә «дус, юлдаш, иптәш, сердәш» мәгънәсенә ия. Әлеге антрополексемалар катнашып: Сәхиббай, Сәхиббәк, Сәхәбетдин, Сәхибулла, Сәхибкамал, Сәхибҗамал, Сәхибхан, Сахибҗан, Сәхипгәрәй, Сәхипзадә, Сәхипкамал, Сәхәпкол һ. б. кебек кушма төзелешле кеше исемнәре ясалган һәм татарларда да кулланылышта йөргән. Сәхәпче (юлдаш булучы) — гарәби чыгышлы *сәхәп* (дус, юлдаш, иптәш) сүзенә татар теленең *-че* кушымчасы ялганып барлыкка килгән ясалма исем. Ул Казан татарларында Сәхәпчиев фамилиясендә (мәсәлән, Татарстанның Лаеш районы Пәрәү авылында) сакланган.

## Баланың теге яки бу мифологик, фольклор, әдәби әсәр каһарманы, тарихи шәхес кебек булып үсүен теләү исемнәре

Нинди дә булса яхшы сыйфатка ия булган мифологик, фольклор, әдәби әсәр каһарманнары һәм тарихи шәхесләр элек-электән кеше күңелендә ихтирам уятканнар. Алар халыкның әдәби, этик, һәм эстетик зәвыгын канәгатьләндергәннәр, аны үстергәннәр һәм тәрбияләгәннәр. Менә шуңа мондый мифологик, фольклор яки әдәби әсәр каһарманнары, атаклы тарихи шәхесләрнең исемнәре борынгы заманнарда ук барлык халыкларда да диярлек балаларга кушылып килгән. Ата-ана дөньяга яңа килгән сабыйга мондый исем кушканда, аның үзенә исем итеп бирелгән мифологик, фольклор яки әдәби әсәр герое, атаклы тарихи шәхес кебек булып үсүен, танылуын теләгән һәм исем кушканда менә шушы теләк төп мотив булган. Ономастик әдәбиятта бу төр кеше исемнәрен б а г ы ш л а у и с е м н ә р е (меморативлар) дип атыйлар.

Татар халык экиятләрендә урын алган мифологик канатлы ат, чабышкы, яу аты *тулпар* атамасына нигезләнеп тарихи антропонимиконыбызда Тулпар исеме барлыкка килгән. Шушы исемнән Тулпаров фамилиясе ясалган. Татарларда Тулпар исеме хәзер дә кулланылышта йөри.

Көчле ташкын, көчле яңгыр, давыл, ураган; бөтен дөньяны су басу — *туфан* турындагы риваять нигезендә Туфан исеме барлыкка килгән. Туфан — күренекле татар шагыйре Хәсән Туфанның псевдонимы. Аның чын фамилиясе Гөлзизин әнисе Гөлзизә ~ Гөлзәүҗә (гөлдәй ха-

тын) исеменнән ясалган. Шагыйрь әдәби имзасын бабасы Фәхретдиннең кушаматы Туфаннан ала. Туфан исеме 30 нчы еллардан башлап ир балаларга кушыла башлый.

Төрки халыкларда Айваз исеме шактый киң таралыш алган (төрекмәннәрдә Овез, азәрбайҗаннарда Эйваз, үзбәкләрдә Авез). Бу исем әрмәннәргә дә кергән. Атаклы рәссам Айвазовскийның фамилиясе шул исемнән. Ул башта Айвазян (Айваз улы, токымы) фамилиясен йөрткән. Таҗик галиме Алим Гафуров Айваз (Аваз) исеме гарәп телендәге *авад (алмаш)* сүзеннән ясалган, бу исемне аннан алдагы ир туганы үлгәннән соң туган ир балага, ягъни абыйсына алмашка килүче балага кушканнар дигән караштә тора. Р. Г. Әхмәтьянов исә Айваз исеме фарсыча «якты ай», «тулган ай» мәгънәсен белдерә дип саный. Шушы исемнән Казан татарларында һәм Дунай болгарларында Айвазов фамилиясе ясалган. Болгар галиме Стефан Илчев Дунай болгарларындагы Айвазов фамилиясенең асылында төрекләрнең *ауваз* (өй хезмәтчесе) сүзе ята дип саный (Илчев С., 1969).

Татар халкының тамырлары бик еракларга киткән «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф вә Зөләйха», «Таһир белән Зөһрә», «Шәһсәнем һәм Гариб», «Бүз егет» һ. б. мәхәббәт дастаннарында яшьләрнең саф, керсез, кайнар мәхәббәте белән беррәттән, шәхес иреге, гүзәл идеалга омтылу кебек гуманистик идеяләр алга сөрелә, урта гасырлар чоры залимнәре фаш ителә. «Дастан образларында татар халкы үз хыялында саклаган батырлык, үз күңелендә йөрткән тугрылык, пакьлек хисләрен һәм үзе идеал дип санаган матурлыкны тасвирлаган» (Әхмәтова Ф. В., 1984). Әлеге мәхәббәт дастанарының геройлары халык күңеленә һуш килгәнгә, күбесенең исемнәре яшь буынга яратып кушыла торган «бәхетле» исемнәребезгә әверелгәннәр.

Игезәк булып туган малай белән кызга Таһир һәм Зөһрә исемнәре кушу гадәте татарларда бик күптәннән килә. Мондый гадәт башка төрки халыкларда да бар. Бу исемнәрнең мәгънәләре дә бик күркәм. Таһир исеме «саф, пакь, гөнаһсыз» мәгънәсенә ия булса, Зөһрә исеме «нур чәчеп, балкып торучы» дигән мәгънә белдерә.

«Йосыф вә Зөләйха» дастаны һәм Колгалинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» поэмасы тәэсирендә Йосыф һәм Зөләйха исемнәре шулай ук бик актив һәм популяр исемнәребез булып киткәннәр. Бу исемнәрне татарлар хәзер дә балаларына яратып кушалар.

Көнчыгыш халыклары арасында «Ләйлә белән Мәҗнүн» поэмасының ифрат популярлыгы аркасында гарәби чыгышлы Ләйлә исеме киң таралышка һәм кулланылышка ия. «Төн, кич, кичә; кара чәчле» мәгънәсенә ия булган Ләйлә исеме — татарларда да популяр.

Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасының баш геройлары Галиябану белән Хәлилне татар халкының ихласи яратуы, бу образларга кайнар симпатиясе Галиябану (бөек, олы, югары дәрәҗәле кәләш, ханым, бикә) һәм Хәлил( якын дус, чын дус) исемнәренең 20 нче еллардан башлап киң таралуына, популярлашуына китерде.

Фарсылардан кергән Әсфәндияр һәм Рөстәм исемнәренең бездә популярлык казануының төп сәбәбе нәрсәдә? Әсфәндияр («бакыр тәнле») — борынгы иран эпосы каһарманы. Рөстәм (бик зур, алып гәүдәле; әзмәвер) — борынгы иран фольклорында легендар каһарман, пәһлеван, батырлык символы, Фирдәүсинең атаклы «Шаһнамә» поэмасының төп герое. Рөстәм — хәзерге заманда татарларда ир балаларга кушыла торган иң популяр исемнәрнең берсе.

Атаклы тарихи шәхесләр хөрмәтенә кушыла торган берничә багышлау исемгә тукталып үтик.

Борынгы Грециянең атаклы яубашы Александр Македонскийга мөнәсәбәтле рәвештә урта гасыр башларында гарәпләрдә Искәндәр (ирләрне яклаучы) һәм Зөлкарнай (куш мөгезле) исемнәре барлыкка килгән. Бөек Александр Македонский куш мөгезле баш киеме киеп йөргән. Шәрык халыклары аны Искәндәр Зөлкарнаен (Куш мөгезле Искәндәр) дип атаганнар. Татарларда да Искәндәр исеме шактый актив кулланылышка ия. Зөлкарнай исеменең татарларда Зөлкар һәм Карнай дигән диалекталь вариантлары барлыкка килгән.

Безгә гарәпләрдән урта гасырларда килеп кергән Әфләтун исеменең асылында борынгы Грециянең бөек философы Платон (яңа эрага кадәр 427—347 еллар) исеме ята. Грекча *платюс* (киң җилкәле, тулы, көчле) сүзеннән Платон исеме ясалган. Татарлар балаларына Әфләтун исемен аның үскәч Әфләтун хәким кебек бөек фикер иясе булуын теләп кушканнар. Әфләтун исеменең Әфли диалекталь варианты барлыкка килгән. Болардан Әфләтунов һәм Әфлиев фамилияләре ясалган.

**Асылларында баланың үзенә нисбәтле төрле ышанулар, йолалар, гадәт-традицияләр мотив булып яткан исемнәр**

Татар антропонимиясенең бу төр кеше исемнәре дистәдән артык лексик-семантик төркемне үз эченә ала. Хәзер шул төркемнәрне карап үтик.

Баланың төс-бите мотив булган исемнәр

Яңа туган баланың күзе, бите, чәче, кашы һ. б. әгъзасының төсенә карап исем кушу гадәт-йоласы барлык халыкларга да хас. Татар антропонимиконында да шушы нигездә байтак кына борынгы кеше исемнәре барлыкка килгән.

Татар исемнәре хәзинәсендәге антонимик (капма-каршы мәгънәле) кеше исемнәренең зур күпчелеге кеше әгъзасы атамаларына (анатомик терминнарга) төс белдерүче *ак* һәм *кара* сыйфат сүзләре кушылу юлы белән ясалган: Аккүз — Каракүз, Акбаш — Карабаш, Акчәч — Карачәч, Акчар (ак йөзле, кыяфәтле) — Карачар (кара йөзле, кыяфәтле), Аккал (ак миң) — Каракал (кара миң), Аккаш — Каракаш һ. б. Мондый исемнәребезнең байтагы, авыл атамаларына әверелеп, безнең көннәргәчә килеп җиткәннәр (Аккүз — Татарстанның Актаныш, Акбаш — Баулы, Карабаш — Бөгелмә районнарындагы татар авыллары) һәм Аккүзов (Аккузов), Аккүзин, Акузин, Акбашев, Акчаров, Аккашев, Аксакалов (1773—1775 елларда Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар кузгалышында катнашкан бер татар Аксакалов фамилиясен йөрткән. Аксакалов фамилиясе русларда да бар), Каракашев, Карабашев кебек фамилияләр дә, әлбәттә, исемнәрдән килеп чыкканнар.

Карачар исеме кара чәчле, кара тутлы ир балаларга тышкы кыяфәтләренә карап кушылган. Бу исем Казан шәһәре һәм Казан өязенең XVI—XVII йөзләргә караган сан алу кенәгәләрендә очрый. Казан татарларында һәм русларда Карачаров фамилиясендә сакланган. Дөрес, Н. А. Баскаков руслардагы Карачаров фамилиясенең асылында *кара жар* (яр) географик термины ята дип карый.

Анатомик терминнарга төс белдерүче башка сыйфат сүзләр кушылу юлы белән: Күккүз, Алакүз, Сорыкүз, Сарыбаш, Алабаш, Кызылбаш, Утбаш (җирән чәчле ир балага кушылган), Сарычәч, Сарытолым, Алтынчәч (алтын кебек саргылт чәчле), Борнак (борыны ак); Алсылу, Аксылу, Алсу, Алсинә (ак күкрәк) һ. б. кебек исемнәр ясал-

ган. Бу исемнәрдән Алабашев ~ Алабышев, Алакүзев, Күккүзов, Сорыкузин, Кызылбашев, Утбашев, Акбитов, Борнаков (Бурнаков) фамилияләре пәйда булган. Алабышев, Бурнак, Бурнаков фамилияләре русларда да бар. Пермь өлкәсендәге бер татар авылы Борнак исемен йөртә. Татарстанның Апас районында — Зур Күккүз, Кече Күккүз, Балтач районында Борнак дигән татар авыллары бар.

Төс белдерүче төп сыйфат сүзгә, аның артыклык яки кимлек дәрәҗәсе алган, яисә антропонимик кушымчалар ялганган формаларына нигезләнеп тә кеше исемнәре ясаганнар: Коңгырт — коңгырт күзле яки коңгырт чәчле ир балага кушылган исем, Казан татарларында Коңгыров (Кунгуров), русларда Кунгуров фамилияләрендә сакланган. Казан губернасы Әҗәкүл авылында XVIII гасыр азакларында Коңгыр исемле мулла яшәве һәм 1781 елда «Казыйлар өчен кулланма» дигән хезмәт язуы билгеле; Сары (борынгы төрки халыкларда сары төс — затлы төс, алтын төсе итеп саналган. Табигатьнең сары төстәге әйберләре ихтирам ителгән.) — ир-ат исеме. Бу исем Сариев, Сарыев фамилияләрендә сакланган; Аппак — ир-ат һәм хатын-кыз исеме. Бөек азәрбайҗан шагыйре Низами Ганҗәвинең кыпчаклы хатыны Аппак исемле булган. Бу исем Казан татарларында һәм татар-мишәрләрдә Аппаков фамилиясендә һәм Әлки районындагы Аппак (Апак) авылы атамасында сакланган; Аппаккай — Аппак исеменә *-кай* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган исем. Төрдәше Апакай, антонимы Каракай. Шуннан Казан һәм Себер татарларындагы Каракаев фамилиясе ясалган. Апакай — Татарстанның Питрәч районындагы Ленино-Кокушкино рус-татар авылының татарлар яши торган өлешенең атамасы. Татар-мишәрләрдә Аппакаев, Апакаев фамилияләре бар, Аппакач — Аппак исеменә *-кач* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган исем. Диалекталь вариантлары: Апакач, Апакаш. Болардан Казан татарларында Апакачев һәм Апакашев фамилияләре ясалган; Аккай — *ак* сыйфат сүзенә *-кай* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган ир-ат исеме. Татар-мишәрләрдә Аккаев фамилиясендә сакланган. Аккач — *ак* сыйфат сүзенә *-кач* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган борынгы ир-ат исеме. Казан татарларында Аккачев, Акачев фамилияләрендә сакланган; Акчуар — төс белдерүче *ак* һәм *чуар* сыйфат сүзләрен бергә кушу юлы белән ясалган ир-ат исеме. Казан татарларында Акчуаров (Акчуваров) фамилиясендә сакланган; Алак — төс белдерүче *ал* һәм *ак*

сыйфат сүзләрен кушу юлы белән барлыкка килгән ир-ат исеме.

Төс белдерүче сыйфат сүзләре туганлык терминнарына ялгану юлы белән дә байтак кына кушма төзелешле кеше исемнәре барлыкка килгән: Акъегет (Казан татарларында, Акъегетов, татар-мишәрләрдә Акъегетзадә фамилияләрендә сакланган; Зеленодольск районында Акъегет дигән татар авылы бар) — Караегет, Аккыз — Каракыз, Акбикәч — Карабикәч, Акбикә (бу исем мариларга да кергән) — Карабикә, Албикәч, Албикә, Җизбикә, Акбала, Карабала, Сарыбала, Сарымалай, Агул (ак угыл; Бу исем мариларга да кергән. Татар-мишәрләрдә һәм русларда Акулов фамилиясендә сакланган), Акзадә (ак бала) һ. б.

Акбай, Алабай, Карабай, Сарыбай һ. б. кебек составларында төс белдерүче сыйфат сүзләр булган төрки-татар кеше исемнәре дә баланың төс-кыяфәтенә карап кушылган борынгы йола исемнәребезнең бер төрен тәшкил итәләр. Бу исемнәр, йон төсенә карап, этләргә дә кушыла, ягъни зооним булып та йөри.

Урта гасырларда гарәпләрдән кергән Әхмәр (кызыл; кызыл-алсу йөзле), Әбьяз (ак, ак төс), Әсмәр (кызгылт-көрән), Әсфир — Әсфирә (сары төс), Әсфәр (сары), Әхзар (яшел), Хамра (кызыл), Сәвади (каралык; кара төстәге), Мави — Мавия (су төсендәге, зәңгәр), Мәүрә (каратутлы, кара күзле), Әдһәм — Әдһәмия (каратутлы), Габәш ~ Габиш — Габишә (кара тутлы, кара чырайлы), Әшкар (җирән чәчле; сары чәчле, төрдәше Әшкә), Сөмәйрә (каратутлы), фарсы чыгышлы Залия (ак чәчле кыз) һ. б. кебек төс-кыяфәт белдерүче исемнәр хисабына антропонимиконыбызның әлеге лексик-семантик төркеме тагын да байый төшкән.

Татар антропонимиконына рус теле аша кергән латин чыгышлы Альбина исеме «ак, ак йөзле, ак чырайлы», Руфия, Руфинә исемнәре «алтын сыман саргылт чәчле; җирән», Руфис исеме «җирән, җирән чәчле» мәгънәсенә ия. Димәк, болар да төс-кыяфәт белдерүче исемнәр икән.

### Бала тугач аның берәр үзенчәлекле әгъзасы мотив булган исемнәр

Бала тугач, аның үзенчәлекле (гадәтидән зур яисә үсеш алмаган, зәгыйфь) әгъзасы күзгә ташлана. Борынгы заманнарда кеше исемнәре шул әгъза атамасына нигезләнеп тә барлыкка килгән.

Шушындый үзенчәлек мотив булган борынгы төрки-татар исемнәренә Корсак, Карнак (зур корсаклы), Аксак, Чатан, Гөберчәк, Көкүз (күкрәк) һ. б. гади төзелешле һәм составында йөз (чырай, бит), күз яки каш антрополексемасы булган Йөзсылу, Сылуйөз, Гөлйөзем, Күзбай, Күзби, Күзбәк, Күзкәй, Айкаш, Каләмкаш һ. б. кебек кушма төзелешле исемнәрне мисал итеп китерә алабыз.

Корсак исеме корсагы гадәтидән зур булган, күзгә ташланып торган кыска буйлы ир балага кушылган. Зур корсаклы булганга, дала төлкесенең бер төрен дә *корсак~карсак* дип атаганнар. Корсак (Карсак) исеме Казан татарларында Карсак нәселе кушаматына һәм Карсаков фамилиясенә әверелеп сакланган. Мәсәлән, Татарстанның Зеленодольск районы Мулла иле авылында берничә семьяны үз эченә алган Карсак нәселе бар. Шушы нәсел кешеләренең күбесе Карсаков фамилиясен йөртә. Н. А. Баскаков руслардагы Корсаков, Дондуков-Корсаков, Римский-Корсаков фамилияләрнең килеп чыгышын төрки телләрдән рус теленә алынган *корсак* (дала төлкесе) сүзе белән бәйләнешле дип саный. Русларда төрки-татар Корсак исеменнән ясалган Курсаков фамилиясе дә бар.

Карнак исеме борынгы төрки телдә «зур корсаклы» мәгънәсен белдергән *карнак* сүзенә барып тоташа. Туганда корсагы зур булган балага Карнак исеме кушканнар. Татар-мишәрләрдә һәм керәшен татарларында Карнаков фамилиясендә сакланган.

Аксак исеме туганда ук бер аягы икенчесеннән кыскарак булган ир балага бирелгән. Синонимы Чатан. Татарстанның Арча һәм Питрәч районнарында Аксаков фамилиясен йөртүче татар гаиләләре яши. Руслардагы Аксаков фамилиясенең асылында да әлеге кушамат-исем ята (Баскаков Н. А., 1979).

Гөберчәк исеменең төзелеше *гөбер* (оры, бөкре) + *чәк* кечерәйтү кушымчасыннан гыйбарәт (чагыштыр: *гөберле бака*). Туганда аркасында гөбере, бераз бөкресе булган ир балага әлеге кушамат-исем кушылган (чагыштыр: Горбун, Горбуша — борынгы рус исемнәре; Веселовский Б. С., 1974). Татарстанның Арча районында Гөберчәк дигән татар авылы бар.

Көкүз исеме төрки телләрнең угыз группасында (азәрбайҗан, төрек, төрекмән һ. б.) «күкрәк» дигән мәгънә белдерә. Бу исем күкрәк сөякләре гадәттәгедән бераз алгарак чыгып торган ир балаларга кушылган. Татар-мишәрләрдә Көкүзов (Кокузов) фамилиясендә сакланган.

Гарәпләрдә *садыр* (күкрәк, түш, йөрәк) сүзе катнашып ясалган Садретдин (дин күкрәге), Садрый — Садри, Садыйр — Садыйрә, Садрелислам, Садрелшәһит, Әхмәтсадыйр һ. б. кебек кеше исемнәре урта гасырларда татар антропонимиконына кабул ителгәннәр. Гарәби чыгышлы Әлбәдән исеме «тән, гәүдә, бәдән» мәгънәсендә. Безнең регионда бу исем Татарстанның Питрәч районындагы Әлбәдән дигән керәшен татарлары авылы атамасына әверелеп сакланган. Фарсы генезислы *синә* (күкрәк) антрополексемасына нигезләнеп Синәгол (Башкортстан татарларында Синәголов ~ Синегулов фамилиясендә сакланган), Синәй (Казан татарларында Синәев, татар-мишәрләрдә Синаев фамилияләрендә сакланган) дигән ир-ат, Гөлсинә (гөл күкрәкле), Илсинә, Алсинә, Нурсинә, Филсинә, Айсинә һ. б. кебек хатын-кыз исемнәре ясалганнар. Әлеге хатын-кыз исемнәре бездә бүгенге көндә дә актив кулланылышка ия.

Тарихи антропонимиконыбызда *йөз* (бит, чырай) сүзе катнашып Йөзем, Гөлйөзем (синонимнары Гөлруй, Гөлчирә), Йөзембикә, Йөзембану, Йөзсылу, Сылуйөз, Миңлейөз (синонимнары Миңлеруй, Калчирә, Калчәр) Нурлыйөз (синонимы Нурлыруй), Нурйөз (синонимы Нурчирә) һ. б. кебек хатын-кыз исемнәре барлыкка килгән. Гарәби чыгышлы Симай (ир-ат), Сима (хатын-кыз), Тәлгать исемнәре дә «төс, чырай, йөз» дигән мәгънәгә ия.

Борынгы төрки-татар күз антрополексемасы катнашып Күзбай, Күзби, Күзбәк, Күзкәй һ. б. кебек ир-ат исемнәре барлыкка килгән. Мондый исемнәр зур күзле яки (күчерелмә мәгънәдә) «күз кебек кадерле» ир балаларга кушылган. Казан татарларында шушы исемнәрдән ясалган Күзбаев, Күзбәков (Кузбеков) фамилияләре бар. Күзби — Татарстанның Буа районындагы Урта-Лащи авылының җирле халык телендәге атамасы, Минзәлә районында Күзкәй дигән татар авылы бар.

Фарсы телендә «күз» төшенчәсен белдерә торган *дидә* сүзенә нигезләнеп Дидә, Нурдидә (күз нуры) кебек хатын-кыз исемнәре барлыкка килгән. Бу исемнәр татарларда шактый актив кулланылышка ия.

Бу типтагы кеше исемнәре көнчыгыш славян халыкларында (русларда, украиннарда, белорусларда) аеруча күп була. Мәсәлән, Брюха, Брюхан, Горбун, Голова, Голован, Голеня, Голанище, Лоб, Лобач, Лобан, Губа, Губан, Нос, Горбонос, Ломонос, Кривонос, Нога, Короткие Ноги, Ус, Ушак, Костяные Уши, Очи, Грозные Очи, Очкас,

Шея, Кривошея һ. б. — борынгы рус исемнәре (Веселовский Б. С.). Боларның күбесеннән хәзер дә кулланылышта йөри торган рус фамилияләре ясалган.

### Баланың тугач та ясаган хәрәкәте мотив булган исемнәр

Баланың тугач та ясаган хәрәкәте мотив булган исемнәр бездә күп түгел. Моңа Болгак, Булгак, Болгар, Болгаш, Иделбакты, Иткосты, Суламыш, Еламыш, Сыктамыш, Исхак (көлде) һ. б. кебек борынгы исемнәрне мисал итеп китерә алабыз.

Борынгы төрки-татар Болгак~Булгак исеменең асылында *булгак* (кулларын болгаучан) сүзе ята. Бу исемне кулларын еш болгаучан ир балага кушканнар дип уйларга кирәк. Татар-мишәрләрдә һәм русларда ул Булгаков фамилиясендә сакланган.

Борынгы Болгаш исеменең этимологиясе *болгау-болгаш* (кулларны болгау) фигыленә кайтып кала. Шушы исемнән Булгашев фамилиясе ясалган.

Болгар этнонимы, тугач та кулларын бишектә болгап ятканга, Болгар исеме кушылган шәхес (Болгар баба) исеменә барып тоташа дип сөйләнә торган риваять бар. Ш. Мәрҗани дә болгар этнонимының асылында *болгау~болгар* сүзеннән ясалган Болгар (Болгар баба) исеме ята дигән карашта тора.

Күренекле тел белгече Латыйф Җәләй үзенең лекцияләрендә (1950—1955 еллар) болгар бабаларыбыз тугач та Идел ягына борылып караган ир балага — Иделбакты, телен чыгарып күрсәткәненә Иткосты исеме биргәннәр дип сөйли иде. Иделбакты исеменең төрдәше Иделбак. Казан татарларында болардан Иделбактин, Иделбаков фамилияләре ясалган.

Тарихчы Һ. В Юсупов XIII—XVIII йөзләргә караган болгар-татар кабер ташы язмаларында баланың тугач та тәүге мәртәбә ясаган хәрәкәтен белдерүче Суламыш, Еламыш (себер татарларындагы синонимы Сыктамыш) исемнәре урын алуын күрсәтә.

Татар антропонимиконында гарәплэрдән кергән борынгы яһүди-гарәби чыгышлы Исхак исеменең бирелү мотивы да шулай ук баланың тугач та ясаган беренче мәртәбә ясаган хәрәкәтенә — мимикасына нисбәтле. Тугач та көлеп җибәргән балага Исхак (көлде) исеме кушканнар (чагыштыр: Көләч, Көлемсәр — борынгы болгар-татар исемнәре). Бу исем дөньякүләм таралышка ия. Руслар-

да — Исаак, Иса, Исай; грекларда — Исааккос, Исаакий, инглизләрдә — Айзак, Айзек, немецларда — Изаак, итальяннарда Изакко һ. б.

### Баланың туу урыны мотив булган исемнәр

Барлык халыкларда да диярлек баланың туу урыны мотив булган исемнәр шактый үзенчәлекле бер лексик-семантик төркем барлыкка китергәннәр.

Борынгы бабаларыбыз күчмә һәм ярымкүчмә тормыш шартларында яшәгән заманнарда бу төркемгә карый торган исемнәребез, башлыча, бала туган елга-су буе атамасына (гидронимга), төбәкнең физик-географик объектларына нисбәтле рәвештә *ялан, тау, үзән, арал, тугай, урман, юл, җәйләү* кебек терминнарга нигезләнеп ясалганнар.

Безнең регионда яшәгән борынгы халыклар (һуннар, хазарлар, кыпчаклар, болгар-татарлар, чувашлар, бортаслар, башкортлар, казахлар, нугайлар һ. б.) тормышында мул сулы иң зур елгаларның берсе булган Идел елгасы аеруча әһәмиятле роль уйнаган. Менә шуңа күрә Идел гидронимы бу халыкларның антропонимиясендә дә чагылыш тапкан.

V гасырда Рим империясе белән көч сынашкан төркиһуннарның легендар юлбашчысы (ханы) Атилла исеме «Иделле, Идел кешесе», ягъни «Идел елгасы буенда туучы (Атилле>Итилле>Иделле) дигән мәгънәгә ия.

Болгар бабаларыбызда Идел елгасы буенда күчеп йөргәндә туган ир балаларга Идел компонентлы исемнәр кушу гадәте булган. Ир балаларга Идел, Иделбай, Иделбәк, Иделле, Иделморат, Иделхан, Иделхуҗа; кыз балаларга Иделбикә, Иделсылу һ. б. кебек исемнәр биргәннәр. Болгар һәм башкортларда Идел (Волга), Чулман иделе (Кама) һәм Агыйдел буендагы җәйләүләрдә туган ир балаларга Иделсабый исемен бирү йоласы булган. Шуның кебек үк, казах һәм башкортларда Җаек елгасы буенда туган ир балаларга Җайыкбай~Яйыкбай, кыз балаларга Җайыкбикә~Яйыкбикә исемен биргәннәр.

*Идел ко*мпонентлы борынгы исемнәр, Казан татарларында Иделбаев, Иделбеков, Иделморатов, Иделханов, Иделхуҗин кебек фамилияләргә әверелеп, безнең көннәргәчә сакланганнар. Татар-мишәрләрдә Иделлиев фамилиясе бар. Урта Азиядә яшәүче татарларда бабаларының

туган җирләре Идел хөрмәтенә кыз балаларга Иделә исемен кушу хәзер дә шактый киң таралган.

Борынгы төрки телдә *арал* сүзе «камыш тугайлы утрау» төшенчәсен белдергән. Кыпчак бабаларыбыз камыш тугайлы утрауда туган ир балаларга Арал, Аралбай, кыз балаларга Аралбикә исемнәре биргәннәр. Башкортларда Аралбай исеме хәзер дә кулланылышта йөри. Бу исемнән татар-мишәрләрдә Аралбаев фамилиясе ясалган. Аралбаев фамилиясе казахларда да бар.

Электә болгар-татарлар, башкортлар, казахлар һ. б. төрки халыклар, язын мал-туар белән яшел җәйләүгә чыккач, җәйләүдә туган ир балаларга Җәйләү ~ Йәйләү, Җәйләүбай ~ Йәйләүбай, кыз балаларга Җәйләүбикә ~ Йәйләүбикә исемнәре кушканнар. Үзәндә туган ир балаларга Үзәнбай, тау буенда туганнарга Таубай, Таубәк, яланда туучыларга Яланбай, Яланбикә, япанда (ачык далада) туучы ир балага Япанчы (диалекталь вариантлары Япай, Яфай, Япи; Казан ханлыгында Нугай һәм Алат юлларында Япанчы (Епанчино) дигән татар авыллары булган), кырда туучы ир балага Кырчы, урманда туучы ир балаларга Урман, Урманчы, Урмантай, Урманбай, Урманша, кыз балаларга Урманҗиһан, утарда туучы ир балага Утарчы, Утарбай исемнәре биргәннәр.

Төрки халыкларда тугайда (елганың борылмалы, түгәрәк үзәнле урынында) туган ир балаларга *тугай* компонентлы Тугай, Тукай, Токай һ. б. исемен кушу гадәте дә бар. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай (Тукаев) фамилиясенең асылында да борынгы төрки-татар Тукай исеме ята. Алим Гафуров төрки телләрдәге Тугай исеме «урман куаклыгы, әрәмәлек» төшенчәсен, ә аның фонетик вариантыннан гыйбарәт Токай ~ Тукай исеме «урманлы җир» мәгънәсен белдерә дип саный. Казахларда Токай, Токас, карачай-балкарларда Токай, хакасларда Тогай, үзбәкләрдә Тогай, Тогайҗан, Тогаймамат, Тогаймирза, Тогаймурад, Тогаймухаммад, Тогайназар, Тогайниез, Тогайкузи, Тогайкул исемнәре бүгенге көндә дә шактый актив кулланылышка ия. Ә Себер татарлары Туктасын, Туктаргали исемнәрен кыскартып, җанлы сөйләм телендә Тукай рәвешле кулланалар.

Әнисе кунакка баргач туган балаларга Кунак, Кунакбай, Кунакбәк, Кунакбикә исемнәре кушканнар.

Электә башлыча терлекчелек белән шөгыльләнеп көн күргәннәр. Мал-туарны яшел азык белән тәэмин итү өчен бер урыннан икенче урынга күчеп йөргәннәр, күчмә тормышта яшәгәннәр. Бер төбәктән икенчесенә күченгәндә

туган балаларга *куч~кучу* сүзе кергән исемнәр биргәннәр: Күчем~Күчүм (бу исем башкортларда һәм алтайлыларда әле дә кулланылышта йөри. Себер һәм Урал татарларында Кучумов фамилиясендә сакланган), Күчеш (татар-мишәрләрдә Кучушев фамилиясендә сакланган), Күчәбай, Күчәбәк, Күчәбикә; Күчәгол, Күчәк, Күчәрбай (диалекталь варианты Күчәй, Кучай. Шуннан Кучаев фамилиясе ясалган. Казан татарларында Күчәрбаев фамилиясе бар), Күчтән һ. б.

Юл-сәфәр йөргәндә юлда туган балаларга *юл, юлчы, сәфәр, йөрек* компонентлы исемнәр кушылган: Юлбакты, Юлбирде, Юлсубай, Юлтай, Юлчыбай, Юлчыбәк, Юлчыгол. Сәфәр, Сәфәрбай, Сәфәрвәли, Сәфәргали, Сәфәргәрәй, Сәфәрхуҗа, Сәфәрҗан, Йөрекбай (соңгысы Пермь татарларында Йөрекбаев фамилиясендә сакланган) — ир-ат исемнәре; Юлбикә, Сәфәрия, Сәфәрбикә, Сәфәргөл, Гөлсәфәр, Йөрекбикә һ. б. — хатын-кыз исемнәре. Хәзер дә самолетта очкан вакытта туган ир балага — Самолет, Ил (Илюшин) маркалы самолетта туган кызга Илия исемнәре бирү очраклары бар.

Баланың кайсы өйдә тууы да исем кушуда мотив булган. Мәсәлән: Ак чардакта («кыек астында бизәп ясалган балконга охшаш янкорма») туган ир балага Акчардак исеме кушылган. Бу исем татар-мишәрләрдә Акчардаков, Акчердаков фамилиясендә сакланган.

Электә болгар-татарлар һәм башкортлар Урал тавы (Урал тау<урау тау) буенда күчеп йөргәндә туган ир балаларга Урал, Уралбай, Уралбәк, кыз балаларга Уралбикә, Уралия һ. б. кебек исемнәр кушканнар. Урал тавы хөрмәтенә кушыла торган Урал, Уралия исемнәре татар һәм башкортларда хәзер дә шактый еш очрый.

Бала туган урынның атамасын аңа исем итеп кушу гадәте казахларда да бар. Мәсәлән, казах акыны Җамбул Җабаевка (1846—1945) көньяк Казахстанда Җамбул тавы итәгендә туганга, Җамбул исеме кушылган. Аның хөрмәтенә 1938 елда Әүлия-Ата шәһәренә Җамбул исеме бирелә. Без биредә ялгызлык исеменең бер төренең икенче төргә әверелүе, күчеше, динамикасы белән очрашабыз.

## Баланың туганда физик (физиологик) халәте мотив булган исемнәр

Баланың тугандагы (физиологик) халәте, бөтен әгъзалары төгәл-тулы, ким яки артык, таза яки ябык, зур яки кечкенә булып тууы балага исем кушуда мөһим бер

мотив исәпләнгән. Тарихи антропонимиконыбызда шушы мотивка нисбәтле рәвештә байтак кына кеше исемнәре барлыкка килгән. Бу төркемгә карый торган борынгы исемнәрне ясауда баланың анатомик-физиологик халәтен тасвирлый торган *төгәл, төз (төзек), таза, арык, тук, тулы, артык, ким, дәү, кече (кечкенә)* сүзләре продуктив булган.

Менә берничә исемнәр тупламы.

Төгәлбай — «барлык әгъзасы да исән-имин ир бала» (Татарстанның Әлки районында Татар Төгәлбае, Рус Төгәлбае дигән авыллар бар).

Төгәлбота — төгәл + бота, ягъни дөя баласы.

Төгәлбуга — төгәл + буга (үгез).

Төзбай — «төз, тулы; барлык әгъзасы да булган бала» (татар-мишәрләрдә Төзбаев ~ Тузбаев фамилиясендә сакланган).

Төзбәк (татар-мишәрләрдә Төзбәков ~ Тузбеков фамилиясендә сакланган). Төзкилде — «төз, барлык әгъзасы да исән-имин бала килде».

Төзтуган, Төзҗан.

Тулымбай ~ Тулбай — «барлык әгъзасы да тулы, исән-имин бала» (Казан татарларында Тулбаев, Толбаев, Себер татарларында Тулыбаев фамилиясендә сакланган. Тулбай — Татарстанның Мамадыш районындагы, Тулыбай — Минзәлә районындагы татар авыллары атамасы).

Тулыбәк ~ Тулбәк (Казан татарларында Тулбәков ~ Тулбеков фамилиясендә сакланган).

Тукбай — «тук, тулы, бөтен бала» (бу исем марилларга да кергән).

Тукбакты, Тукбарс, Тукбирде, Тукбәк, Тукморза.

Туган (ягъни, «тук аш ~ иш»; диалекталь вариантлары Тугыш, Тугиш, Тугуш. Болардан Казан һәм керәшен татарларында Тугашев, татар-мишәрләрдә Тугишев, Тугушев фамилияләре ясалган. Тугаш — Татарстанның Мөслим районындагы татар, Биектау, Питрәч һәм Тукай районнарындагы рус авыллары атамасы).

Тукман (Казан татарларында Тукманов фамилиясендә сакланган), Тукмөхәммәт, Туксолтан, Туксубай, Туксәет, Туктай (Казан татарларында Туктаев фамилиясендә сакланган), Туктимер, Туктуган, Тукхуҗа (татар-мишәрләрдә Тукхузин), Тукчура, Тукшаһ, Тукшәех (диалекталь вариантлары Тукшәй, Тукшай); Төгәлбикә, Төзбикә, Тукбикә, Туксылу һ б.

Баланың туганда барлык әгъзасы да тулы-камил булуын белдерүче исемнәр рәтенә гарәби чыгышлы *камил* (тулы, бөтен, мөкәммәл килгән, һәрьяктан җитеш) һәм

*камал* (тулылык, өлгергәнлек, һәрьяктан җитешкәнлек; кимчелексез, камил) антрополексемалары катнашып ясалган Камил — Камилә, Камилҗан, Камильяр, Бибикамилә, Камиләбану; Камал — Камалия, Камалетдин (диалекталь вариантлары Камай, Камалый ~ Камали, Камкай, Камук, Камуш, Камалюк); Маһикамал, Шәмсекамал, Бибикамал, Нуркамал, Гөлкамал, Шәрифкамал, Әшрәфкамал, Әһликамал, Өммекамал һ. б. кебек исемнәр өстәлгән.

Баланың таза яки арык булып тууы антропонимик пар тәшкил итүче *таза* һәм *арык* сүзләре катнашып ясалган исемнәр белән белдерелгән: Тазабай — Арыкбай, Тазабәк — Арыкбәк, Тазаҗан — Арыкҗан һ. б. Базык — «базык, таза-нык бәдәнле». Бу исем Казан татарларында Базиков фамилиясендә сакланган.

Борында төрки халыкларда, шул исәптән татарларда, *ким* компонентлы Кимекәй, Кимеш, Кимәк, Кимбай, Кимбәк, Кимчура, Кимәч (Татарстанның Актаныш районы Зөбәр авылы халкының Закир бабай Саттаров тарафыннан язылган нәсел шәҗәрәсендә Кимәч исеме бар: Кимәч Колеш улы, Мортаза Кимәч улы һ. б.) исемнәре аяк яки кул бармаклары яки башка әгъзасы җитешсез, ким булган ир балаларга бирелгән.

В. А. Никонов көньяк Себердәге Кемерово шәһәре атамасының нигезендә дә Кимер (ким ир) дигән төрки кеше исеме ята дип карый.

*Ким* сүзенең антонимы булган *артык* сүзе дә төрки халыкларда кеше исеме буларак кулланылышта йөргән. Мәсәлән, үзбәкләрдә һәм казахларда Артык, Артыкбай, Алтыбай, Алтыкай һ. б. исемнәрен берәр әгъзасы артык булган (күбесенчә, кулы яки аягы алты бармаклы) ир балаларга кушу гадәте бар. Алтыбай — электә татарларда аяк яки кул бармаклары алты булып туган ир балаларга кушылган йола исем. Диалекталь варианты Алтый. Татар-мишәрләрдә Алтыбаев, Алтыев фамилияләрендә сакланган.

Баланың дәү яки кечкенә буйлы булып тууы *олы, дәү* һәм *кечкенә* сүзләре (яки күчерелмә мәгънәдә шуңа төгәл башка сүз) катнашып ясалган кеше исемнәре белән белдерелгән: Олыбай, Олыбәк, Олыхан, Дәүбай, Дәүбәк, Дәүбикә, Дәвен (*Дәү* сүзенә антропонимик *-ен* кушымчасы ялгану юлы белән ясалган исем. Авыл картлары Татарстанның Алабуга районындагы Иске Юраш авылына Дәвен карт нигез салган дип сөйлиләр.), Дәвек (*дәү* сүзенә *-ек* иркәләү кушымчасы кушылып ясалган исем. Татарстанның Апас районында татар авылы атамасында сак-

ланган), Дәвеш («Дәү иш». Татар-мишәрләрдә Дәвишев, Девешев фамилияләрендә һәм Татарстанның Апас районындагы Дәвеш авылы атамасында сакланган); Кечкенәиш, Кечеби, Кечекбай, Кечеәмир, Икбакты (борынгы төрки телдә *иг~ик* сүзе «орчык» мәгънәсен белдергән. Орчыктай кечкенә булып туган ир балага Икбакты исемен биргәннәр. Урал һәм Себер татарларына Икбактиев, Ихбахтиев, Екбактиев фамилияләрендә сакланган), Икбикә (орчык бикә, ягъни бик кечкенә булып туган кыз бала.)

Электә татарларда кыска буйлы ир балага Тәбәшек, Тәбәнәк, Тәбәнәч исемнәре бирү гадәте булган. Бу исемнәрдән Тәбәшеков, Тәбәкәчев, Тәбәнәков фамилияләре ясалган. Табанаков фамилиясе русларда да бар.

Татар антропонимикасында гарәпләрдән кергән Мөниф — Мөнифә, Мәмдүд — Мәмдүдә, Тавил — Тавилә исемнәре «озын буйлы, сузынкы, сузан», Касир — Касирә, Сәгыйрә, Ясир — Ясирә исемнәре исә «кечкенә, бәләкәй, кыска; кече» мәгънәсенә ия. Монголлардан кергән Канкай исеме «озын буйлы» мәгънәсен белдерә. Бу исем Е. Пугачевның батыр полковнигы Бәхтияр Канкаев фамилиясендә сакланган.

Мари-татар чыгышлы Кугубай исеме мари телендәге *кугу* (зур) сүзенә татар телендәге бай титулы кушылып ясалган. «Зур бай; зур туган ир бала» дигән мәгънәгә ия. Кугубай исеме мариларда әле дә кулланылышта йөри.

Татарстанның Актаныш районы Куян авылында Кугубай исеменнән ясалган Кугубаев фамилиясен йөртүче гаиләләр бар. Кугубаев фамилиясе Куян авылына килеп төпләнгән татар-типтәрләр составында мари компонентының булуын хәбәр итә.

## Баланың үз этисе булмавы мотив булган исемнәр

Бу төркемгә карый торган кеше исемнәре берничә генә.

Борында татарлар никахсыз хатыннан туган ир балага Тумак, кыз балаларга Тумакбикә исеме кушканнар. Бу исемнәрнең асылында *тумак* (никахсыз туган) сүзе ята. Тумак исеме (Тумак Аллабердеев) Казан өязенең 1602—1603 елларда язылган сан алу кенәгәсендә бар. Казан татарларында һәм татар-мишәрләрдә Тумаков фамилиясендә сакланган. Төрдәше Тунак. Шуннан руслардагы Тунаков фамилиясе ясалган.

Татарлар һәм руслар арасында очрый торган Чумаков (мәсәлән, Татарстанның Әгерҗе районындагы Иж-Бәйкә

дигән татар авылында шушы фамилияне йөртүче гаиләләр бар), украиннарда шактый киң таралган Чумак фамилияләренең асылында Тумак исеменең фонетик варианты булган Чумак яту ихтималы бар.

Чувар~Чуар исеме, мөселман динендәге татар һәм башка диндәге халык вәкиленнән туган ир балаларга, башлыча, әнисе татар булып, әтисе башка дин тотканга күрә никах укылмаган ир балаларга кушылган. Чубар һәм Чубаров антропонимнары русларда да бар (Веселовский С. Б., 1974). Чубар — Татарстанның Биектау районындагы рус, Чубар-Абдул — Азнакай районындагы татар авылы атамасы.

Электә төрки халыкларда Качкын, Качкынбай исемнәре никахсыз туган ир балаларга яисә башка нәсел ыругкабиләдән качып килгән ир-егетләренә кушылган.

## Баланың гаиләдә ни рәвешле пәйда булуы мотив булган исемнәр

Борынгы заманнарда баланың нәсел-ыруда, гаиләдә ни рәвешле пәйда булуы да исем бирүдә бер мотив булып торган. Очраклы табып алынган ир балаларга Табылдык исеме биргәннәр. Яудан алып кайтылган ир балага Яубирде исеме кушылган. Кем дә булса ташлап калдырган ир балага Ташландык, кыз балага Ташландыкбикә исемен куша торган булганнар.

Әнисе бер кияүдән кайтып торганнан соң, икенчесенә барганда артыннан ияртеп алып килгән ир балага (элекке иреннән туган балага) Иярмеш~Йөрмеш исеме тагылган. Бу исем Себер татарларында Ермишев фамилиясендә сакланган. Казан татарлары икенче кияүгә әнисе белән ияреп килгән ир яки кыз балага Килмешәк дип әйткәннәр. Икенче бер ырудан, урыннан, авылдан күчеп килгән кешене (ир яки хатын-кыз булуларына карамастан) Килмешәк дип атау гадәте булган. Этимологик яктан караганда, *килмешәк* (*кил+меш+әк*) һәм *килен* (*кил+ен*) сүзләренең асылында *кил~килү* тамыры ята.

Үз балалары булмаганга, гаиләгә асрамага, угылыкка алынган ир балага Алмыш исеме кушылган. Бу исем Казан татарларында Алмышев, Алмушев фамилияләрендә сакланган.

## Баланың туу вакыты мотив булган исемнәр

Антропонимик системаларда баланың кайсы елда, елның кайсы фасылында, кайсы айда туувы исем бирүдә мөһим фактор исәпләнә.

Борынгы заманнарда төрки халыклар ел исәбен 12 хайван циклыннан торган календарь буенча алып барганнар. Бу циклның еллары *Тычкан, Сыер, Барс, Куян, Ләү* (яки *Аждаһа, Кәлтә, Крокодил), Елан, Елкы, Куй, Мичин* (яки *Маймыл, Керпе), Тавык, Эт, Дуңгыз* исемнәре белән атап йөртелгән. XI йөзнең атаклы галиме Мәхмүд Кашгари язып калдырганча, төркиләр бу елларның һәркайсында бер-бер хикмәт бар дип ышанганнар. Әйтик, Крокодил елы керсә, явым-төшемнең һәм иген уңышының мул булуы көтелгән. Ни өчен дигәндә, крокодил — суда яшәүче хайван. Сыерның сөзешергә хирыслыгыннан чыгып, Сыер елында сугышлар булыр дип сакланганнар. Тавык елында бөртекле ашлык уңарга тиеш булган.

Болгар-татарларда унике хайван циклының теге яки бу елында туган ир балага шул ел атамасын исем итеп бирү гадәте булган. Барс елында туган ир балага Барс, колгына (тычкан) елында туганга — Колгына (Татарстанның Апас районында Колгына дигән татар авылы бар), Тычкан, Тычканбай (башкортларда Сыскан, Сысканбай), эт елында туганга — Нугай ~ Ногай (борынгы монгол-төрки телдә *нокай* — «эт»), дуңгыз елында туганга — Кака (борынгы монгол-төрки телдә *кака* — «дуңгыз»), Какабай һ. б. кебек исемнәр биргәннәр, Кака исеме Татарстанның Зеленодольск районы Мулла иле авылында Кака дигән борынгы нәсел-ыру кушаматына әверелеп безнең көннәргәчә сакланган.

Ел фасыллары атамалары да тарихи исемнәр системасында чагылыш тапкан. Кышын туган ир балага Кышбакты, кыз балага Кышбикә, язын туган ир балага Язбакты, Язбай, Язбәк, Атыяз, кыз балага Язбикә, Язгөл, Бәһар (фарсыча «яз»), Гөлбәһар, җәй көне туган ир балага Җәйбакты, көзен туган ир балага Көзбакты, кыз балага Көзбикә исемнәре кушканнар. Безгә фарсылардан кергән Хазан исеме «көз, көз көне», ягъни «көзен туган ир бала» мәгънәсенә ия.

Ай атамалары турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Хәзерге ел исәбе буенча мартка туры килә торган хәмел аеның исеме иске татар телендә *кузы* (язгы яшь бәрән; куй бәтие) дип аталган. Шул айда туган ир балаларга

Кузы, Кузый, Кузи, Күзәй, Кузыбәк, Кузыбала, Кузыкилде, Кузымкол исемнәре биргәннәр. Бу исемнәрдән Казан һәм Уфа татарларындагы Кузаев, Кузиев, Кузеев, Урал һәм Себер татарларындагы Кузыбаев, Казан татарларындагы Кузимкулов һәм Себер татарларындагы Кузыгилдиев фамилияләре ясалган.

Борынгы төрки-татар Кырлай, Кырлач исемнәре *кырлач ай>кырлай*, ягъни «салкын ай» дигән мәгънәгә ия. Кырлач — кышның иң салкын вакыты, *олы кырлач* январь аена, *кече кырлач* февраль аена туры килә. Идел-Кама болгарларында һәм аларның варислары Казан татарларында кышның иң салкын аенда туган ир балаларга Кырлачай> Кырлай дип исем кушу гадәте (русларда кышкы каты салкыннарда туган ир балага Мороз исемен биргәннәр) булган. Казан артында Алат юлы өстендә Иске Кырлай һәм Яңа Кырлай (хәзерге Тукай-Кырлай) авылларының Казан ханлыгы чорында булулары мәгълүм.

Фәрвәрдин һәм Әсфән — борынгы иран календаренең беренче ае, Абан — сигезенче ае атамасы. Шуларга нигезләнеп Фәрвәр, Фәрвәрия, Әсфән, Абан, Абанчы исемнәре барлыкка килгән. Абанчы исеме Казан татарларында Абанчеев фамилиясендә сакланган. Гарәпчә *сәвер* — апрель аена, *кавәс* ноябрь аена туры килә. Болардан Саур — Саурә, Кавәс ~ Кавис исемнәре ясалган.

Хәзер татарларда аерата актив кулланылышка ия булган Ләйсән ~ Ләйсәнә ~ Ләйсәния исемнәре гарәпчә *нисан* «юмарт» сүзенә барып тоташа. Борынгы Сирия календаре буенча ул — явым-төшемгә юмарт апрель ае атамасы. Шул айда туган кыз балаларга кушыла торган йола исем. Беренче шифалы яңгырны да бездә *ләйсән яңгыр* диләр.

Ислам дине белән бәйле рәвештә татарлар ай елын (һиҗри елны) һәм гарәпчә ай исемнәрен кулланылышка алганнар. Шул ай атамаларының күбесен балаларына исем итеп тә биргәннәр: Мөхәррәм (ай елының беренче ае исеме), Сәфәр (икенче ай исеме), Рабигуль әүвәл (өченче ай исеме), Рәбигуль әхир (дүртенче ай исеме) Рабига, Рәҗәб (җиденче ай исеме) — Рәҗибә, Шигъбан (сигезенче ай исеме), Рамазан (тугызынчы ай исеме), Шәвәли (шәүвәл — унынчы ай исеме), Зөлхиҗҗә (уникенче ай исеме) һ. б.

## Баланың кайсы көнне тууы мотив булган исемнәр

Антропонимик системада баланың кайсы елны, елның кайсы фасылында, кайсы аенда тууы гына түгел, бәлки кайсы көнне (бәйрәм көнне, туй көнне, базар көнне, изге көндә һ. б.) тууы да исем кушуда мөһим бер йола-мотивны барлыкка китергән.

Идел-Кама болгарлары һәм Казан татарлары бәйрәм көнне туган ир һәм кыз балаларга *бәйрәм* сүзе катнашып ясалган кеше исемнәре кушканнар: Бәйрәм, Бәйрәмбай, Бәйрәмгали, Бәйрәмгол, Бәйрәмхан, Бәйрәмхуҗа, Бәйрәмша, Бәйрәмбану, Бәйрәмбикә, Бәйрәмсылу һ. б.

Идел-Кама болгарларында сабан туе, җыен кебек язгы хезмәт бәйрәмнәреннән тыш, Багана бәйрәме, Чук бәйрәме кебек бәйрәмнәр дә булган.

Идел-Кама болгарларында, чувашларда һәм керәшен татарларында кеше үлеп бер ел үткәч, аны искә алып, каберенә багана утырту йоласы башкарылган. Бу көн «Багана бәйрәме» дип аталган. Шушы йоланы башкару Татарстанның Әлмәт районы Сарапалы авылы керәшен татарларында әле дә күзәтелә. Шушы көнне туган ир балаларга Багана, Баганай исемнәре бирелгән. Идел-Кама болгарларында Сәет Баганай исемле шәхес булган. Бу исем Баганаев, Паганаев фамилияләрендә һәм Татарстанның Чистай районындагы Татар Баганасы һәм Мордва Багана авыллары атамасында сакланган.

Чук бәйрәме керәшен татарларында хәзергәчә сакланып калган. Ул Петров деньгә яки Троицага кадәр үткәрелә торган мәҗүси бәйрәм (яңгыр теләү бәйрәме). Чук (күплек, байлык, муллык, уңыш, яңгыр теләү) бәйрәме көнне кешеләр урамнарга чыгып, бер-берсенә су сибешкәннәр, кырга чыгып ботка пешереп ашаганнар, яңгыр (муллык, уңыш) чакырганнар. Чук бәйрәме чувашларда һәм удмуртларда да булган. Болгар-татарлар Чук бәйрәме көнне туган ир балага Чук исеме яки *чук* компонентлы башка исем кушканнар. Татарстанның Саба районы Шекше авылында яшәүче Гарәфша бабай Батыршиннарның унике буынны эченә алган шәҗәрәсе Чук бабайдан башланып китә: Чук ⟶ Мөкәй ⟶ Габделкәрим ⟶ Габделмоталлап ⟶ Габделмәннаф ⟶ Габдерәшит ⟶ Надырша ⟶ Батырша ⟶ Фәйрүша ⟶ Әхмәтша ⟶ Гарәфша ⟶ Гаделша. Казан татарларында Чук исеменнән Чукин, Чуков фамилияләре ясалган. Татарстаннан Әгерҗе районы

Иж-Бубый авылында Чуков фамилиясен йөртүче гаиләләр бар.

Чук бәйрәме көнне туган ир балаларга *чук* антрополексемасы катнашып ясалган Чукай, Чукан, Чукбай, Чукгали, Чукчы, Чуклы, Чукхан кебек исемнәр дә кушканнар. Мариларда Чукай, Чукачай, Чукчы исемнәре соңгы вакытларга кадәр кулланышта йөргән. Бу исемнәрдән Казан татарларында һәм керәшеннәрдә Чугаев, Чукаев, Чуканов, Чаханов, Чуклиев, Чуклин, Чукханов, Чукчин фамилияләре ясалган. Чукаев, Чукханов, Чуканов, Чуханов фамилияләре русларда да бар. Чукан исеме 1773—1775 елларда Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар кузгалышы турындагы татарча документларда очрый. Элекке Казан губернасы Лаеш өязендә Чукай дигән татар авылы булган. Бу авыл хәзер Татарстанның Балык Бистәсе районында. Исеме, нечкә әйтелеш алып, Чүкәй дип йөртелә.

Әби-бабаларыбыз туй көнне туган бала бәхетле, шатлык-сөенечле, мул ризыклы була дип ышанганнар. Менә шуңа туй көнне туган ир һәм кыз балаларга составларында *туй* сүзе булган исемнәр кушканнар: Туй, Туйбак, Туйбакты; Туйбикә, Туйсолтан, Туйсылу һ. б.

Идел-Кама болгарларында сабан туе язгы чәчү-сабан эше беткәннән соң уздырыла торган иң зур бәйрәмнәрнең берсе була. Сабан туен традицион рәвештә хәзер дә зур бәйрәм итеп үткәрү Идел-Урал регионында яшәүче төрки халыклардан татарларга, чувашларга һәм башкортларга хас. Болгар-татарлар һәм чувашлар сабан туе көнне туган ир балаларга Сабантуй яки Акатуй (чувашча *акатуй* — сабантуй) исеме кушканнар. Акатуй исеменнән керәшен татарларында Акатуев, Акатиев фамилияләре ясалган.

Борынгы Иранда яңа ел бәйрәме Нәүрүз дип аталган. Ул «яңа көн, яңа елның беренче көне (яз бәйрәме)» дигән мәгънә белдерә. Язын көн белән төннең тигезләшкән вакыты 21 нче мартка туры килә. Иске татар халык календаренда ул яңа ел бәйрәме булып исәпләнә. Шушы көнне туган балаларга Нәүрүз дип яки Нәүрүз компонентлы исемнәр кушылган: Нәүрүз, Нәүрүзбай, Нәүрүзбәк, Нәүрүзгали, Нәүрүзмөхәммәт (диалекталь варианты Нәүрүзмәт, шуннан Наурузметов фамилиясе ясалган), Нәүрүзхан, Нәүрүзым (Казан татарларында Наурузимов фамилиясендә сакланган); Нәүрүзбикә, Нәүрүзсылу һ. б.

Ислам дине йогынтысында болгар-татарларда атна яки җомга (җыелу көне) изге көн булып саналган. Борында фарсы чыгышлы атна сүзе «җиде тәүлек» мәгънәсендә дә, «җомга көн» мәгънәсендә дә кулланылган. Әле хәзер дә

татар теленең көнбатыш (мишәр) диалектында, урта диалекталь Тау ягы сөйләшләрендә пәнҗешәмбе көнне «кич атна», җомга көнне «атна көн», дип, ә Урал татарлары әдәби телдәге атна сүзен нечкә әйтелеш белән «әтнә», пәнҗешәмбе көнне «кич әтнә» яки «әтнә кич» дип атыйлар.

Борынгы заманнарда татарларда атна (җомга) көнне туган балаларга шул көн исемен кушу йоласы булган. Әтнә, Әтнәгол, Әтнәбай, Атнакай, Азнакай, Атнакилде, Атнахуҗа, Атнагали, Атнамөхәммәт, Атнаш һ. б. кебек ир-ат; Атнасолтан, Атнасылу, Атнаҗамал һ. б. дигән хатын-кыз исемнәре әнә шул йолага нисбәтле рәвештә барлыкка килгәннәр.

Борынгы гадәт-йола буенча, *атна көн* термины урынына гарәп теленнән кергән *җомга* термины кулланыла башлагач та, татарларда шул көнне туган балаларга җомга (диалекталь әйтелештә *җома* яки *йома*) сүзен кертеп исем бирү дәвам иттерелгән: Җомгабай, Җомагол, Йомагол, Җомахуҗа, Йомадил, Йомгасалих, Йомахан; Йомабикә, Йомасолтан, Йомасылу һ. б.

Республикабызның Арча районындагы Бәрәскә авылы атамасының килеп чыгышы Бәрәскә дигән борынгы кеше исеме белән бәйләнешле. Грек телендә *параски* сүзе «җомга көн» мәгънәсен белдерә. Хазарларга *бараски* (җомга көн) сүзе яһүд дине аша килеп кергән. Әрмән-кыпчак, карачай-балкар һәм караим телендә пәнҗешәмбе көн «кичи бараски», ә җомга көн *«улу бараски»* дип атала. Караимнарга да «җомга көн» төшенчәсен белдерә торган бараски (Прасковья көне) сүзе яһүд дине аркылы грек теленнән килеп кергән. Кавказ-иберия телләренә карый торган чечен, черкас, кабардин, грузин һәм адыгей телләрендә бараски сүзе «җомга көн» дигәнне белдерә.

Русларга греклардан кергән Прасковья исеме дә «әзерлек, бәйрәм алды; җомга көн» (борында бәйрәм көн булып шимбә саналган) мәгънәсенә ия. Җомга көн культы белән бәйләнешле исемнәрдән Атна, Әтнә, Әтнәхуҗа, Атнагол, Азнакай, Җомагол, Җомабикә һ. б. исемнәрнең иске татар телендә кулланылышта йөрүен искә төшерик.

Борынгы заманнарда хазарлар Идел буйлап мал көтүләре белән язын төньякка күтәрелә, ә көз җитү белән көньякка Түбән Иделгә кайтып китә торган булганнар. Хазарлар яки Хазар каганлыгы составында булган болгарлар Бараски (җомга көн) дигән кеше исемен Казан елгасы буйлап утырган авыл атамаларына эверелдергәннәр һәм алар безнең көннәргә кадәр килеп житкәннәр (Югары Бәрәскә, Түбән Бәрәскә — Арча районындагы татар авыл-

лары). Димәк, Бәрәскә атамасы ерак гасырлардан безгә шактый кызыклы тарихи-лингвистик мәгълүматлар хәбәр итә. Бәрәскә авылы янындагы «утлам җире» дигән болын исеме дә хазар яки болгарлардан ук килә торган атама булырга тиеш. Мал-туарны утлатып, ашатып йөри торган көтүлекне алар «утлам» дигәннәр. Бу микротопонимның асылында *ут (үлән)* дигән борынгы төрки сүзе ята. Ул бездә *утлык, утлау, сарут, чәнеч уты* һ. б. кебек махсус терминнарда һәм үлән исемнәрендә сакланып калган.

Бәрәскәнең Казан артындагы бик борынгы татар авылларыннан берсе булуы да югарыда әйтелгән фикерне куәтли. Тарихи чыганаклар буенча бу авылның Казан ханлыгы чорында булуы билгеле.

Бәрәскә авылында туып үскән Госман Әхмәтҗанов, авыл картларының сөйләвенә таянып, әлеге авыл исеменең килеп чыгышы турында безгә мондый риваять сөйләде.

Бәрәскәнең утырган урыны элек башка җирдә, тау өстендә булган. Байчыга дигән авылдан Ибраһим бай җирләрне икегә аерып бүлгән. Шуннан Бәрәскәнең бер өлеше түбән якта, ә икенче өлеше югары якта калган. Авылның түбән очын «Түбән авыл», югары очын «Югары авыл» дип атап йөртә башлаганнар. Түбән авыл белән Югары авыл гел тату гына яшәмәгәннәр. Алар арасында җир өчен, чәчүлек, көтүлек һәм болын өчен низаг чыгып, ызгышбәргәләшүләр дә булып торган. Шундый низаг вакытында Түбән авылныкылар: «Бәр аска, бәр аска» дип, ә Югары авылныкылар «Бәр өскә, бәр өскә» дип кычкыралар. «Бәр аска» дип кычкырудан Бәрәскә авылының исеме килеп чыккан, имеш».

Болай аңлату — Бәрәскә авылы исемен охшаш яңгырашлы сүзтезмәгә бәйләп аңлатуга, ягъни халык этимологиясенә ачык мисал булып тора.

Дүшәмбе көнне туган ир балаларга Дүшәмбай, кыз балаларга Дүшәмбикә дигән исемнәр дә кушканнар.

Баланың тәүлекнең кайсы вакытында тууы да антропонимиядә чагылыш таба. Төнлә туган ир балага Төнгатар (төн катар; төн уртасы җиткәндә, төн катканда туган ир бала мәгънәсендә), көндез төш вакытында туган кыз балага Өйләбикә, кичке эңгер-меңгер вакытында туган ир балага Ахшам, Шәфәкъ исемнәре кушу гадәте булган.

Татар антропонимиконына гарәплләрдән кергән Зоха исеме (төш вакыты; көннең беренче яртысы), Гаши — Гашия (кич), Зәбил — Зәбилә (көннең кичке ягы), Зөлмәт — Зөлмә (бик караңгы төн, караңгылык), Зөлфәт (таң алды), Сәхәрия (гарәпчә *сәхәр* «таң ату, сәхәр вакыты» сү-

зеннән), Сәхәрбикә, Сәхәрбану, Сәхәрбәнат, Яум, Яуми (көн, көндезге) исемнәре барысы да йола исемнәр. Соңгысы Яумов, Яумев, Яумиев, Яумин фамилияләрендә сакланган. Фарсылардан кабул ителгән Руз-Руза исемнәре — «көн, көндез», Наһап исеме «көн үзәге, төш вакыты» дигән мәгънәгә ия.

## Бала туганда һава торышы мотив булган исемнәр

Татарларда бу төркемне тәшкил итә торган кеше исемнәре һава торышын, атмосфера күренешләрен белдерә торган *аяз, чуак, буран, томан, яңгыр, кар, кырпак, тамчы, яңгалыч* (салават күпере), *җил* һ. б. кебек метеорологик терминнар нигезендә формалашканнар. Хәзер шундый исемнәрне карап үтик.

*Таң* — матурлык, яшьлек, яңа туар көнгә өмет, бәхет көтү, матур киләчәк символы. Татар халык җырларында таң, таң алды, таң ату вакыты һәрчак яхшыга юрала, ул хәерле вакыт, бәхетле матур киләчәккә өмет итеп карала.

Татар антропонимиконында таң лексемасына нигезләнеп ясалган байтак кына ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре бар. Аларның күбесе таң алдыннан яки таң атканда туган балаларга кушылган: Таң, Таңатар, Таңатмыш, Таңбулат, Таңбаты, Таңгатар, Таңкилде, Таңиш (таң ише), Таңкуәт, Таңкай (Казан татарларында шул исемнән Танкаев, Таңгаев фамилияләре ясалган), Таңташ (татар-мишәрләрдә Таңташев, Танташев фамилияләрендә сакланган), Таңчура (шуннан Танчурин, Танчуров фамилияләре), Таңчираг (таң чырасы, яктысы), Таңсызар (сызылып таң атканда туучы), Таңчы, Таңчыбай, Таңгачы (Таңгачев, Таңгачиев фамилияләрендә һәм Татарстанның Лаеш районындагы Тангачи дигән рус авылы атамасында сакланган), Танай (таңгы ай; Карачай-балкарларда Танай исеме әле дә кулланылышта йөри. Танай — Татарстанның Зеленодольск районындагы татар, Алабуга районындагы рус авылы атамасы. Татарларда һәм русларда шул исемнән ясалган Танаев фамилияләре бар. Казан губернасының 1834 елгы Ревизские сказки материалларында Казан артындагы Олы Бәрәскә авылында Шәфигулла Танаев дигән шәхеснең яшәве теркәлгән), Таңморза, Таңсары (шуннан Таңсаров, Таңсарин фамилияләре ясалган), Таңмөхәммәт, Таңсолтан, Таңнур, Актаң, Илтаң, Иштаң; Таңбикә, Таңчыбикә, Таңгөл, Таңзифа, Таңнура, Таңсылу (башкортларда Таңһылыу), Айтаң, Алтаң һ. б.

Марилар болгар-татарлардан Танай, Танатар, Танатмыш, Танаш, Тангуат (Таңкуәт), Танияр, Танлыбай, Тансар, Тансыбай һ. б. ш. ир-ат исемнәрен кулланылышка алганнар (Черных С. Я., 1978).

Электә төрки халыкларда, шул исәптән болгар-татарларда, бала туганда һаваның торышына, тәүлекнең нинди халәттә булуына (яңгырлы, буранлы, карлы, аяз, кырпаклы, җилле, яшенле һ. б.) карап та, бу бала туган көнне тәңре һаваның шундый торышын үзе җибәргән дип ышанып, шул халәт-күренешне изге итеп санап, исем кушканнар.

Буранлы көнне туган ир балага Буран, Буранбай, Буранбәк, Бурангол, Буранхан, Бураншa, Буранчы һ. б. исемнәр биргәннәр. Бу исемнәр татарларда Буранов, Буранбаев, Бурангулов, Буранбеков, Бураншин, Буранханов, Буранчиев, Буранчин фамилияләрендә сакланган. Буранлы көнне туган кыз балаларга Буранбикә исемен кушканнар.

Кышын (көзен яки язын) кар күп булып яуган көнне туган ир балага — Карлы, Карлыхан, Карьяуды һ. б., кыз балаларга исә Карлыбикә, Карлысылу һ. б. кебек исемнәр биргәннәр. Бу исемнәрнең кайберләре, географик атамаларга әверелеп, безнең көннәргәчә килеп җиткән. Татарстанның Чүпрәле һәм Буа районнары аша Карлы дигән елга агып уза (Зөя елгасына коя), Буа районында — Карлы (русча Мещеряково), Чүпрәле районында Карлыбаш дигән татар авыллары бар. Башкортстанның Белокатай районында Карлыхан, Чакмагыш районында Карьяуды исемле авыллар бар.

Томанлы көнне туган ир балаларга Томан, Томанхан, Томанша, Томанбай, Томанбәк исемнәре кушылган. Томан исеменең бирелү мотивы хакында Әбелгази Баһадур ханның «Шәҗәрәи төркмән» әсәрендә түбәндәгеләрне укыйбыз: «Огуз иле Куркутка әйтте: «Малайга матур исем бир»,— диде. Коркут ата әйтте: «Исеме Томан хан булсын» Халык матуррак исем табуын үтенде. Коркут ата: «Моннан да матур исем юк»,— диде. Малай томан вакытында туды, шуның өчен Томан дип атадым.— «Мин аңа бәхетле язмыш телим. Томан озак тормый, тарала. Аннары кояшлы, аяз көн була. Томанны мин малайның яшьлегенә охшатам, аннан соң килгән якты көн аның бәхете һәм озын гомеренә тиң булсын».

Томан исеменнән керәшен татарларында Томанов (Туманов), Томанин (Туманин) фамилияләре ясалган. Русларда Туманов, Туманский фамилияләре бар. Казан татар-

ларында Томанша (Томаншаһ) исеменнән Томаншин (Туманшин) фамилиясе барлыкка килгән.

Татар антропонимиконында асылларында күк йөзенең болытсыз, ачык булуын белдерүче *аяз* термины яткан кеше исемнәре дә бар: Аяз, Аязгает, Аязгол, Аязкол, Аязхан, Аязҗан һ. б.

Аяз исеме «зиһенле, зирәк, ачык хәтерле» мәгънәсенә дә ия. Баланың гомере якты, кайгы-хәсрәтсез, бәхетле булсын дигән теләктән чыгып кушыла. Борында төрки халыкларда Аяз исеме чибәр колларга бирелгән. Төрдәше Аязгол (Кашгари). Казан ханлыгында Алат юлында Аяз дигән татар авылы булган. Аязгает исеменнән ясалган Аязаетов фамилиясе Казан шәһәренең 1916 елда чыгарылган адрес-календаренда бар.

Борынгы төрки халыкларда Яг (йагмур, яңгыр) изге рух, игелек-яхшылык эшләүче илаһи көч булып саналган. Борынгы төрки телдә *яг* сүзе: 1) май, җир; 2) яву, төшү (яңгырга, карга карата); 3) корбан чалу төшенчәләренә ия булган. Бер-берсеннән ерак торган әлеге мәгънәләр яңгыр (ягмур) терминында сизелерлек якыная. Терлек асрау белән шөгыльләнүче борынгы күчмә төрки кабиләләр сөтне изге ризык санаганнар. Мал-туар көрәйсен һәм сөтне мул бирсен өчен, яңгыр сорап тәңрегә ялварганнар, корбан чалганнар. Менә шуннан яг — һәм яңгыр, һәм күк яхшылыгы, игелеге. Җәй коры елларда татар авылларында яңгыр теләп күмәкләшеп яңгыр боткасы пешереп ашау, шуннан соң кешеләрнең бер-берсенә чиләкләп су сибешү күренеше һәм «яңгыр келәве» әлеге борынгы төрки мәҗүси ышанулар һәм ырымнар белән аваздаш.

Төрки халыкларда яңгыр — байлык, муллык, бәхет; яхшылык, изгелек, игелек символы. Электә яңгырлы көнне туган бала әлеге уңай сыйфатларның барысына да ия була дип каралган һәм аңа «яңгырлы» исем биргәннәр: Ямгур, Ямгурчы ~ Яңгырчы. «Писцовая книга Казанского уезда 1602—1603 годов» (Казань, 1978) дигән тарихи чыганакка караганда, Казан татарларында XVI—XVII йөзләрдә Яңгырчы исеме актив кулланылышта йөргән. Ямгурчин, Ямгурчиев, Янгурчин, Янгурчиев фамилияләрендә безнең көннәргәчә сакланган), Яңгырбәк, Яңгырбикә, Яңгырбай, Яңгырхан (Оренбург өлкәсе Абдуллин районы Чаганалы авылында яшәүче татар-мишәрләрдә Яңгырханов фамилиясендә сакланган) һ. б.

Болгар-татарлардан марилар — Яңгырай, Янгурчи, удмуртлар Янгур, Янгурчы исемнәрен кулланылышка алган-

нар. Яңгырчы — Татарстанның Балтач районындагы удмурт авылы атамасы.

Исеме татар телендә *«яшен»* һәм *«аҗаган»* мәгънәләренә ия булган *елдырым* сүзенә нигезләнеп Елдырым дигән ир-ат исеме ясалган.

Яңгыр явып узганнан соң, кояш чыккач күк гөмбәзендә барлыкка килә торган *салават күперен* ерак бабаларыбыз изге, илаһи бер күренеш дип санаганнар. Салават күперен, җәя кебек бөгелгән кылычка охшатып, *яңгалыч ~ яңгылыч (яң — «җәя» + гылыч ~ кылыч)* термины белән атаганнар. Борынгы төрки телдә «җәя» мәгънәсендә кулланылышта йөргән *янгы* сүзе хәзерге башкорт телендә *йан* (җәя) формасында сакланган. Карачай-балкар телендә *яңгылыч* сүзе хәзер дә «салават күпере» мәгънәсендә кулланыла. Борынгы төрки халыклар, шул исәптән татарлар, күк йөзендә яңгалыч — «салават күпере» булганда туган ир балага Яңгалыч ~ Яңгылыч исеме биргәннәр. Бу исем Янгалычев, Янглычев һәм Енгалычев фамилияләрендә безнең көннәргәчә сакланган. Мондый фамилияләр Башкортстан һәм Сергач мишәрләрендә, керәшен татарларында бар.

Көзен җирне катырып, ап-ак булып *кырпак* төшкән төнне туган ир балага Кырпак исеме биргәннәр. Шушы исемнән татар-мишәрләрдәге Кырпаков фамилиясе ясалган.

«Аяз көн» төшенчәсен белдерә торган *чуак* термины катнашып Чуак, Акчуак исемнәре ясалган. Бу исемнәрне бала чуаклы (аяз) көнне туганда яки аның гомер юлы аяз, болытсыз булсын, кайгы-хәсрәт күрмәсен, дип кушканнар. Казан татарларында Чуваков, Акчуваков фамилияләрендә сакланганнар.

Тамчы, Тамчыкай, Тамчыбай, Тамчыбәк, Тамчыбикә, Тамчысылу, Тамчыгол, Тамчыхан һ. б. кебек *тамчы* компонентлы борынгы исемнәр язын, кояш карап, тамчылар тама башлаганда туган балаларга кушылган. Бу исемнәрдән Тамчин, Тамчыбаев, Тамчыбеков, Тамчыголов, Тамчыханов кебек фамилияләр барлыкка килгән.

Тарихи антропонимиконыбызда, *җил* метеорологик терминына нигезләнеп, Җилгелде ~ Җилкилде (җил кебек җитез, хәрәкәтчән бала килде, туды яки җилле көнне туды), Җилдәр (җитез, тиз), Җилкәй исемнәре ясалган һәм кулланылышта йөргән. Җилгелде — Татарстанның Арча районындагы татар авылы атамасы.

Кыргызларда хәзер дә кулланылышта йөри торган Давыл исеме бар. Чыңгыз Айтматовның «Буранлы станциясе» романындагы бер персонажы Давыл исемен йөртә.

## Баланың туу тәртибе мотив булган исемнәр

Гаиләдә баланың ничәнче булып туувы исем кушуда шулай ук роль уйнаган, исем кушуда бер мотив булып торган. Башлыча гаиләдә ир яки кыз баланың беренче, баш бала булып туувы, уртанчы яки соңгы, төпчек бала булуы исемдә ассызыкланган.

Гаиләнең беренче булып туган баш балаларына *тәүге, баш, ал* сүзләре катнашып ясалган исемнәр кушылган: Башбакты (баш, өлкән, беренче ир бала туды). Бактыбаш, Башбүре (баш бүре, ягъни өлкән ир бала; керәшен татарларында Башбурин, Башбуров фамилияләрендә сакланган), Баштай, Башбәк, Башбикә; Тәүгебай (гаиләдә тәүге, беренче булып туган бай, ир бала), Тәүгегилде~Тәүгилде, Тәүей (тәүге, беренче бала; татар-мишәрләрдә Тәвиев, Тәбиев~Табиев фамилияләрендә сакланган), Тәүгебәк, Тәүгебикә, Тәүләкән (тәүлә, тәүге хан; башлап, беренче булып туучы хан~кан~кән), Тәүгеморза; Албакты (алгы, беренче бала бакты туды; Албактин фамилиясендә сакланган. Албакты исеме марыйларда әле дә кулланылышта йөри), Алгай (алгай, алгы, беренче, әүвәлге ир бала. Төрдәшләре — Алгач, Алгаш. Алгай — Татарстанның Мамадыш районындагы татар авылы атамасы), Алгилде, Алдан (алдан, беренче булып туучы — *Шайхулов А. Г.*, 1978), Алтуган, Алкай (Алкаев һәм Алкин фамилияләрендә сакланган), Алхуҗа (алдан, беренче булып туучы хуҗа) һ. б.

Гарәби чыгышлы Вахит, Әхәт (беренче, берәү), Әүхәди (беренче, тәүге), Сания (икенче), Санибай, Санихан, Саниәхмәт, Салисә (өченче) һ. б. кебек исемнәрдән тыш, төрки-татар чыгышлы Икәч (икенче бала), Өчтәк (өченче бала), Дүртәк (дүртенче бала), Биштәк (бишенче бала), Алтыш (алтынчы бала), Җидебай (җиденче бала), Сигезәк (сигезенче бала), Тугыз, Тугызай, Тугызбай (тугызынчы бала), Тугызбәк һ. б. кебек ир-ат исемнәре дә кулланылышта йөргән. Монгол чыгышлы Куран исеме «өч, өченче» дигән мәгънәгә ия. Гаиләдә өченче булып туган ир балага кушыла торган бу исем татар-мишәрләрдә Куранов фамилиясендә сакланган. Бу фамилия русларда да бар. Фарсы генезислы *чар* (дүрт) сүзенә *-ыш* кушымчасы ялганып ясалган Чарыш исеме гаиләнең дүртенче ир баласына бирелгән. Бу исем Казан татарларында Чарышев фамилиясендә сакланган.

Гаиләнең уртанчы булып туган ир баласына Уртабай исемен кушу гадәте булган. Бу исем Урал татарларында (мәсәлән, Пермь өлкәсе Барда районында) Уртабаев фамилиясендә сакланган. Гарәпләрдән кергән Миян исеме дә «уртанчы, арадагы» дигән мәгънә белдерә.

Гаиләдәге беренче ир яки кыз баладан соң дүрт-биш ел вакыт узгач, ягъни шактый ара ясап, *арадаш* булып туган ир балага Арадаш~Ардаш исеме кушылган. Казан татарларында Ардашев фамилиясендә сакланган, бу фамилия русларда да бар.

Ялгаш исеме, ялгаучы, дәвамчы, ягъни ата-ана гомерен дәвам иттерүче, ялгап алып китүче ир бала дигән мәгънәгә ия. Берсе артыннан икенчесе озак тормастан туган, нәүбәттәге ир балага да шушы исем кушылган.

Гаиләнең төпчек, соңгы баласына аның төпчек, соңгы, кече бала булуын белдерә торган *абалак, азак, ахыр, кинҗә* (төпчек бала), *кече~кечек* һ. б. сүзләр катнашып ясалган исемнәр бирелгән.

Абалак исеме «кечкенә малай, төпчек ир бала» дигән мәгънәгә ия. Бу исем Казан татарларында Абалаков фамилиясендә сакланган. Диалекталь вариантлары Аблак, Абалай, Аблай (болардан Аблаков, Абалаев, Аблаев фамилияләре ясалган), Абалач. Төмән өлкәсе Табул районында Абалак дигән рус-татар, Татарстанның Алабуга районында Абалач исемле татар авылы бар.

Азак — гаиләдә иң азактан туган, төпчек ир балага кушыла торган йола исем. Казан татарларында Азаков фамилиясендә сакланган. Нечкә әйтелеше — Әзәк. Татарстанның Арча районында Югары Әзәк һәм Түбән Әзәк дигән татар авыллары бар. Азов шәһәре һәм диңгезе атамасының асылында да төрки Азак~Азаг~Азау (чагыштырыгыз: *азау теш* —иң соңыннан чыга торган, авыз куышлыгындагы соңгы тешләр, акыл тешләре) исеме ятса кирәк.

Борынгы төрки телдә «төпчек бала» төшенчәсен белдерү өчен кулланылган *кинҗә* (диалекталь вариантлары *кинтә, кинчә*) сүзе катнашып тарихи антропонимиябездә байтак кына исемнәр барлыкка килгән: Кинҗә, Кинҗәбай, Кинҗәбулат, Кинҗәбәк, Кинҗәгали, Кинҗәгол, Кинҗәкәй (Кинзекиев фамилияләрендә сакланган), Кинҗәморат, Кинҗәморза, Кинҗәнур, Кинҗәсолтан, Кинҗәхан, Кинҗәхмәт; Кинҗәбану, Кинҗәбикә, Кинҗәгөл, Кинҗәсылу һ. б., Кинйә, Кинйәбай, Кинйәбулат, Кинйәгол, Кинйәкәй, Кинйәсолтан, Кинйәбикә исемнәре башкортларда әле дә кулланылышта йөри (Кусимова Т. Х., 1982).

*Кече~кечек* сүзе катнашып ясалган Кечек (Казан татарларында Кучуков фамилиясендә сакланган), Кечекбай (Урал татарларында Кучубаев фамилиясендә сакланган), Кечебай, Кечеккол, Кечеби, Кечеәмир һ. б. кебек борынгы исемнәр дә гаиләдәге төпчек ир балага кушылган.

Гарәби чыгышлы *ахир* (ахыр, соң), *хәтем* (тәмамлау, нәрсәнең дә булса соңгы, нәтиҗәсе, ахыры; соңгы бала), *әнҗам* (ахыргы, азаккы; йомгак, нәтиҗә) сүзләре катнашып та гаиләнең ахыргы, соңгы, төпчек баласы булуын белдерә торган Ахир, Ахирьяр~Ахияр; Хәтим — Хәтимә, Мирхәтим, Әнҗам — Әнҗамия һ. б. исемнәр ясалган һәм урта гасырларда татар антропонимиконына кабул ителгән.

## Бала туганчы этисе яки тугач әнисенең үлүе мотив булган исемнәр

Болгар-татарларда борынгы заманнарда ук ир яки кыз бала туганчы этисе яки тугач та озак тормастан этисе яисә әнисе үлсә, әлеге сабыйга Бүләк дигән яки *бүләк* сүзе кергән исем бирү йоласы булган: Бүләк, Байбүләк, Бүләкбай, Бүләкбәк, Бүләккәй, Бүләкбикә, Бүләкгәрәй, Бүләкбирде, Бүләккол, Бүләкҗан, Ишбүләк, Ирбүләк, Акбүләк, Гөлбүләк, Бүләкгөл һ. б. Мондый бала этисе яки әнисе бүләге итеп саналган. Бу йола башка халыкларга да хас. Шушы йола тәэсирендә гарәпләрдә «бүләк» мәгънәсенә ия Гата, Гатият, Инәм, Ибәт (Һибәт), Наил, Нафил, Туфаил, Төхфәт кебек ир-ат, Гатия, Һибә, Наилә, Нәфилә, Һәдия кебек хатын-кыз; фарсыларда Нияз, Нияза һәм Ниязия исемнәре барлыкка килгән. Бу исемнәр татар теленә кабул ителгәч, антропонимик синонимик рәтләр барлыкка килгән: а) Бүләк — Гата — Инам — Ибәт — Наил — Нәфил — Туфаил — Төхфәт — ир-ат исемнәре; б) Бүләк — Гатия — Наилә — Нәфилә — Һибә — Мәүһибә — Һидия; Бүләкбану — Һәдиябану — Бүләкбикә — Һәдиябикә — хатын-кыз исемнәре.

Татарлар этисе үлгәч туган ир балага, этисе төсе итеп, Истәлек, Ядкарь~Ядегәр, Варис, Мирас, Ирас (мирас калдыру), туганда яки тугач та озак тормастан әнисе үлгән кыз балага, әнисе истәлеге итеп, Хәтирә (истәлек, ядкарь), Варисә, Тәскирә (ядкарь, истәлек; таныклама), Мәүрүзә (мирас булып калган) һ. б. кебек исемнәр кушканнар.

Иске татар теленә удмурт теленнән кергән *кузьым* «бүләк» (татарча әйтелештә *кужәм*) сүзенә татар телен-

дәге кол титулы кушылып Күҗәмкол дигән ир-ат исеме ясалган һәм кулланылышта йөргән. Бу исем төрки-татар чыгышлы Буләккол исеме белән бердәй мәгънәгә ия. Күҗәмкол исеме Казан татарларында Кузямкулов фамилиясендә сакланган. Әлеге фамилия Казан губернасының Лаеш өязендә 1968 елда үткәрелгән «Ревизские сказки» материалларына Ямаш авылында теркәлгән.

Кузьым сүзенә татар телендәге *-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы кушылып ясалган Күҗәмкәй исеме төрки-татар чыгышлы Буләккәй исеме белән синонимдаш. Диалекталь варианты — Күҗәмкә. Күҗәмкә (русча Кузьямка) — Татарстанның Зеленодольск районындагы рус авылы атамасы. Казан өязенең 1602—1603 елда язылган сан алу кенәгәсендә Күҗәмкәй (Күҗәмкә) исемен йөртүче берничә татар кешесе телгә алына. Күҗәмкол, Күҗәмкәй исемнәре — шулай ук үзе туганчы әтисе яки тугач та озак тормастан әтисе яисә әнисе үлгән ир балаларга кушылган йола исемнәр.

Удмурт чыгышлы *кузьым* сүзе катнашып ясалган кеше исемнәренең кулланылышта йөрүе Казан татарлары этногенезына удмурт компонентының кушылуы турында сөйли торган мөһим бер антропонимик дәлил.

### Баланың каты авырудан терелеп, исән калуы мотив булган исемнәр

Медицина тиешле үсеш алмаган заманнарда төрки халыкларда сабый баланың каты авырудан терелеп, исән калуы исем кушуда мөһим бер мотив булып торган. Электә татарлар каты авырудан савыгып яшәп киткән сабыйга *калды* (авырудан исән калды) компонентлы: Калды, Калдыбай, Калдыбәк, Калдыбикә, Калдыиш, Калдыкай, Калдыгол, Калдыгөл, Калдыхуҗа, Ишкалды, Саукалды, Исәнкалды, Аманкалды; Сауыкты, Терелде; Сауыкмыш, Терелмеш; Сауыккан, Терелгән һ. б. кебек исемнәр кушканнар.

Гарәби чыгышлы Кыям (күтәрелү, терелү, савыгу; каты авырудан терелү), Нәҗат (котылу; авырудан котылу, арыну) исемнәре дә — каты авырудан терелеп исән калган ир балаларга бирелә торган борынгы йола исемнәр.

### Баланың холкы мотив булган исемнәр

Балага исем кушканда еш кына аның холкы-фигыле, үзен ничек тотуы, кайсы ягы белән күрсәтүе, характеры да искә алынган. Болгар-татарларда шушы мотивка нигез-

ләнеп байтак кына кеше исемнәре барлыкка килгән һәм асылларында шушы мотив яткан гарәби яисә фарсы чыгышлы кеше исемнәре кулланылышка алынган. Бу төркемгә карый торган исемнәрнең кайберләренең асылында бу бала исемдә белдерелгән сыйфатка ия булсын иде дигән теләк ятарга да мөмкин.

Кешенең холык-характер сыйфатлары күп кырлы һәм аларга һәртөрле үсеш-үзгәреш хас. Элекке заманнарда сабый балада холык-характерның кайсы сыйфаты, билгесе аерылыбрак торса, күзгә ташланса, шул сыйфат, билге атамасы аңа исем итеп бирелгән. Елмаючан ир балага Көләч, кыз балага Көлемсәр (гарәби чыгышлы Назир — Назирә исемнәре дә «көләч» мәгънәсенә ия), елак ир балага — Елак, Сыктый; тыныч, сабыр холыклы ир балага Түзем, Түзембай, Түзембәк, Тыныч, Тынычбай, кыз балага — Түзембикә, Тынычбикә кебек исемнәр кушканнар. Татар антропонимиконына гарәп теленнән «тыныч», «сабыр» төшенчәсен белдерә торган байтак кына ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре кулланылышка алынган. Вәзинә, Сәүбән, Сабир — Сабира, Рәзин — Рәзинә, Сәкин — Сәкинә, Хәфазә һ. б. исемнәр әнә шундыйлардан.

Юмартлык, игелеклелек, шәфкатьлелек — кеше холкының иң һәйбәт сыйфатларыннан берсе. Менә шуңа кеше исемнәребез хәзинәсендә «юмарт, шәфкатьле, мәрхәмәтле» төшенчәсен белдерүче исемнәр шактый күп: Юмарт, Юмартбай, Юмартбәк, Вафир — Вафирә, Ваһап, Исмак, Азадә, Мөшфикъ — Мөшфика, Шәфикъ — Шәфика, Шәфкать — Шәфкыя, Шәфәгать, Шәфәгатулла, Мәрхәмәт, Кәрим — Кәримә, Нәваз, Надия, Фәез — Фәйзия, Рәхим — Рәхимә, Рәиф — Раифә, Рәүф — Рәүфә, Салих — Салиха, Сәмих — Сәмиха, Сәхи — Сәхия ~ Сәхилә, Хөсрәү, Җәвад, Әкрәм — Әкрәмә, Әхтәм һ. б.

Җор, җитез, елдам ир балага Тәмәй, Җор, Җитез, Елдам, Алкын, Өлгер исемнәрен кушканнар. Гарәплердән кергән Сарим — Саримә, Назыйрә, Фаһадия, Шаикъ, Зүдә (соңгысы фарсы чыгышлы) исемнәре дә «үткен, җор, елдам» төшенчәсен аңлаталар.

Әби-бабаларыбыз ягымлы, *илгәзәк* ир һәм кыз балаларга Илгәзәк дигән исем кушканнар. Гарәплердән кергән Мәрзи — Мәрзия, Мәхнүнә, Нәсим — Нәсимә, Һани — Һания исемнәре дә «илгәзәк, ягымлы, мөлаем» мәгънәсенә ия.

Җитдирәк кыяфәтле балага Каранай исеме бирелгән. Бу исем татар-мишәрләрдә Каранаев фамилиясендә сакланган. Тиз кызучан, кабынып китүчән ир балага Кыдрач исеме кушканнар. Казан губернасы буенча 1834 елда

уздырылган Ревизские сказки материалларына Кыдрачев фамилияләре элекке Лаеш өязенә караган Олы Нырсы һәм Күн авылларында теркәлгән. Кыдрач исеменең диалекталь варианты — Кызрач. Шуннан Кызрачев фамилиясе ясалган (Сарман районы Иске Минзәләбаш авылында әлеге фамилияне йөртүче гаиләләр бар). Гарәпләрнең ислам кабул иткәнчегә кадәр барлыкка килгән борынгы мәҗүси Габбас исеме дә «кырыс» мәгънәсенә ия. Фасил — Фасилә исемнәре дә «катгый» төшенчәсен белдерәләр.

«Горур» мәгънәсенә ия булган борынгы төрки чыгышлы Кунай һәм Үктәм исемнәре Казан татарларында Кунаев һәм Уктямов фамилияләрендә сакланган. Кунаев фамилиясе казахларда һәм русларда да бар. Гарәби чыгышлы Мәгъруp — Мәгърурә исемнәре дә «горур» мәгънәсендә.

Басынкы, тыйнак ир балага Базык, Тыйнак, Тыйнакбай, Тыйнакбәк, кыз балага Тыйнакбикә, Тыйнаксылу исемнәре кушылган. Базык исеменнән Казан татарларында Базиков, Базуков фамилияләре барлыкка килгән.

Мәзәкчән, кызык, уен-көлке яратучан ир балага Ирмәк исеме биргәннәр. Себер татарларында һәм казахларда «кызык» мәгънәсенә ия булган Ирмәк исеме хәзер дә кулланылышта йөри. Гарәби чыгышлы Һәзил исеме дә «мәзәкчән» дигән мәгънәгә ия.

Иркә, назлы балаларга Иркә, Иркәбай, Иркәбану, Иркәгали, Иркәгөл, Иркәсылу исемнәре кушылган. Татарлар фарси *наз* (иркә) компонентлы Назик — Назикә, Назигөл ~ Назгөл, Гөлназ, Илназ, Назлыбикә, Назлыгөл, Назлысылу, Назлыбай, Назлым, Айназ, Сылуназ, Сәрбиназ, Миңленаз, Фәхриназ һ. б. кебек исемнәрне кулланышка алганнар.

Тәвәккәл балаларга Тәвәккәл, Хазим — Хазимә (гарәпчә хазим — «тәвәккәл») исемнәре бирелгән.

Акрын хәрәкәтләнүче, ашыкмас ир балаларга Акрын, Ашыкмас исемнәре кушылган. Гарәпләрдән кергән Госман исеме дә «акрын, ашыкмас» мәгънәсенә ия (Гафуров А.). Диалекталь вариантлары: Гусман, Усман, Осман, Усманай. Тарихи антропонимиконыбызда фарсыча «салмак, акрын» төшенчәсен белдергән Дөреш исеме дә бар. Бу исем авыл атамаларына әверелеп сакланган (Сарман районында Иске Дөреш һәм Таулы Дөреш дигән татар авыллары бар).

Тапкыр, тиз төшенүчән, сизүчән ир һәм кыз балаларга Тапкыр, Сизгер исемнәрен кушу гадәте булган. Гарәби чыгышлы Бәдиһә дигән хатын-кыз исеме дә «тапкыр, сизгер» төшенчәсен белдерә.

* * *

Без тарихи-лингвистик яссылыкта татар телендә кеше исемнәренең барлыкка килүен һәм үсеш-эволюциясен карап үттек. Балага исем кушудагы мөһим мотив һәм традицияләргә, төп антропонимик берәмлек булып саналган исемнең асылын тәшкил иткән факторларга һәм аларга нигезләнеп барлыкка килгән антропонимик-семантик төркемнәргә шактый киң тукталдык. Алар, бер-берсе белән үзара бик нык керешеп, тулы бер система хасил итәләр. Бу бүлектә әлеге системаның барлык семантик төркемнәрен, ягъни исемнәр чылбырының барлык буыннарын күрсәтеп һәм аңлатып бетердек, дип әйтә алмыйбыз. Без карап киткән 35 семантик төркемнән тыш, тагын, мәсәлән, асылларында ата-анасы һәм туган-тумачаларының баланың тырыш, булдыклы, хезмәт сөючән булып үсүен теләү мотивы яткан Тырыш, Тапай (борынгы төрки телдәге *тапаг* — «хезмәт итү» сүзеннән; болгар-татарларда, чувашларда Тапай исеме шактый дәвамлы вакыт кулланылышта йөргән. Казан татарларында бу исем Тапай дигән нәсел кушаматына һәм фамилиягә әверелеп сакланган. Татарстанның Зеленодольск районы Мулла иле авылында бик борынгыдан килә торган Тапай нәселе бар. Саба районындагы керәшен татарларында Тапаев фамилиясен йөртүче гаиләләр байтак. Тапаев фамилиясе кыргызларда да бар), гарәби чыгышлы Кафи — Кафия (булдыклы), Фаил — Фаилә, Фагыйль — Фагыйлә (эшләүче; эшчән тырыш); асылларында баланың илләр гизүче, ерак илләр белән сәүдә итүче булуын теләү мотивы яткан Җөрдәк; Илгизәр, Илгиз — Илгизә, гарәби чыгышлы Сәях (илгизәр, сәяхәтче), Сәяр — Сәярә (йөрүче, гизүче); тукыма атамаларына нигезләнеп ясалган Бархат ~ Бәрхет, Ефәк, Ефәксылу, Атлас һ. б. кебек исемнәрне үз эченә алган семантик төркемнәр һәм башка төркемчәләр турында сүз алып барырга мөмкин булыр иде.

Башта әйткәнебезчә, кеше исемнәре дөньясы зур һәм тирән бер «диңгез» тәшкил итә. Бер китапта гына бу «олуг диңгез»нең бөтен киңлеген һәм тирәнлеген иңләп бетерү һич тә мөмкин түгел. Без алдыбызга андый «зур колачлы» максатны куймадык та.

## ИСЛАМ ҺӘМ ТАТАР ИСЕМНӘРЕ

Күпчелек төрки халыкларда ислам дине йогынтысында кулланылышка алынган гарәп һәм фарсы исемнәре иң ишле антропонимик катлам тудырган. Татар антропонимиконында гарәп һәм фарсы исемнәре, X гасырдан башлап, берничә гасыр дәвамында туплана һәм ишәя барганга, сан ягыннан иң зур күпчелекне (исемнәрнең 70—75%ын) тәшкил итә һәм аларның шактый өлеше бүгенге көндә дә актив кулланыла.

Болгар ханы Алмуш-Балтавар тарафыннан 922 елда ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгәннән соң, Идел-Кама болгарларына гарәп сүзләре һәм исемнәре интенсив рәвештә үтеп керә башлый. Татар теленең башлыча ислам дине йогынтысында гарәп исемнәре белән тулылануына урта гасырларда фарсы теле шактый нык арадашлык иткән. Болгар дәүләтенең Урта Азия, Иран һәм башка Көнчыгыш илләре белән борынгы заманнардан ук башланган сәүдә һәм культура бәйләнешләре аркылы болгар-татар теленә, ә соңыннан исә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында, татар теленә байтак кына фарсы сүзләре һәм кеше исемнәре (мәсәлән, Бану, Баһман, Бәһрам, Гәүһәр, Гөлзадә, Гөлнара, Гөлсинә, Гөлзифа, Гөлшат, Гөлҗиһан, Диларә, Dилә, Дилназ, Диләфрүз, Дираз, Зифа, Лалә, Маһи, Маһия, Маһидә, Маһишат, Маһруй, Наһар, Нияз, Пакизә, Рушан, Рушат, Рәгъия, Рәния, Рөстәм, Сәрвәр, Шаһбаз, Шаһимәрдән, Әсфәндияр, Җиһангир, Җиһанша, Һәнүз — Һәнүзә һ. б.) килеп кергән.

Татар антропонимиконында меңнән артык ел дәвамында (X гасырдан башлап) саф төрки-татар исем компонентлары белән гарәп һәм фарсы телләреннән алынган исем компонентларының үзара кушылуы аркасында байтак кына катнаш төзелешле исемнәр барлыкка килгән һәм алар берничә катлам тудырган.

Татар антропонимиконының катнаш катламнарын барлыкка китергән исемнәр түбәндәге калыплар буенча ясалганнар:

а) *төрки-татар исем компоненты+гарәп компоненты:* Акназар, Айназар, Илморат, Ишморат, Йөзлеҗамал, Колгали, Колсәет, Коләхмәт, Котлызаман, Котлыниса, Миңлегаян, Миңлегали, Татлыбәнат, Тимергази, Тимергали, Ташмөхәммәт (Ташмәт), Уразмөхәммәт (Уразмәт), Чалмөхәммәт (Чалмәт. Идел-Кама болгарлары телендә чал — «таш»), Яумөхәммәт (Яумәт ~ Җәүмәт) һ. б.;

б) *гарәп компоненты+төрки-татар компоненты:* Гай-

шәбикә, Галимбәк, Дәүләтбай, Дәүләткилде, Муллагол, Мөхәммәтхан, Нурсылу, Сәлимхан, Фәезхан, Шәмсесылу, Әсмабикә, Әмирхан, Әхмәтхан һ. б.;

в) *төрки-татар компоненты+фарсы компоненты:* Айгөл, Айназ, Акхуҗа, Биморза, Илморза, Илназ, Иркәбану, Ишнияз, Миңлегөл, Ишморза, Миңлезадә, Миңлеруй, Сылуҗиһан, Тимерша(һ), Чалморза һ. б.

г) *фарсы компоненты+төрки-татар компоненты:* Гөлбикә, Гөлүсә, Гөлүс, Дилүс, Маһисылу, Морзахан, Хуҗабикә, Хуҗагол, Шаһибәк, Җантимер, Җанчура, Җиһанбай, Җиһансылу һ. б.

Татар антропонимиконында тулаем алынма гибрид исемнәр дә байтак. Алар түбәндәге лексик-семантик калыпларга салынып ясалганнар:

а) *гарәп компоненты+фарсы компоненты:* Гаделша(һ), Гаделҗан, Закирҗан, Зөлфиназ, Зәкиябану, Камәрбану, Нурзадә, Фаягөл, Хәсәнша(һ), Шакирҗан, Әмирҗан, Өммеһани, Өммеҗиһан һ. б.;

б) *фарсы компоненты+гарәп компоненты:* Бибинур, Бибиҗамал, Былбылниса, Маһибәдәр, Маһикамал, Маһинур, Ниязгали, Таҗетдин һ. б.

Ислам дине һәм гарәп-фарсы культурасы һәм әдәбияты йогынтысында татар антропонимиконына кабул ителгән кеше исемнәрен лексик-семантик яктан ике зур төркемгә аерып карый алабыз: 1) *асылларында ислам дине төшенчәләре яткан гарәп-фарсы чыгышлы алынма исемнәр; 2) асылларында дөньяви эчтәлекле гарәп-фарсы сүзләре яткан алынма исемнәр.*

### Асылларында ислам дине төшенчәләре яткан гарәп-фарсы чыгышлы алынма исемнәр

Борынгы һәм Урта гасырларда дин тормышның бөтен экономик һәм идеологик даирәләрен үз йогынтысында тоткан һәм, әлбәттә, кеше исемнәре системасына да көчле тәэсир ясаган.

Ислам дине көнчыгышка хас бик күп төрле диннәрнең, шул исәптән мәҗүсилекнең, йолаларын үзләштерә, үз эченә туплый барган. Менә шуның аркасында ислам дине көнчыгышта күбрәк таралган да. Ягъни ислам дине башка диннәрдән үзенең «специфик көнчыгыш йолаларын саклавы белән» аерыла.

IX—X йөзләрдә Болгар дәүләте руслар, хазарлар һәм көнчыгыштагы мөселман илләре белән сәүдә иткән. Бу чорларда гарәпләр Якын Көнчыгыштагы илләрнең күбесенә үз

хакимлекләрен урнаштырганнар. Кавказ аръягы һәм Урта Азияне яулап алгач, гарәп сәүдәгәрләренә аеруча киң юл ачыла. Алар, Урта Азиянең ком сахраларын кәрваннар белән кичеп, Идел буйлап Болгар иленә килеп җиткәннәр. Гарәпләр һәм болгарлар арасында сәүдә элемтәләре көчәя. Гарәпләр болгарлардан затлы җәнлек тиреләре, бал, балавыз һәм башка товарлар алганнар, ә үзләре тукыма, чапаннар, бөркәнчекләр, бизәнү әйберләре, борыч, йөзем, чикләвек кебек әйберләр сатканнар.

Халыкларны буйсындыруда ислам диненең көчен сизгән гарәпләр Болгар илендә дә мөселманлык урнаштыру белән кызыксынганнар. Сәүдәгәрләр белән бергә, биредә мөселман миссионерлары да үз эшләрен киң җәелдергән.

Болгар патшалыгындагы социаль-экономик шартлар ислам динен кертүдә зур роль уйнаган. Бу вакытта Болгар патшалыгы аерым кабиләләрдән торган, ә гарәп миссионерлары аларның үзара тынычсыз яшәүләреннән оста файдаланганнар.

Болгарларда мәҗүсилек хөкем сөргән. «Изге» һәм «явыз» рухларга ышану аеруча киң таралган. Тарихи мәгълүматларга караганда, аларда үзләренең «вазифа»лары белән бер-берсеннән аерылып торган ундүрт төрле алла булган: кояш алласы, җәй алласы, яңгыр алласы, җил алласы, су алласы, төн алласы, көн алласы, үлем алласы, тереклек алласы, җир алласы, агачлар алласы, кеше алласы, хайваннар алласы һәм күк алласы. Соңга таба, ислам дине урнашкач, бу аллаларның күбесе төрле рухлар, «ияләр» булып калганнар. Мәсәлән, урман иясе (шүрәле), су иясе (су анасы), өй иясе (бичура), абзар иясе, өрәк һ. б.

Күп аллалык болгарларның бер дәүләткә берләшүенә комачаулап торган. Ә ислам дине, үзенең бер аллага һәм бер хакимгә буйсындыру идеологиясе белән, ыруглык мөнәсәбәтләрен җимереп, феодаль мөнәсәбәтләр урнаштыруга һәм феодаль дәүләтне ныгыту максатларына тулысынча туры килгән.

Риваятьләргә караганда, ярым легендалар Айдар хан вакытында ук инде (IX йөз) болгарлар арасында ислам диненә өндәүчеләр булган, ләкин әле ул вакытта яңа дин болгарларда киң таралыш алмаган.

X йөз башында Болгар дәүләте белән гарәпләр арасындагы сәүдә мөнәсәбәтләре тагын да көчәйгән, 922 елда бирегә Иранннан Җәгъфәр хәлифәнең махсус илчеләре килгән. Алар Болгар ханы Алмуш-Балтаварга хәлифәнең мөрәҗәгатен укыганнар. Шул вакыттан алып Алмуш-Балтавар хан ислам динен кабул иткән һәм үзен алланың җирдәге

шәүләсе дип белдергән, исемен дә габбасидлар хәлифәсе Җәгъфәр исеменә алмаштырып, Алмуш-Җәгъфәр дип атала һәм дәүләт эшләрен ислам кануннары нигезендә алып бара башлаган.

Мәҗүсилектән ислам диненә күчү исемнәр хәзинәбезнең баю-тулылануында зур роль уйнаган.

Ислам үз йогынтысындагы барлык төрки халыкларга алланың канунлаштырылган изге 4000 исемен тәкъдим итеп (гамәлдә бер мең, дөресрәге, изге дип саналган 99 исем киң кулланышка ия булган), мәҗүсилеккә бәйле исемнәргә чик куярга, аларны кулланылыштан төшереп калдырырга омтыла.

Ислам дине тәэсирендә борынгы мәҗүси йолалар ислам йолалары белән алмаштырыла башлый. Балага исем кушу белән бәйләнешле борынгы төрки мәҗүси йола-мотивлар һәм традицияләрне дә ислам мотивлары һәм традицияләре кысрыклап чыгара бара. Борынгы заманнардан ук килә торган төрки-татар исемнәребезнең күбесе актив кулланылыштан төшеп кала. Алар урынына дини төшенчә белдерүче исемнәр һәм дөньяви эчтәлекле гарәп-фарсы исемнәре гамәлгә алына. Әмма борынгы мәҗүси йола-мотивлар һәм гадәтләр нигезендә барлыкка килгән традицион төрки-татар исемнәр дә тулысынча юкка чыкмаганнар.

Инде әйткәнебезчә, ислам дине көнчыгышка хас булган күп төрле диннәрнең, шул исәптән мәҗүсилекнең дә байтак кына йола һәм традицияләрен үзләштергән. Болар арасында гарәп һәм фарсыларның балага исем кушуга караган борынгы мәҗүси антропонимик йола-мотивлары һәм традицияләре дә бар. Борынгы төрки-татар һәм гарәп-фарсы антропонимик йола-мотивлары һәм традицияләренең үзара туры килүе, тәңгәл-универсальлеге нигезендә, исемнәр хәзинәбезнең бер үк семантик төркемгә карый торган берәмлекләре гасырлар дәвамында арта-ишәя барган.

Бездә гарәп, фарсы исемнәренең һәм кушма төзелешле гибрид исемнәрнең таралышы һәм кулланылышы төрле дәвердә төрлечә булган. Болгар-татар теленә гарәп һәм фарсы исемнәре Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгәннән соң алына башласалар да, XIX йөз башларына кадәр киң таралышка һәм популярлыкка ия булмаганнар әле. Бу чорга кадәр борынгы төрки-татар кеше исемнәре күбрәк кушылган. Болгар-татар кабер ташларындагы, нәсел шәҗәрәләрендәге, сан алу кенәгәләрендәге һәм башка тарихи чыганаклардагы татар кеше исемнәре нәкъ менә шуны раслый. XIX йөздә исә бу хәл бик нык үзгәрә. Татарлар арасында ислам дине белән бәйле гарәп һәм фарсы

исемнәре киң тарала. Алар башлыча ислам динен, алланы, Мөхәммәт һәм башка пәйгамбәрләрне, аларның якыннарын, ислам мәзһәпләренең имамнарын олылауга, илаһи сыйфат-атрибутларын атауга нигезләнгән исемнәр була.

Билгеле булганча, *ислам* сүзе түбәндәге мәгънәләргә ия: 1. «Буйсыну, бер аллага буйсыну, күндәмлек. 2. Мөслим, мөселман. 3. Сәламәт, сау, төзек». Ислам компонентлы Ислам — Исламия, Исламбакый, Исламбәк, Исламгази, Исламгали, Исламгир, Исламгол, Исламхуҗа, Исламгәрәй, Исламетдин, Исламнур — Нурислам, Исламхан — Ханислам, Исламхаҗи — Хаҗиислам, Исламхуҗа — Хуҗаислам, Исламша(һ) — Шаһислам, Исламшәех, — Шәйхеислам, Исламшәриф — Шәрифелислам, Галиислам, Газизислам, Габделислам, Гайнелислам, Зәйнелислам, Садрелислам, Сәйфелислам, Фәйзелислам, Фәтхелислам һ. б. кебек исемнәр барлыкка килгән һәм татарларда да кулланылышка кергән. Мөслим — Мөслимә исемнәре дә — ислам динен олылау-зурлауга мөнәсәбәтле дини эчтәлекле исемнәр.

Составларында *дин* (инану, ышану; дин) сүзе булган бик күпләгән кеше исемнәренең асылында да ислам динен зурлау аңа инану, табыну, буйсыну мотивы ята: Дин — Динә, Афзалетдин (диннең иң лаеклысы, иң кадерлесе), Габетдин (гыйбадәт кылучы; дингә хезмәт итүче), Гайнетдин (дин чишмәсе), Зыятдин — Зыятдинә (дин яктылыгы, дин нуры), Зәйнәгыйтдин (дин бизәге), Кәшфетдин (динне ачыклаучы), Мифтахетдин (диннең ачкычы), Мөхетдин (динне терелтүче, куәтләүче, яклаучы), Нуретдин (дин нуры), Рәшидетдин (дингә тугрылыклы; дингә дөрес юл тотучы), Садретдин (дин күкрәге, дин үзәге), Таҗетдин (дин таҗы), Хәйретдин (диннең игелеклесе), Хөснетдин (диннең күркәмлеге, гүзәллеге), Камәретдин (диннең ае), Шәмсетдин (диннең кояшы), Фәрхетдин (диннең иң сөеклесе), Фәүзетдин (диннең тантанасы), Шиһабетдин (диннең якты йолдызы), Шәйхетдин (дин карты, дин башлыгы), Әкрәметдин (диннең иң камил кешесе), Әкъмәлетдин (диннең иң камил кешесе), Җамалетдин (дин чибәрлеге, гүзәллеге), Җәләлетдин (диннең олылыгы), Һилалетдин (диннең яңа туган ае), Динбай, Диндар (бик динле), Динислам, Динмөхәммәт (Мөхәммәт дине кешесе), Мөхәммәтдин, Динулла (алла дине), Диншәех (дин шәехе; рухани башлыгы), Динәхмәт (диннең мактаулысы, данлысы) һ. б.

Ислам дине төшенчәләрен белдерүче гарәп, фарсы һәм гибрид исемнәрнең байтагы *алла* ~ *улла* (бер вә бар, тәңре, хода, хак) сүзе катнашып ясалган: Аллабирде, Алла-

биргән, Аллагол, Аллахуҗа, Аллакуәт, Алламорат (алла теләге), Аллаһияр (алла дусты, алла ияргән); Габдулла (алла колы), Гайнулла (алла чишмәсе), Зәйнулла (алла бизәге), Лотфулла (алла мәрхәмәте, шәфкате), Миңнулла (алланың бәхетле кешесе), Мотыйгулла (аллага буйсынучы, баш июче), Нәбиулла (алланың илчесе, пәйгамбәре), Рәхмәтулла (алла мәрхәмәте), Рәхимулла (алла шәфкәте, рәхиме), Сәйфулла (алла кылычы), Сәлимулла (алланың сәламәт бәндәсе), Шәйхулла (алла шәехе, алла карты), Әсәдулла (алланың арысланы), Әхмәдулла (алланың мактаулы, данлы кешесе), Әһлиулла (алланың әһеле, алла бәндәсе) һ. б.

Исламның алланы олылауга, аңа табынуга корылган исемнәре «иң күркәм» 99 исемне үз эченә ала. Бу исемнәр алланың илаһи сыйфатларын, атрибутларын белдерүче эпитетлардан гыйбарәт. Мәсәлән: Азамат (бөеклек, шөһрәт, дан), Басыйр (барысын да күреп торучы), Барый (тап итүче, яратучы, тудыручы, иҗат итүче), Вахит (бердәнбер), Ваһап (тереклек бирүче, гомер бүләк итүче), Вәли (изге), Газиз (кодрәтле, көчле, кадерле), Газим (бөек, югары дәрәҗәле), Гаффар (барысын да гафу итүче, кичерүче, ярлыкаучы), Даян (кылган эшләренә күрә җәзасын бирүче), Кави (көчле, куәтле, киң кодрәтле), Кадыйр (кодрәтле, һәрнәрсәгә көче җитүче), Касыйм (бүлеп бирүче, өлеш чыгаручы), Каюм (бер дә үзгәрмәүчән, тотрыклы, уяу), Каһһар (чиксез көчле, бик куәтле), Кәбир (олы, биек), Кәрам (юмарт, киң күңелле), Кәрим (юмарт, рәхимле, киң күңелле), Латыйф (шәфкатьле, игелекле, мөлаем), Моталлип (җавапка тартучы), Мәннан (чиксез рәхимле, нигъмәт бирүче), Мәннаф (өстен, иң югары), Мәҗит (данлы, мактаулы, атаклы), Насыйр (ярдәм бирүче, яклаучы), Рахман (рәхимле, шәфкатьле, ярлыкаучы), Рәхим (мәрхәмәтле, рәхимле, аяучан), Рәззак (ризык бирүче, туендыручы), Рәкыйп (барын да күреп торучы), Рәүф (рәхимле, кызганучы), Сабир (түземле, сабыр), Самат (мәңге яшәүче), Саттар (гафу итүче, яклаучы), Сафи (саф, чын), Сөббух (олы, данлы, мактаулы), Сөбхан (дан, мактау), Фәттах (ачучы), Хак (чын, дөрес, хак), Халикъ (яратучы, бар кылучы), Харис (саклаучы, яклаучы), Хәер (изгелек кылучы), Шакир (шөкер итүче), Җәббар (зур көч-куәт иясе, кодрәтле), Җәлил (бөек, шөһрәтле, данлы), Җәләл (күркәм, матур, чибәр), Һади (туры юл күрсәтүче) һ. б.

Шушы эпитетларга *абд ~ габд ~ габде ~ габдел* (кол, алла колы, алла бәндәсе, хезмәтчесе) алкушымчасы ялганып, исем-эпитет вариантларының (дөресрәге, мөстәкыйль

антропонимик берәмлекләрнең) саны тагын да күбәя төшкән: Габделвахит (бирдән-бернең, ягъни алланың колы), Габделгафур (ярлыкаучының, кичерүченең колы), Габделмалик (хакимлек итүченең, боеручының колы), Габделҗәббар (бөек кодрәтленең колы), Габдерәүф (рәхимленең, кызганучының колы), Габдерәхим (рәхим-шәфкатьленең колы), Габдесаттар (гафу итүченең колы), Габдессәлам (исәнлек, сәламәтлек бирүче, коткаручының колы), Габдешшәкүр (бик шөкер итүченең колы) һ. б.

Алланың эпитетларына гарәп, фарсы һәм төрки-татар чыгышлы башка исем компонентларын кушу юлы белән дә дини төшенчә белдерүче бик күп исемнәр ясалган. Мәсәлән, *рахман* эпитетына антропокомпонентлар ялганып: Фәйзерахман, Фәтхерахман, Фазлырахман, Хәбибрахман, Галирахман, Рахманзадә, Миңлерахман, Рахманбай, Рахманби, Рахманбәк, Рахманкол һ. б.; *кәрим* эпитетына исем компонентлары кушылып: Фәезкәрим, Әхмәткәрим, Миңлекәрим, Кәримбай, Кәримбәк, Кәримхан, Кәримхуҗа, Кәримша, Кәримҗан һ. б. кебек исемнәр барлыкка килгән.

Тарихи антропонимиконыбызда ислам диненә нигез салучы Мөхәммәтнең, аның сәхәбәләре һәм якыннарының исемнәре аеруча актив кулланылышка ия була.

Мөхәммәт Коръәндә Әхмәт исеме астында гәүдәләнә. Телдән сөйләнгән хәдисләренә пәйгамбәр үзен Мөхәммәд дип тә, Әхмәд дип тә, Мәхмүд дип тә, Хәмид дип тә атый. Бу исемнәрнең барысы да «дан, мактау» төшенчәсен белдерә торган бер үк *хмд* тамырына кайтып кала.

Мөхәммәт, Әхмәт, Мәхмүт, Хәмит дигән исемнәргә, гарәби һәм фарси генезислы антрополексемалар ялганып, күп кенә кушма төзелешле кеше исемнәре барлыкка килгән һәм ислам йогынтысында болгар-татарлар тарафыннан да кулланышка алынган. Болгар-татарларда бу исемнәргә, үз антропокомпонентлары кушылып та яңа исемнәр ясалган.

Мондый исемнәрнең күбесе Мөхәммәт исеменә нигезләнеп ясалганнар: Мөхәммәтбакый, Мөхәммәтбакир, Мөхәммәтзакир, Мөхәммәтгали, Мөхәммәтшакир, Мөхәммәтҗан, Мөхәммәтша(һ), Шаһимөхәммәт, Мөхәммәтхан, Ханмөхәммәт, Аймөхәммәт, Баймөхәммәт, Бикмөхәммәт, Дусмөхәммәт, Илмөхәммәт, Ишмөхәммәт, Мөхәммәтиш, Нурмөхәммәт, Мөхәммәтнур, Ташмөхәммәт, Чалмөхәммәт, Килмөхәммәт, Миңлемөхәммәт, Шәмсемөхәммәт, Кадермөхәммәт, Уразмөхәммәт һ. б.

Татар теле сөйләшләрендә Мөхәммәт исеме һәм аның кушма төзелешле төрләренең байтак кына диалекталь вариантлары барлыкка килгән: Мөхәмәй, Мөхәмми, Мөхәм,

Мокамай, Мукай, Мукач, Мухач, Мамай, Мамак, Мамук, Мамаш, Мәмәт, Мәмбәт, Мамыш, Мәмәш; Баймөхәммәттән: Баймәмәт, Баймәт, Байми, Баймук, Байман, Баймуш, Баембәт; Бикмөхәммәттән: Бикмәмәт, Бикмәт, Бикми, Бикмүш, Бикмүч, Бикмүк, Бимәт, Бикмәй, Бикәү, Бикмәч, Бикмеч, Бикуш; Ишмөхәммәттән: Ишмәмәт, Ишмәт, Ишмәй, Ишми, Ишмүк, Ишүк, Ишмуй, Ишмәк, Ишәй, Иши, Ишуй, Ишмекәй, Ишембет; Нурмөхәммәттән: Нурхәмәт, Нурми, Нурмат, Нурмый, Нурмай, Нурмач, Нурмук, Нурмак, Нурхәми, Нирхи, Нурмуш; Калмөхәммәттән (абсолют синонимы Миңлемөхәммәт): Калмәмәт, Калмәт, Калмай, Калмый, Калми, Камәт һ. б. Болардан татарларда Мөхәммәтов, Мөхәмәев, Мөхәммиев, Мөхәмов, Мокамаев (татар-мишәрләрдә), Мукаев, Мукачев, Мухачев, Мамаев (себер татарларында), Мамаков (керәшен татарларында), Мамуков, Мамашев, Мәмәтов, Мәмбәтов, Мәмәшев, Мамин (татар-мишәрләрдә), Мамышев; Баймөхәммәтов, Баймәмәтов, Баймаметов, Баймәтов, Байметов, Баймиев, Баймин, Баймуков, Байманов, Баймутов, Баймушев, Баймушин, Баембетов; Бикмөхәммәтов, Бикмәмәтов, Бикмаметов, Бикмәтов, Бикматов, Бикметов, Бикмиев, Бикмин, Бикмушев, Бикмучев, Бикмуков, Бимәтов, Бикмәев, Бикмаев, Бикмачев, Бикмечев, Бикушев, Бикушин һ. б. фамилияләр ясалган.

Әхмәт (иң данлы, иң мактаулы) исеменә нигезләнеп: Әхмәтбакир, Әхмәтбакый, Әхмәтбарый, Әхмәтвафа, Әхмәтвәли — Вәлиәхмәт, Әхмәтгази — Газиәхмәт, Әхмәтгали — Галиәхмәт, Әхмәтгани — Ганиәхмәт, Әхмәтгариф, Әхмәтзыя — Зыяәхмәт, Әхмәтзадә, Әхмәтзакир, Әхмәтзәки, Әхмәтрәсүл — Рәсүләхмәт, Әхмәтсадыйк, Әхмәтсафа, Саниәхмәт, Әхмәтсәет — Сәетәхмәт, Әхмәтфәез — Фәезәхмәт, Әхмәтшакир, Әхмәтша, Әхмәтшәриф, Әхмәтҗан, Әхмәтъяр, Әхмәтбай, Әхмәтбәк, Миңлеәхмәт, Муллаәхмәт, Хуҗаәхмәт, Хуҗиәхмәт, Әхмәтгәрәй, Нуриәхмәт, Нурәхмәт, Әхмәтнур, Әхмәдулла (диалекталь варианлары: Әхми, Әхмүк, Әхмүч, Ахмук, Ахман, Ахмадук, Ахмуш), Әхмәтһади — Һадиәхмәт һ. б. кебек кушма исемнәр ясалганнар.

Мәхмүт (макталган, мактаулы) исеменә нигезләнеп: Мәхмүдә, Мәхмүтниса, Мәхмүтгали, Мәхмүтвәли, Мәхмүтсолтан, Мәхмүтфоат, Мәхмүтбай, Мәхмүтбәк, Мәхмүтгәрәй, Мәхмүтхан, Мәхмүтша, Мәхмүтьяр, Мәхмүтҗан һ. б. кебек кушма төзелешле исемнәр барлыкка килгән.

Хәмит (мактаулы, мактауга лаеклы) исеме һәм аның диалекталь варианты Хәмәт) исеме катнашып: Хәмидә, Бибихәмидә, Хәмитбай ~ Хәмәтбай, Хәмитбәк ~ Хәмәтбәк, Хәмитвәли ~ Хәмәтвәли, Хәмиткамал, Хәмитхан, Хәмит-

ша, ~ Хәмәтша, Хәмитҗан ~ Хәмәтҗан, Хәмәтвафа, Хәмәтгали, Хәмәтгалим, Нурхәмит ~ Хәмитнур ~ Хәмәтнур, Хәмәтрәхим. Хәмәтсафа, Хәмәтсәгыйть һ. б. кебек кушма төзелешле кеше исемнәре ясалган һәм гамәлдә йөргән.

Ислам руханилары тарафыннан Мөхәммәт пәйгамбәргә бирелгән эпитетлар да вакытлар узу белән ислам динендәге халыкларда актив кулланылыштагы кеше исемнәренә әверелгәннәр: Рәсүлулла (алланың илчесе), Нәбиулла (алланың пәйгамбәре), Камил (мөкәммәл, һәр ягы җитеш), Кәрим (юмарт, мәрхәмәтле), Вәси (яклаучы), Лотфулла (алла мәрхәмәте), Нигъмәтулла (алла бүләге), Мостафа (сайлап алынган, иң саф; башкалардан өстен), Мохтар (сайланган, сайлап алынган), Хәйдәр (арыслан), Җәвад (юмарт), Һади (туры юл күрсәтүче, туры юлга күндерүче), Әмин (ышанычлы, тугрылыклы) һ. б.

Ислам дине йогынтысында Мөхәммәт пәйгамбәрнең төп сәхәбәләре һәм хәлифләре Әбүбәкер (яшь дөя атасы), Гомәр (яшәеш, гомер итү, чәчәк ату), Госман (акрын, ашыкмас), Гали (бөек, олы дәрәҗәле) исемнәре һәм Әбүбәкергә бирелгән Ситдыйкъ (тугрылыклы), Гомәргә кушылган Фарук (яхшы белән яманны нечкәләп аера белүче), Госманга бирелгән Зиннурайни (нурлы бизәк, нур иясе), Галигә кушылган Мортаза (сайлап алынган) кушамат-эпитетлары да мөселман халыкларында популяр булалар.

Ислам йогынтысында Мөхәммәт пәйгамбәрнең этисе Габдулла (алла колы), энисе Әминә (1. ышанычлы турылыклы; 2. куркусыз, тыныч), абыйлары Габбас (кырыс, катгый) һәм Хәмзә («үткен, өтеп ала торган» мәгънәсендә, Мөхәммәт Әсәдулла, ягъни «алланың арысланы» дип атый), хатыннары Хәдичә (җитлекмәгән, вакытыннан элек туучы), Гайшә (яшәүче, тере), кызлары Фатыйма (имүдән аерылган), Өммегөлсем (ал яңаклының анасы), Зәйнәп (тулы гәүдәле, таза), Рокыя (тылсым; күңелне үзенә тартып торучы, җәлеп итүче), оныклары Хәсән (чибәр, матур; яхшы), Хөсәен (чибәр, гүзәл, яхшы; ике матурның берсе) һәм башка туган-тумачаларының исемнәре дә киң таралышка һәм кулланылышка ия булган. Хәсән һәм Хөсәен — игезәк ир балаларга, Хәдичә һәм Фатыйма (Фатыйманың энисе Хәдичә булган) — игезәк кыз балаларга кушыла торган традицион исемнәр.

Библиядәге пәйгамбәрләрнең исемнәре дә мөселманнарның «изге исемнәре»нә әверелеп киткән: Адәм (адәм, кеше), Гайса (алла мәрхәмәте), Гозәер (ярдәмче, теләктәш), Давыт (сөекле, үзенә җәлеп итүче), Ибраһим (халыклар атасы), Исхак (ул көлде), Исмәгыйль (алла үзе ишетә),

Идрис (өйрәнүче, укучы), Ильяс (алла могҗизасы), Йосыф (алла тарафыннан арттырылган, өстәлгән гүзәллек), Муса (бала), Сөләйман (исән-имин яшәүче; тыныч), Шогаеп (нурлы), Хозыр (мәңге үлемсез), Якуб (ияреп баручы, артыннан калмаучы), Яхъя (җанландыручы), Әюп (тәүбә итүче) һ. б. Ислам руханилары исламның төп пәйгамбәрләре булып саналган Адәм пәйгамбәргә Сафиулла (алланың сайлап алганы), Мусага — Кәлимулла (алланың әңгәмәдәшчесе), Гайсага — Рухулла (алланың рухы), Ибраһим пәйгамбәргә Хәлиулла (алланың дусты) дигән өстәмә исемнәр биргәннәр. Пәйгамбәрләрнең чын исемнәре һәм эпитетлары мөселман дөньясында шулай ук киң таралган һәм актив кулланган.

Ислам дине титулларына (*ахун, имам, мулла, сәет, хаҗи, хуҗа, хәзрәт, шәех* һ. б.) нигезләнеп барлыкка килгән кеше исемнәре дини төшенчәләргә бәйле исемнәрнең аерым бер төркемен тәшкил итә. Без алар турында алдагы бүлектә сүз алып бардык.

Мөселман бәйрәмнәренең атамаларына нигезләнеп тәгади һәм кушма төзелешле кеше исемнәре ясалган.

Мөселман бәйрәмнәре күп түгел, һәм алар барысы да беренче тапкыр ислам диненә өндәүче Мөхәммәт пәйгамбәр исеме белән бәйләнгән.

Ислам дине барлыкка килгәч туган һәм барлык мөселманнар өчен мәҗбүри саналган бәйрәмнәр икәү — ураза һәм корбан бәйрәме.

Милади белән X, һиҗри белән III йөздә боларга тагын өч бәйрәм өстәлә, «ләйләте әл-кадер» — сер ачылу төне (татарлар «кадер кичәсе» диләр), «гарәфә» — искә төшерү бәйрәме һәм «ләйләте әл-бәраэт» — үлгәннәр рухына дога кылу бәйрәме.

Милади белән XII, һиҗри белән V йөздә янә ике бәйрәм өстәлә: «мигъраҗ» — Мөхәммәтнең Мәккәдән Бәйтелмөккатдәскә (Иерусалимга), аннан «алла янына төнге сәяхәтен» искә алу бәйрәме һәм «мәүлет» — Мөхәммәтнең туган көне.

Бу бәйрәмнәр, Коръәннең 62 сүрәсендә (9 нчы аять) телгә алынган җомганы исәпләмәгәндә, ислам диненең «мәҗбүри» кагыйдәләренә бәйләнмәгәннәр. Алар ислам барлыкка килгәннән соң күп еллар үткәч уйлап чыгарылганнар.

Хәзер безнең якларда таралган сөнни мәзһәбе мөселманнарындагы дини бәйрәмнәргә һәм аларның атамаларына нигезләнеп ясалган кеше исемнәренә тукталып үтик.

Ураза бәйрәме (Гайде фитыр). Бу бәйрәмдә ураза

тоткан һәр кеше шәригать нигезендә муллаларга фитыр сәдакасы бирергә тиеш. Бәйрәмнең исеме дә әнә шул фитырга бәйләнгән. Ураза тотучылар, үзләренең ай буена көндезен ач торып, төннәрен уяу булулары, тәрәвих намазы укыганнары өчен алладан «теге дөнья»да бүләк өмет итеп «бәйрәм» итәләр.

Ураза бәйрәменең беренче көнендә махсус намаз — *гаег* укыла. Монысы инде борынгыларның уразадан соң аерым ашарга ярамый дигән карашларына һәм кабилә белән бергә җыелып, алладан рөхсәт сорау йоласына кайтып кала.

Гает көнне туган ир балаларга *гает* сүзе кергән исем кушу гадәте йола-традиция булып киткән: Гает (диалекталь вариантлары — Ает, Аит. Болардан Гаетов, Аетов, Аитов фамилияләре ясалган), Гаетбай～Аетбай, Гаеткол～Аиткол, Гаетмөхәммәт (диалекталь вариантлары Аетмөхәммәт, Аетмәт, Аймәмәт, Әйтмәт, Әйтүкә, Әйүкә), Гаетхан, Гаетхуҗа, Гаетҗан һ. б.

Электә татарларда рамазан аенда ураза тотканда, таң атканчы сәхәр ашау вакытында, туган кыз балаларга гарәби чыгышлы сәхәр («таң ату; сәхәр вакыты») компоненты булган исем кушу йола-гадәте урын алган. Сәхәрбан («таңчы», таң атканда — сәхәр вакытында туучы кыз бала. Казан губернасы буенча 1834—1858 елларда уздырылган Ревизские сказки материалларына караганда, бу исем XVIII гасыр азагында һәм XIX гасыр урталарында Казан артындагы татар авылларында еш очраган), Сәхәрбану, Сәхәрбикә, Сәхәрбәнат, Сәхәрия, Сәхәрхәят һ. б.

Корбан бәйрәме. Бу бәйрәмдә мөселманнар корбан чалалар. Корбан чалу йоласы да, ураза кебек үк, борынгы мәҗүсиләрдән күчереп алынган. Аның тарихы борынгыларның җан бар, дип ышануларына, анимизмга барып тоташа. Кыргый халыклар үзләренең шәхси һәм иҗтимагый тормышларындагы һәр күренеш җаннар тормышына да хас: җан ашый да, эчә дә, өйләнә дә, бала да таба дип уйлаганнар. Җаннарның иң яраткан ризыгы кан дип уйлап, алар өчен кан агызганнар. Шуннан корбан чалу килеп чыккан.

Ислам дине иң элек Гарәбстанда киң таралган. Андагы борынгы мәҗүсиләр йоласы, Тәүраттагы Ибраһимның улы Исхакны (мөселманнарда Исмәгыйльне) корбан чалу турындагы әкияткә бәйләп, корбан чалу изге йола итеп канунлаштырылган.

Электә корбан аенда, бигрәк тә корбан бәйрәме көнне туган балаларга гарәпчә *корбан* (үз-үзен аямаучы, корбан

итүче, фида кылучы) сүзе кергән кеше исемнәре биргәннәр: Корбан, Корбаный, Корбанай, Корбанбай, Корбанбакый, Корбанбикә, Корбанбулат, Корбанбәк, Корбанвәли, Корбангази, Корбангали, Корбангилде, Корбанкол, Корбангөл, Корбангүзәл, Корбаннәби, Корбансылу һ. б.

Мәүлет бәйрәме. Бу бәйрәм XII йөздә урнаша, ә Россиягә XIV йөздә генә килеп керә. Ул Мөхәммәтнең туган көненә багышланып, барлык мөселманнарда да, ай календаре белән 12 нче Рабигел-әүвәлдә үткәрелә.

Мәүлет (мәүледе-н-нәби) бәйрәме көнне туган балаларга *мәүлет* сүзе кергән исем кушу йола-мотив булып киткән: Мәүлет-Мәүлидә, Мәүлетбай, Мәүлетбикә, Мәүлетбирде, Мәүлетбәк, Мәүлетгәрәй, Мәүлетдин, Мәүлеткол, Мәүлетхан, Мәүлетша, Мәүлетьяр, Мәүлетҗан һ. б.

Гашура бәйрәме дүртенче хәлифә Галинең улы Хөсәеннең үлүенә (дин юлында шәһит китүенә) багышланган. Шул вакыйгага бәйләп, шигый мөселманнары Хөсәен үлгән көнне — мөхәррәм аеның унынчы көнен (гарәпчә гашир «унынчы») дини бәйрәм көне иткәннәр, «шәхсәй-вәхсәй» яки гашура бәйрәме итеп үткәрә башлаганнар. Гашура — тарәп булмаган мөселманнарда мөхәррәм аеның синонимы.

Мөхәррәм аеның унынчы көнендә — Гашура бәйрәме көнне яки гомумән мөхәррәм аенда туган балаларга Гашура, Гаширә — Гаширә, Ашир — Аширә, Әшүр — Әшүрә исемнәрен кушу гадәткә кергән.

Татар балаларына исем кушуда әлеге дини тенденцияне Бохараның схоластик мәдрәсәләрендә укып кайткан мулла-мөдәррисләр алга сөрә.

Дин әһелләре мондый исемнәрне махсус пропагандалап, аларны туплап, аерым китапчыклар, циркулярлар бастырып чыгарганнар. 1848 елда Казанда «Исме аллаһе тәгалә әлхәсәни», 1865 елда «Аврадия Фәтхия», 1899,1900 елларда ахун Бендуковның «Исем. Балага күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафикъ китап», 1914 елда Кәримовларның «Унбер Әхмәт исемнәре» һ.б. китаплар бастырып таратыла. Бу китапларда исемнәрнең дини ягы макталып, аларның шәригатькә туры килүе таләп ителә. Аллаһе тәгаләнең 99 күркәм исеме санап чыгыла һәм аларның мәгънәләренә аңлатма бирелә.

Оренбург мөселман дине нәзарәте 1894 елның 13 мартында исемнәр турында махсус циркуляр чыгара (№ 1886) һәм гамәлгә ашыру өчен мәхәллә имамнарына җибәрә. Бу циркулярда мәхәллә имамнарына, муллаларга яңа туган балаларга нинди исемнәрне кушмаска, нindиләрен кушарга кирәклеге турында күрсәтмә бирелә.

Тыелган исемнәргә төрки чыгышлы Җәмәтәй, Сүрсенбай, Салбай, Көсбикә һ. б. исемнәр кертелә. Алар эчтәлексез һәм ямьсез исемнәр итеп санала.

Яңа туган балаларга Рамазан, Рәҗәп, Мөхәррәм, Шәгъбан, Сәфәр һ. б. кебек ай исемнәрен, җомга, шимбә, якшәмбе, дүшәмбе... шикелле көн атамаларын кушарга тәкъдим ителми. Циркулярда яңа туган балаларга традицион *асыл, иш, им, ахун, бик, бикә, баба, бану, бай, тимер, дәүләт, солтан, мелла~мулла, мирза, хан, хаҗи, хуҗа, яр, әмир, җан, гөл* һ. б. антропонимик компонентлар ялганып ясалган кушма исемнәрне бирмәскә кушыла.

Яңа туган балаларга алла исемнәренә *габде* («кол») сүзе кушылган исемнәрне (мәсәлән, Габдрахман, Габделкәрим, Габделрәхим, Габделкәбир, Габдерәшит һ. б.), пәйгамбәрләр исемнәрен (Мөхәммәт, Әхмәт, Идрис, Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Якуб, Әюп, Муса һ. б.), Мөхәммәт пәйгамбәр сәхәбәләренең (Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали), якын туган-тумачаларының исемнәрен (мәсәлән, ир балаларга: Габдулла, Габбас, Хәмзә, Хәсән, Хөсәен, Сәгыйть, Халит, Вәлит, Сабит, Җәббар; кыз балаларга: Фатыйма, Рокыя, Мәрьям, Әсма, Зәйнәп, Сафия, Зөбәйдә, Хәлимә, Рабига, Әминә, Ләйлә, Сәгадәт һ. б.) бирергә киңәш ителә.

Исемнәр турындагы бу циркуляр халык арасында канәгатьсезлек һәм шау-шу тудыра.

Татар-башкорт байлары һәм муллалары, имештер, 1897 елгы халык санын алу вакытында мөселманнарны православный итеп язачаклар, чукындырачаклар һәм аларга рус исемнәре бирәчәкләр, дигән ялган хәбәр тараталар. Исемнәрнең социаль-политик ягын күпертеп, аны үзләренең милләтчел реакцион пропагандалары максатында татар халкын солтан Төркиясенә китәргә өндәү өчен файдаланырга тырышалар.

XX гасыр башында, Беренче рус революциясе йогынтысында, татар антропонимиясендә демократик, прогрессив тенденция үсеш ала. Аның асылы халык арасында традицион саф төрки-татар исемнәрен кушу гадәтен яңартудан һәм шулай ук дөньяви эчтәлекле гарәп һәм фарсы исемнәрен пропагандалаудан гыйбарәт була.

Беренче рус буржуаз-демократик революциясеннән соң татар антропонимиясендә фанатик руханилар җитәкли торган реакцион агым белән демократик агым арасындагы көрәш тагын да кискенләшә. Татар демократик антропонимик хәрәкәтен Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов,

Ш. Бабич кебек күренекле әдипләр һәм халкыбызның башка прогрессив җәмәгать эшлеклеләре җитәкли.

Заман таләпләреннән чыгып язылган «Исемнәребез хакында» («Ялт-йолт» журналы, 1911 ел, 4 июнь саны) дигән мәкаләсендә бөек шагыйребез Г. Тукай татарлар арасында дини эчтәлекле исемнәрнең күбәюенә һәм активлашуына борчылып болай дип яза: «...без — татарларның тәрбиясе — дин тәрбиясе. Һәр абзый, һәр агай, һәр бабай диннең ни булса да бер кирәк нәрсәсе, Гыймадетдин, Мифтахетдин, Микъразетдин (диннең терәге, ачкычы, кайчысы). Соң аллага мозаф (алла сүзенә ияртелгән — *Г. С.*) исемнәр хакында ни дибез? Болар да исәпсез күп ич: Габдулла, Миңнулла, Лотфулла, Гайнулла, Шәмсулла, Гобәйдулла, Гыйбадулла, Сәйфулла, Әхмәдулла, Хәкимулла, Галимулла, вә гайре, вә гайреләр».

Г. Тукай татар халкына: «Һәр нәрсәнең гүзәлен яратабыз бит. Бәс мин телимен ки, Бохари муллаларның бөтен черек нәрсәләренә безнең арада бәһа беткән кеби, киләчәктә ул әфиюн башлар уйлап чыгарган ямьсез исемнәр дә татар балаларына кушылмасын!» — дигән ялкынлы өндәмә белән мөрәҗәгать итә. Тукай татар балаларына «...Тимер, Алтынбик, Япанчы кеби гүзәл милли исемнәребез»нең һәм дөньяви эчтәлекле гарәп-фарсы исемнәренең кушылуын тели. «Гарәп теле — бай телләрнең дә баерагы. Татар исемнәрендә «Тәлгать»ләр толугъ итсен (тусын), «Фаикъ»лар тәфәүвекъ итсен (өстенлек алсын, күбәйсен), «Фатих»лар фәтех итсен (җиңеп чыксын), «Рифгать»ләр тәрәффегъ итсен (югары ашсын)», — ди.

Г. Тукайның ихлас күңелдән әйтелгән бу олы теләгенә, ялкынлы өндәмәсенә халык шул елларда ук колак сала. Ф. Әмирханның «Исемнәрне татарчалаштыру мөнәсәбәте белән» («Мәктәп» журналы, 1914 ел, 5 сан) дигән мәкаләсе әнә шул турыда бик ачык сөйли. Бу мәкалә: «Соңгы елларда Казанның алдынгы гаиләләрендә балаларына чын татарча исемнәр куя башладылар (газеталардан)» дигән сөенеч-куаныч тулы эпиграф белән башланып китә.

Совет чынбарлыгы исә Г. Тукайның әлеге изге теләкләренең тормышка ашуы өчен кирәкле булган барлык шартларны тудырды.

### Дөньяви эчтәлекле гарәп-фарсы чыгышлы алынма исемнәр

Г. Тукай әйткәнчә, гарәп теле (шул җөмләдән фарсы теле дә) дөньяви эчтәлекле кеше исемнәренә дә бай. Аларның

күбесе болгар-татарлар тарафыннан урта гасырларда ук гамәлгә алынган һәм байтагы хәзер дә актив кулланыла.

Төрки-татар чыгышлы борынгы кеше исемнәребезнең лексик-семантик төркемнәре турында сүз алып барганда, дөньяви эчтәлекле гарәп һәм фарсы телләреннән алынган кеше исемнәренә дә шактый киң тукталган идек.

О. Т. Молчанова төрки халыклардан алтай исемнәренә ясаган семантик классификациясендә «Кешенең рухи һәм материаль халәтенә бәйле исемнәр» дигән зур төркемгә: 1) иҗтимагый мөнәсәбәтләргә бәйле кеше исемнәре; 2) төрле һөнәр һәм профессияне белдерүче кеше исемнәре; 3) йорт-җир һәм көнкүреш әсбапларын белдерүче кеше исемнәре; 4) өс киеме һәм бизәнү кирәк-яракларына нисбәтле кеше исемнәре; 5) хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән бәйле кеше исемнәре дигән төркемчәләрне кертеп карый (Молчанова О. Т., 1970). Татар исемнәре хәзинәсендә урын алган дөньяви эчтәлекле гарәп һәм фарсы исемнәре дә, шушы яссылыкта классификацияләгәндә, югарыда күрсәтелгән бүленеш кысасына кереп бетәләр диярлек.

Гарәп һәм фарсы телләре флектив телләр системасына керә, ягъни гарәп һәм фарсы сүзләренең формалары аффикслар белән генә түгел, ә эчке флексия ярдәмендә дә ясала.

Татар телендә исемнәр грамматик җенес буенча бербереннән аерылмыйлар. Гарәп исемнәрендә исә ике грамматик җенес категориясе бар: м ө з ә к к ә р (мужской род) һәм м ө ә н н ә с (женский род).

Фарсы телендә мөзәккәр һәм мөәннәс категориясе юк. Әмма гарәп теле йогынтысында фарсы телендә дә кеше исемнәрендә мондый категория шактый нык чагыла: Дилроб — Дилроба, Рузи — Рузия, Рушан — Рушания һ. б. Татар теленә кабул ителгән гарәп сүзләренең род категориясе бигрәк тә кеше исемнәрендә чагылыш таба: Рәхим — Рәхимә, Сабир — Сабира, Сәлим — Сәлимә, Хәлим — Хәлимә, Җәмил — Җәмилә һ. б.

Татар телендәге дөньяви эчтәлекле гарәп һәм фарсы исемнәрен югарыда күрсәтелгән семантик төркемчәләргә һәм җенес категориясенә нисбәтле рәвештә: а) *хатын-кыз исемнәренә;* б) *ир-ат һәм хатын-кыз исемнәренә* (парлы исемнәр) һәм в) *ир-ат исемнәренә* аерып, анализлап чыгыйк.

1. И җ т и м а г ы й м ө н ә с ә б ә т л ә р г ә б ә й л е к е ш е и с е м н ә р е: Боларга политик мөнәсәбәтләргә караган һәм социаль халәтне белдерүче исемнәр керә: а) хатын-кыз исемнәре — Вәфидә (делегат, илче), Зәмрә (җәмәгать, төркем, класс). Мәрсүлә (илче), Мәккәмә (хөкем йорты, суд),

б) парлы исемнәр (ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре) — Вәкил — Вәкилә (ышанып җибәрелгән кеше, вәкил), Каид — Каидә (җитәкләүче, җитәкче, юлбашчы), Назир — Назирә (мөдир, министр), Наиб — Наибә (урынбасар, наместник), Рәис — Рәисә (башлык, җитәкче, председатель), Рәсил — Рәсилә (җибәрелүче, илче, вәкил), Рәсүл — Рәсүлә (илче, хәбәр китерүче), Сәфир — Сәфирә (илче, тулы хокуклы вәкил); в) ир-ат исемнәре — Голәм (кол, малай), Ибәт (коллар), Даяр (монах), Ислах (реформа) һ. б.

2. Төрле һөнәр һәм профессияләрне белдерүче кеше исемнәре: а) хатын-кыз исемнәре — Асия (дәвалаучы, табибә, врач), Маһирә (оста, мастер, һөнәр иясе), Рәдинә (эрләүче), Тәбибә (дәвалаучы, врач, доктор), Шаирә (шагыйрә), Фәния (Фәния — артистка); б) парлы исемнәр (ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре) — Газыйф — Газыйфә (музыкант, башкаручы), Насыйф — Насыйфә (хезмәтче), Рәсим — Рәсимә (рәсем ясаучы, художник), Сәүбән — Сәүбәнә (карап, тәрбияләп торучы), Талиб — Талибә (укучы, шәкерт, студент), Таҗир — Таҗирә (сәүдәгәр, сатучы), Шәфи — Шәфия (шифа бирүче, дәвалаучы, тәбиб, доктор), Фәкый — Фәкыйһә (юрист), Харис — Харисә (игенче, сабанчы, сукачы, сакчы), Хасип— Хасибә (хисапчы, хисаплаучы), Рәкыйп — Рәкыйбә (күзәтүче, контролер), Гамил — Гамилә (эшләүче, хезмәт итүче, гамәл кылучы), Хатип — Хатибә (оратор, вәгазь сөйләүче), Хаҗип — Хаҗибә (хезмәтче, швейцар), Зариг — Зарига (игенче), Мөсәүвир — Мөсәүвирә (архитектор, рәссам), Катип — Катибә (язучы, секретарь), Таир — Таирә (очучы); в) ир-ат исемнәре — Вассиф (врач, табип, рецепт язучы врач), Гавас (суга чумучы, водолаз), Гамит (гаскәри, сугышчы), Гаттар (хушбуйлар ясаучы һәм сатучы), Гыйльфан (алтын-көмешче, ювелир), Гыймай (хезмәтче), Даян (өлкән судья), Каувас (укчы), Мөдир (мөдир, башлык, идарә итүче), Мөдәррис (югары уку йортларында дәрес бирүче укытучы), Наикъ (курайчы, музыкант), Наҗар (балта остасы, балтачы), Саят (аучы, сунарчы), Сәях (сәяхәтче, дөнья гизүче, турист), Тәрҗеман (тәрҗемәче, толмач), Фавил (борчак белән сату итүче), Сөнгать (осталык, һөнәр) һ. б.

Югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, хатын-кызлар өчен дәвалаучы, эрләүче кебек эш-һөнәр төрләре, ә ир-ат өчен сәүдәгәр, хәрби хезмәткәр, сакчы, укчы, балта остасы, сунарчы кебек эш-кәсеп төрләре хас. Хатын-кыз һәм ир-ат өчен уртак эш-һөнәр төрләре: музыкант, җырчы, дәвалаучы, хисапчы, юрист, художник һ. б.

3. **Йорт-җир, көнкүреш әсбапларын белдерүче кеше исемнәре**: а) хатын-кыз исемнәре — Маидә (яулык, кулъяулык), Мәхфәзә (саклау өчен эченә әйбер салына торган савыт; сумка), Мәшрәбә (су эчә торган савыт, кружка), Мәэва (торак йорт, сыену урыны), Сайфия (дача, җәй көне тора торган урын), Сәфинә (зур көймә), Фәйтүнә (арба, карета), Каимә (казык, багана, терәк); б) парлы исемнәр (ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре) — Кәндил — Кәндилә (яктыртучы, лампа, шәм, люстра), Сираҗ — Сираҗия (яктырткыч, шәм, лампа, факел); в) ир-ат исемнәре — Гомдә (колонна, таяныч, терәк), Микъраз (кайчы), Миндель (кулъяулык), Мифтах (ачкыч), Мисбах (яктылык чыганагы, яктырткыч, шәмдәл, лампа), Тәбәр (балта) һ. б.

4. **Өскиеме һәм бизәнү кирәк-яракларына нисбәтле кеше исемнәре**: а) хатын-кыз исемнәре — Дәһинә (иннек, кершән), Хәлия (хатын-кызның бизәнү әйберләре), Хәллия (кием-салым, костюм); б) парлы исемнәр (ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре) — Гамбәр — Гамбәрия (хушбуй, исле май), Зәйни — Зәйния (бизәкле, бизәлгән); в) ир-ат исемнәре — Зөннар (билбау, кушак), Зиннәт (бизәк, затлы әйбер) һ. б.

5. **Хайванар һәм үсемлекләр дөньясы белән бәйле кеше исемнәре**: Хайваннар дөньясына нисбәтле исемнәр: а) хатын-кыз исемнәре — Газалия (тау кәҗәсе, антилопа), Былбыл (сандугач), Гыйкрәмә (ана күгәрчен), Дөлделә (Гали хәлифә атланып йөргән качыр исеме); б) парлы исемнәр (ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре) — Тавис — Тависә (тавис кошы), Яги — Ягия (акчарлак); в) ир-ат исемнәре — Сәмүр (кош исеме), Бурак (ата дөя), Әбалил (яр карлыгачы, керәшә), Бәкер (дөя баласы, бота) һ. б. Үсемлекләр дөньясына нисбәтле исемнәр: а) хатын-кыз исемнәре — Вәрака (яшь яфрак), Галлә (ашлык бөртеге), Гыйнәбә (йөзем), Дәлия (георгин гөле чәчәге, йөзем тәлгәше), Зәрига (шытым, үренте), Рауза (чәчәкле болын, гөлбакча), Сәмәрия (җимешле әйбер), Мөсәмирә (җимеш бирүче), Сөмбелә (1. ашлык башлыгы; 2. сөмбел чәчәге), Хөбәйбә (орлык, ашлык бөртеге), Сәрби (кипарис, сәрви агачы), Ләлә (тюльпан чәчәге), Шәҗәрә (нәсел агачы); б) парлы исемнәр (ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре) — Зәбиб — Зәбибә (йөзем, йөзем бөртеге), Самир — Самира (җимеш бирүче, җимеш агачы), Зәйтүн — Зәйтүнә (зәйтүн агачы һәм җимеше); в) ир-ат исемнәре — Ногман (лалә чәчәгенең бер төре), Тәлха (акация) һ. б.

Үсемлек атамасына нисбәтле, бигрәк тә *гөл* компонентлы гарәп һәм фарсы исемнәре башлыча хатын-кызларга кушыла.

Татар антропонимиконының гарәби һәм фарсы генезисле хатын-кыз исемнәре сурәтләү исемнәре төркемен тәшкил итәләр. Бу исемнәр күбрәк матурлык, гүзәллек нәфислек, күркәмлек, назлылык, сылулык сыйфатлары белән бәйле. Гарәби һәм фарсы чыгышлы ир-ат исемнәребезнең күпчелеге теләк исемнәре төркеменә карый. Аларына патриотизм, батырлык, кыюлык, белемгә, акыл-тәүфыйкка, кәсеп-һөнәргә ия булу мәгънәләре хас.

Борынгы болгар-татар кеше исемнәренең күбесе җыйнак төзелешле, җиңел әйтелешле булган. Алар, башлыча, ике, сирәк кенә өч иҗектән торган. Аз иҗекле төзелеш исемнәрне кыскартып, бозып әйтүгә юл калдырмаган. Ике иҗектән торган исемне тагын да кыскартып әйтү ихтыяҗы тумаган, чөнки ул болай да җыйнак, әйтү, эндәшү өчен уңай, сөйләү-аралашу өчен экономияле. Мондый борынгы болгар-татар исемнәре өч төрле юл белән ясалганнар.

Беренчеләре ике яки өч иҗекле тамыр сүздән гыйбарәт күмәклек сүзләрнең кеше исеменә әверелүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән: Тимер, Булат, Балкыш, Энҗе, Чәчкә, Арыслан, Чулпан, Үтәмеш, Туктар, Сыртлан, Сылу, Батыр, Карлыгач, Күке, Тәңкә, Алмуш, Алыр, Канак һ. б.

Икенчеләре бер яки ике иҗекле тамыр сүзләрне бергә кушу юлы белән ясалган: Айтуган, Айсылу, Айбикә, Көнсылу, Таңсылу, Иштирәк, Ишбирде, Ишбулды, Алтынбәк, Алтынчәч, Алтынбай, Миңлебай, Гөлбикә, Гөлнур, Миңсылу, Туйбикә, Табташ, Бикташ, Ташбулат, Тимерташ, Таштимер, Чалбай, Чанчура, Байчура, Бикчура, Тимерхан, Хантимер һ. б.

Өченчеләре бер яки ике иҗекле тамыр сүзгә: 1) *-ай, -әй;* 2) *-кай, кәй;* 3) *-ач, -әч,* 4) *-ак, -әк / -ук, -үк, -ык, -ек;* 5) *-аш, -әш;* 6) *-кач, -кәч;* 7) *-каш, -кәш;* 8) *-ан, -ән;* 9) *-чык, -чек;* 10) *-кына, -кенә, -гына, -генә;* 11) *-тай, -тәй;* 12) *-най, -нәй;* 13) *-ка, -кә* һ. б. кебек иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялгану нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Мондый юл белән ясалган кеше исемнәре аз түгел: Балтай, Тукай, Уразай, Котлыкай, Әлкәй, Тимеркәй, Йөзлекәй, Гөлкәй, Балтач, Тукач, Әтрәч, Уразак, Чурак, Дәвек, Кодаш, Тугаш, Тиниш, Бүкәш, Килдеш, Тиңкәч, Татлыкач, Сатукач, Татукаш, Тиңкәш, Балтан, Дәүләкән, Чурачык, Колчык, Уразчык, Бәйчек, Байгына, Ишкенә, Биккенә, Колтай, Чурмантай, Биктай, Гөлнәй, Апанай, Ишнәй һ. б

Кайбер исемнәр исә икешәр иркәләү-кечерәйтү кушым-

часы кабул иткән: Абашкай (аба — «өлкән ир туган, абый» + *-ш* + *-ай*»), Бикчәнтәй (*бик* — «нык» + *-чән* + *-тәй*) һ.б. Борынгы кеше исемнәре составында урын алган антропонимик иркәләү-кечерәйтү кушымчаларының күбесе әле хәзер дә татар халкының җанлы сөйләм телендә (диалектларда һәм сөйләшләрдә) кеше исемнәре сферасында шактый актив кулланылышка ия.

Борынгы исемнәребезнең ике иҗекле төзелештән гыйбарәт традицион милли калыбы соңрак татар теленә гарәп, фарсы һәм рус телләреннән алынган исемнәрнең һәм ике тел сүзе кушылып ясалган гибрид исемнәрнең төзелеш-әйтелешенә дә зур йогынты ясый. Аларның фонетик йөзе, морфологик төзелеше татар теле закончалыкларына шактый нык буйсындырылган хәлдә үзләштерелә. Әлеге ике иҗекле калып тәэсирендә халык өч-дүрт иҗектән торган алынма кеше исемнәрен ике иҗеккә калдырып кыскарта, борынгы исемнәребезгә тартымлы итеп, аларга типологик якынайтып куллана.

Татар телендә гарәби һәм фарсы чыгышлы кеше исемнәрен кыскартып әйтү, аларны фонетик-морфологик яктан үзләштерү нигездә югарыда күрсәтелгән антропонимик иркәләү-кечерәйтү (субъектив бәя) кушымчалары ярдәмендә формалаштырыла:

*-ай, -әй / -ый, -и:* Камалетдин > Камай > Кашшафетдин > Кашай, Билалетдин > Биләй, Фәсхетдин > Фәсхи, Фәсәй, Фәси, Мостафа>Мостай яки Мостый, Мортаза>Мортый, Фәхретдин>Фәхри, Фәйзулла>Фәйзи, Фирдәүсә>Фирди, Хәмделниса>Хәмди, Җәләлетдин>Җәләй, Әсәдулла>Әскый һ.б.

*-ка, -кә:* Сәйфулла>Сәйкә, Ярулла>Яркә, Садретдин>Садка һ. б.

*-кай, -кәй* (диалекталь вариантлары *-ка, -кә, -ки*): Сибгатулла>Сибкай, Кәлимулла>Кәлкәй, Газизулла>Газикәй, Шәмсетдин>Шәмкәй, Дәүләткәй>Дәүләки, Гыйбадулла>Гибәкә һ. б.

*-ач, -әч, -уч, үч:* Нурмөхәммәт>Нурмач, Рәхмәтулла>Рәхмүч, Хәлиулла>Хәлүч, Хәбибулла>Хәбүч, Кәбирулла>Кәбүч, Хәйрулла,>Хәйрүч, Талибулла>Тәлүч, Мәрьям>Мәрүч һ. б.

*-ак, -әк, -ук, (-юк), -үк:* Мифтахетдин>Митак, Вәлиулла>Вәләк, Шаһидулла>Шайдук, Заһидулла>Зайдук, Галиулла>Алюк, Шәмсетдин>Шәмүк, Идиятулла>Идюк, Шәңгәрәй>Шәнүк, Ишмөхәммәт>Ишүк һ. б.

*-аш, -әш, -ыш, -еш, -уш, -үш:* Ибраһим>Ибраш, Зәйнетдин>Зәйнәш, Габдулла>Габдуш яки Апуш, Сәйфул-

ла>Сәйфуш, Сәлимулла>Сәлмүш, Гайнекамал>Гайнуш, Бикмулла>Бикмуш, Хәйретдин>Хәйрүш, Бәдретдин> Бәдрүш, Җәләлетдин>Җәләш һ. б.

Татар телендә алынма кеше исемнәре түбәндәге фонетик-акцентологик чаралар ярдәмендә дә кыскартыла:

1) кушма тамырлы кеше исемнәренең беренче өлешен ташлап, икенче өлешен генә әйтү (а ф е р е з и с): Вәлиәхмәт>Әхмәт, Хәбибрахман>Рахман, Габделхак,>Хак, Хөснижамал>Җамал, Габделхәй>Хәй, Фәтхелислам> Ислам, Мингази>Гази, Маһисәрвәр>Сәрвәр, Бибиҗамал>Җамал һ. б.

2) кушма тамырлы кеше исемнәренең икенче өлешен ташлап, беренче өлешен генә әйтү (а п о к о п а): Нуриәхмәт>Нури, Гарифулла>Гариф, Сираҗетдин>Сираҗ, Сафиулла>Сафи, Әсфәндияр>Әсфән, Сәрбиҗамал>Сәрби, Маһикамал>Маһи, Әһликамал>Әһли, Әсмабану>Әсма, Зиһникамал>Зиһни һ. б.

3) алынма исемнең баштагы иҗеген яки иҗекләрен кыскарту (а ф е р е з и с): Җомгакай>Йомакай>Макай, Исрафил>Рафил, Өммехани>Мохани, керәшен татарлары Александрны — Сандыр, Александраны — Сандра диләр һ. б.

4) исем уртасында сузык авазны, авазлар тезмәсен яисә иҗекләрне кыскарту (с и н к о п а): Халисә>Халсә, Газизә>Газзә, Хәдичә>Хәйчә, Нәфисә>Нәфсә, Гафифә>Гаффә, Нурдидә>Нурдә, Шаһинур>Шайнур, Бикмөхәммәт>Бикмәт, Уразмөхәммәт>Уразмәт, Ширмөхәммәт>Ширәмәт, Шаһимөхәммәт>Шахмәт, Әлмөхәммәт> Әлмәт, Ирмөхәммәтшәез>Ирмешык, Миңлеҗиһан>Минҗан, Миңлехан>Минхан, Мөхәммәтша>Мәтша, Мөхәммәтәюп>Мәюп, Мөхәммәтиш>Мадыш яки Маеш, Хәлиулла>Хәллә һ. б.

5) исемнең соңгы иҗеген яки иҗекләрен кыскарту (а п о к о п а): Мөхәммәт>Мөхәм, Сөләйман>Сөләй, Габдулла>Абдул, Хәйрулла>Хәйрул, Хөснулла>Хөснул, Лотфулла>Лотфул, Гайнулла>Гайнул, Кәүсәрия> Кәүсәр, Җәүһәрия>Җәүһәр, Бибисара>Бибиса, Фатыйма>Фатый, Әбүәпсәләм>Әбүәп һ. б.

6) исем уртасындагы һәм азагындагы сузык авазларны яки иҗекләрне кыскарту: Миләүшә>Милүш, Хәбибулла>Хәбул, Газизулла>Газул, Хәбибрахман>Хәбра һ. б.

7) исемнең баштагы һәм соңгы иҗекләрен кыскарту: Мөсәббихә>Сәбби, Мөхәммәтдин>Хәммәт, Гыйбадулла> Бадул һ. б.

Татар телендә гарәп һәм фарсы исемнәренең фонетик-морфологик үзгәрешләр кичерүенә, борынгы төрки-татар кеше исемнәренең гомумтөрки һәм болгар чорыннан ук килә торган ике иҗекле традицион җыйнак милли калыбы тәэсиреннән тыш, телебезнең диалекталь фонетик системалары да шактый зур йогынты ясаган.

Билгеле булганча, татар телендә өч диалект бар: урта диалект, көнбатыш (мишәр) диалекты һәм көнчыгыш (себер татарлары) диалекты. Бу диалектларның һәркайсы берничә сөйләшкә аерыла.

Татар теленең диалект һәм сөйләшләренә хас булган төп фонетик үзенчәлекләр гарәби һәм фарсы чыгышлы алынма кеше исемнәрен әйтү-үзләштерүдә дә чагылыш таба.

Урта диалектка хас «җ»ләштерү күренеше тәэсирендә һәм *я (йа, йә)* авазына башланган алынма исемнәр «җ»-ләштереләләр: Якуп>Җакуп, Ясмин — Ясминә>Җәсмин — Җәсминә, Ярулла>Җарулла, Язит — Язидә>Җәзит — Җәзидә, Яһүдә>Җәһүдә һ. б.

Көнбатыш һәм Көнчыгыш диалектларга, киресенчә, «й»ләштерү күренеше хас. Бу диалектларда сүз башында «Җ» авазы әйтелергә тиешле алынма исемнәрне дә «й»-ләштереп әйтәләр: Җәмил — Җәмилә>Йәмил — Йәмилә, Җәббар>Йаббар, көнчыгыш диалектта Чаппар, Җәүдәт>Йәүдәт, Җамал>Йамал (көнчыгыш диалектта Чамал) һ. б.

Урта диалектның күпчелек сөйләшләренә *«ф»* тартыгын *«п»* белән алмаштырып сөйләү хас: Фатыйма>Патыйма, Фатих>Патих, Фазлый>Пазлый, Фәхри>Пәхри һ. б.

Көнбатыш диалектның фонетик системасында w, ғ («гаен») к, х, һ тартыклары юк. Составларында әлеге авазлар булган алынма исемнәр дә диалекталь әйтелешкә дучар ителәләр: Wәли>Вәли, Гариф>Ариф, Галим>Алим, Галия>Алия, Гадил>Адил, Гаделниса>Әделниса, Хәмзә>Әмзә, Хәлимә>Әлимә, Һади>Ади, Һания>Ания, Һәдия>Әдия, Маһинур>Майнур, Җиһанша>Йианша, Заһидә>Заидә, Хәдичә>Кәдцә>Кацюк һ. б.

Көнбатыш һәм Көнчыгыш диалект вәкилләре дифтонгларны монофтонглаштырып сөйлиләр: кыйбат>кибат, кайчан>кацан, Барый>Бари, Бакый>Баки һ. б.

Татар теленең көнчыгыш диалектында яңгырау *б, д, ж з, җ* авазлары кулланышта йөрми. Алар алынма исемнәрдә дә саңгырау парлары белән алмашына. Б>п, з>с, д>т, ж>ч күчеше барлыкка килә: Бану>Пану, Баттал>Паттал, Дания>Тания, Диларә>Тиларә, Зарифа>Сарифа,

Җәмил — Җәмилә>Чәмил — Чәмилә, Энҗе>Энче, Җаббар>Чаппар, Таҗетдин>Тачеттин һ. б. Себер татарлары теленә тартык авазларның борынгы составы саклану хас. Шуңа көнчыгыш диалектта алынма *ф, х, һ* тартыклары юк. Ф>п, х>к күчеше хас: Фазыл>Пасыл, Зифа<Сипа, Фәез>Пәес, Харис>Карис, Хәтимә>Кәтимә, Хәдичә,<Кәдичә, Фатиха>Патига. Ике сузык уртасында килгәндә *«х»* тартыгы *«г»* яңгырау тартыгына күчә: Ахун>Агун, Әхмәт>Әгмәт һ. б. *һ* авазы бөтенләй төшеп кала: Һади> Ати, Һарун>Арун, Зөһрә>Сөрә, Таһир — Таһира>Таир — Таира, Җиһанша>Чианша, Заһир>Саир һ. б. Ғ («гаен») авазына башланган алынма исемнәрдә бу аваз себер татарлары әйтелешендә дә, татар-мишәрләрдәге кебек, бөтенләй төшеп кала: Гали>Али, Галия>Алия, Галим> Алим, Галимә>Алимә, Гайса>Айса, Гарифә>Арифә һ. б.

Шулай итеп, татар антропонимиконының катлаулы үсеш эволюциясе кичереп формалашуын, аның төрле этнолингвистик катламнарны, лексик-семантик төркемнәрне һәм телара бәйләнеш-контактлашу күренешләрен үз эченә алуын күреп үттек.

## БӨЕК ОКТЯБРЬ ҺӘМ ИСЕМНӘРЕБЕЗ

Барлык төр ялгызлык исемнәре, тел факты буларак, җәмгыять төзелеше һәм аның тарихы белән бик тыгыз бәйләнгән. Совет властеның җитмеш ике елы дәвамында татар теленең барлык тармаклары да киң колачлы, тирән һәм катлаулы үсеш, баю, тулылану процессын кичерде. Социалистик тормыш шәһәр, авыл, поселок һ. б. топонимиясенә һәм антропонимиягә (бигрәк тә исемнәргә, фамилияләргә, псевдонимнарга) сизелерлек тәэсир ясады. Телебезнең ялгызлык исемнәре (ономастика) тармагында да яңа сыйфатлар барлыкка килде, үзгәрү-үсү процессы хәзер дә дәвам итә.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң, татар антропонимиясендә баю һәм яңару процессы, нигездә, түбәндәге дүрт төрле юл белән бара:

1. Борынгы исемнәрнең, традицион рәвештә саклана килеп, яшь буынга бирелә баруы. Татар теле тарихында ерак гасырлардан килә торган, борынгы гореф-гадәтләр, мәҗүси йолалар белән бәйләнешле төрки-татар исемнәре (Тимер, Алтын, Булат, Миңлегөл, Арслан, Сусылу, Карлыгач, Үлмәс, Айсылу, Айтуган, Айдар, Айрат, Алмаз, Чулпан, Тансык, Илбарс, Сөендек, Миңсылу һ. б.) һәм X гасырдан башлап болгар-татарларга ислам дине аша кергән гарәп һәм фарсы исемнәренең җыйнак (күбесенчә ике иҗекле), матур яңгырашлы дөньяви мәгънәлеләре (Фәрит, Фәридә, Хәмит, Хәмидә, Халит, Халидә, Харис, Мансур, Вахит, Сания, Гадил, Гадилә, Сәгадәт, Зөбәйдә, Шамил, Шамилә, Камил, Наил, Наилә, Равил, Равилә, Дания, Әлфия, Зөлфия, Рәмзия, Дилбәр, Диларә, Дилә, Җәүһәр, Әхәт, Рәис, Рәисә, Фазыл, Галим, Гомәр, Госман, Әмин, Әминә, Мәдинә, Тәзкирә, Нурия, Самат, Фоат, Мансур, Фоадия, Ләйлә, Фатих, Шәүкәт, Өлфәт, Зөлфәт, Җәүдәт, Зәйтүнә, Зөфәр, Зөбәрҗәт, Гөлчирә, Халисә, Мәрҗан, Зөләйха, Кәрим, Кәримә, Рөстәм, Галия, Әнәс, Нияз һ. б.) шушы юнәлешкә карый.

2. Борынгы дини ышанулар (тотемизм һәм анимизм), ислам дине йолалары, туганлык терминнары, колбиләүчелек һәм феодализм чоры сословие титуллары, кәсеп-һөнәр атамалары белән мөнәсәбәтле кеше исемнәренең күбесе, бигрәк тә социалистик җәмгыять кешесенең югары әхлак сыйфатларына, аңы һәм культурасының үсеш дәрәҗәсенә, эстетик зәвыгына туры килми торганнары Октябрьдән соң кулланылыштан төшеп кала бардылар. Хәзерге яшь буын исемнәре арасында: Балтабай, Бишбалта, Байбүре, Бүрехан, Корткай (төрки телләрнең угыз төркемендә, мәсәлән, азәрбайҗан, төркмән, төрек телләрендә *корт* — «бүре»), Котбай, Котлыби, Кочкар (татар теленең көнбатыш диалекты сүзе, үзбәк телендә *кочкар,* татар әдәби телендә *тәкә*), Җанбай, Чалбай (Идел болгарлары телендә *чал* — «таш»), Ташбай, Ташбикә, Таштимер, Байбакты, Байкилде, Ханкилде, Бикмулла, Мәүләкол, Мәүләбай, Балабәй (шуннан Бәләбәй шәһәре атамасы), Балаәмир (шуннан Идел болгарлары шәһәре Балымер атамасы), Бабахан, Тимершәех, Акчура, Колчура, Байчура, Чурабай, Ханбек, Биккол, Аллогол, Сәеткол, Бикморза, Шәһиморза, Морзахан, Ишморза, Чураман, Чурамантай, Чакмак, Чакмагыш, Үтәмеш, Әлдермеш, Бикләмеш, Тозак, Ходайбирде, Динмөхәммәт, Ишгали, Сәйфетдин, Шәйхелислам, Баһаветдин, Борһанетдин, Рамазан, Хакбирде, Аллабирде, Аллагол, Гыйбадулла, Гайнетдин, Сәетхуҗа, Мөхетдин һ. б. кебек бик күп исемнәрне очратмыйбыз диярлек.

3. Бөек Октябрьдән соң татар антропонимиясендә бөтенләй яңа исемнәр барлыкка килде. Аларның ясалу схемасын күздән кичерик.

а) Төрки телләрдә бик борынгы заманнарда ук сүз ясалышында актив чара булган *тамыр сүзне тамыр сүзгә кушу юлы белән хәзерге татар телендә яңадан күп кенә кеше исемнәре ясала* яки шушы юл белән элек ясалган исемнәр актив кулланылышка алына. Мондый кушма исемнәрнең бер компоненты булып *ил, ай, нур, ал, наз, таң, фән* сүзләре шактый еш катнаша. Мәсәлән, Ил, Илсөя, Илсөяр, Илдус, Дусил, Илшат, Илүс, Илүсә, Илгиз, Илгизә, Илгизәр, Илдар, Илсур, Илназ, Илнур, Илтөзәр, Илбизәр, Илдан, Гөл, Гөлшат, Гөлсинә, Гөлсу, Гөлнур, Гөлүсә, Гөлүс, Гөлчәчәк, Гөлсылу, Гөлзәбәр, Гөлназ, Гөлнәзек, Гөлчибәр, Гөлгөл, Гөлйөзем, Гөлүсәр, Гөлнара, Гөлҗәүһәр, Айнур, Айназ, Айзат, Айшат, Айбар, Айгөл, Айзирәк, Айсинә, Айданә, Нур, Нурбәхет, Нурхирәк, Нурсинә, Алнур, Алсинә, Алгөл, Сылуназ, Таң, Таңнур, Таңнура, Таңсылу, Фән, Фән-

заман, Фәнүс, Фәнүсә, Фәнзил, Фәнзилә, Фәнзирәк, Фәнңур, Фәннура, Фәнзия, Фәндил, Фәндилә һ. б.

б) *Кайбер хатын-кыз исемнәре кушма тамырдан гыйбарәт ирләр исеменә хатын-кыз җенесен белдерә торган -а, -ә, -ия кушымчалары ялгану юлы белән барлыкка килде.* Мәсәлән: Илнур — Илнура, Илгиз — Илгизә, Илдар — Илдария, Илсур — Илсура, Айнур — Айнура, Айгиз — Айгизә һ. б. Гади яки кушма төзелеш тәшкил иткән хәлдә хатын-кыз исеме булып йөри торган берничә исемнең әлеге кушымчалар ялгану юлы белән вариантлары пәйда булды: Гөлнар ~ Гөлнара, Нәркиз ~ Нәркизә, Дилбәр ~ Дилбәрә ~ Дилбәрия, Рушан ~ Рушания, Гүзәл ~ Гүзәлия, Ләйсән ~ Ләйсәния һ. б.

в) *Тамыр сүзгә иркәләү-кечерәйтү, сүз ясаучы һ. б. кушымчылар ялгану юлы белән яңа исемнәр барлыкка килә:* Гөлкәй, Гөлдәй, Гөлгенә, Гөлле, Гөлем, Гөлгенәм, Гөлләр, Гөлия, Айлы, Нурлы, Нуркай, Алсу, Сылукай, Чибәркәй, Матуркай, Назлы, Көлемсәр һ. б.

г) *Гамәлдәге кеше исемнәренең структур төзелешенә һәм әйтелеш-яңгырашына охшату, иярү, чагыштыру юлы белән яңа исемнәр ясала.* Татар антропонимиясендә гарәп һәм фарсы телләреннән алынган күп кенә бер үк мәгънәдәге сүзләр ирләр өчен дә, хатын-кызлар өчен дә исем булып йөри (Сабир — Сабира, Хәбир — Хәбирә, Зәки — Зәкия, Раил — Раилә, Җәмил — Җәмилә, Мансур — Мансура, Фоат — Фоадия, Гали — Галия, Мөслим — Мөслимә, Хәлим — Хәлимә, Җәмил — Җәмилә, Әсфир — Әсфирә һ. б.). Род категориясенә ия булган гамәлдәге исемнәргә охшату (хатын-кыз исемнәре *-а, -ә, -ия* род күрсәткечләре алып) нәтиҗәсендә шушы төркемгә керә торган яңа исемнәр барлыкка килде. Мәсәлән: Алмаз — Алмазия, Дулкын — Дулкыния, Азат — Азадия, Наз — Наза, Нур — Нура, Риф — Рифа, Руф — Руфа, Бәйрәм — Бәйрәмия, Раниф — Ранифа, Лавр — Лавра, Рубин — Рубина, Флер — Флера, Эльмир — лә — Нурсил, Венера — Венер, Альбина — Альбин һ. б.

Кайбер хатын-кыз исемнәреннән ир-ат исемнәре дә барлыкка килде: Әкълимә — Әкълим, Халисә — Халис, Нурсилә — Нурсил, Венера — Венер, Альбина — Альбин һ. б. Бу мисалларда шулай ук род категориясе хас булган рус теленең йогынтысы шактый нык сиземләнә.

Г. И. Богин «Лингвистик күренешләрнең психологик аспекты» («Вопросы общего и германского языкознания» җыентыгы, Уфа, 1964) дигән мәкаләсендә Октябрьдән соң татарлар һәм башкортлар арасында *-ра, -са, -за, -рә, -сә, -зә* иҗекләренә беткән яңа хатын-кыз исемнәренең (мә-

сәлән, Венера, Луиза һ. б.) киң кулланылышка кереп баруы һәм моңа әйтелеш-яңгыраш ягыннан иске һәм яңа исем арасында охшашлыкның (мәсәлән, Мөнирә дигән иске исем белән Венера дигән яңа исем арасында) кеше психологиясенә зур йогынты ясавы турында сөйли.

Татарларда яңа туган сабыйга кушу өчен исем сайлаганда бер гаилә һәм нәсел эчендә ир һәм кыз балаларга башлыча әтисе, әнисе яисә иң өлкән абыйсы, апасы исемнәренә рифмадаш исем бирү гадәтенең зур психолингвистик фактор булуын әйтеп китәргә кирәк (мәсәлән, Әхмәтша — Җиһанша — Гаделша — Мөбарәкша — Дәүләтша; Шиһабетдин — Хәйретдин — Шәйхетдин — Җамалетдин — Камалетдин — Сәләхетдин; Габдрахман — Фәйзерахман — Фәтхерахман — Хәбибрахман; Габдулла — Сәлимулла — Хәйбулла—Рәхимулла—Закирулла; Әхмәтҗан—Сәлимҗан—Рәхимҗан — Галимҗан; Сибгать — Тәлгать — Рифкать, Самат — Марат — Ренат; Маһикамал — Зиһникамал — Бибикамал — Хөсникамал — Хәтбикамал — Сәрбикамал; Бибинур — Шәмсенур — Маһинур — Җиһаннур — Гөлнур; Әлфия — Зөлфия — Рәмзия — Фәнзия; Фәйрүзә — Мәфрүзә — Рауза — Луиза — Лениза һ. б.). Югарыда сөйләнгән факторлар тәэсирендә, мәсәлән, Фәйзә, Хафизә, Фәйрүзә, Фирәзә, Фәнүзә, Рауза һ. б. кебек *-за, -зә* иҗегенә рифмадаш яңгырый торган Роза, Луиза, Эльза, Лиза, Лениза, Ленуза исемнәре таралыш алды. Без, татар телендә кеше исемнәрен охшату-чагыштыру, рифмалаштыру тәэсирендә, мәсәлән, Римза исемендә *-«за»* ның хатын-кыз исеме ясый торган кушымчага әверелүе кебек гаять кызыклы факт белән очрашабыз (Рим — ирләр исеме, Римза — хатын-кызлар исеме).

Биредә Октябрьдән соң татарлар арасында кайбер кеше исемнәренең аеруча популярлашуы телдән тыш факторлар белән бәйләнешле булуын күрсәтеп үтү урынлы. Илсөяр, Кадрия, Газинур һәм Резеда исемнәренең киң таралуына Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» (1938 ел), Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» (1935), Г. Әпсәләмовның «Газинур» (1951), Илдар Юзеевның «Таныш моңнар» (1955) әсәрләренең басылып чыгуы, бу әсәрләрне укучының яратуы, алардагы образларга тирән симпатия белән каравы булышлык итте. Илсөяр һәм Кадрия исемнәре 1940 еллардан башлап татар халкының кыз балаларга сөеп кушыла торган исемнәренә әверелделәр. 1950 еллардан алып Газинур һәм Резеда исемнәре популяр булып китте. Башкорт халкының баһадир улы Салават Юлаев, герой шагыйребез Муса Җәлил, Бөек Ватан сугышында

һәлак булган патриот шагыйрьләребез Фатих Кәрим, Гадел Кутуй хөрмәтенә ир балаларга Салават, Җәлил, Фатих, Гадел ~ Адиль исемнәрен бирү күзәтелә. СССР халык артисты Шәүкәт Биктимиров, РСФСР халык артистлары Илһам Шакиров, Айрат Арсланов хөрмәтенә 60—80 нче елларда ир балаларга Шәүкәт, Илһам, Айрат исемнәрен кушу шактый популяр булды.

Галиябану, Зөбәрҗәт, Әнисә, Зәйтүнә, Нурия, Зөләйха, Раушания, Зөлфия, Рәйхан, Фазыл, Сәрия, Фирдәвес, Әлфия, Рәмзия, Сания, Мәдинә, Тәзкирә һ. б. исемнәрнең киң таралуы шушы исемнәргә багышланган татар халык җырлары булудан да килә, әлбәттә.

д) *Кайбер күмәклек исемнәре* (табигатьтәге, тормыштагы күркәм нәрсәләрне, күренешләрне яки социаль-политик төшенчәләрне белдерүче сүзләр) *кеше исемнәре итеп кулланыла башлады:* Чәчәк, Чәчкә, Иркә, Миләүшә, Сөмбел, Лалә, Кояш, Ирек, Азат (сирәк булса да Азат дигән хатын-кыз исеме дә очрый), Бүләк, Очкын, Ялкын, Сандугач, Ләйсән, Ләззәт, Зәвык, Тырыш, Тамчы, Йөзем, Җиләк, Йолдыз, Офык, Шәфәкъ, Аяз, Алма, Якут, Хөррият, Дулкын, Ташкын, Таң, Нур, Байрак, Ландыш, Рубин һ. б.

4. Октябрь революциясеннән соңгы татар антропонимиконына рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән байтак кына исемнәр алынды. Интернациональ характердагы алынма исемнәрне төзелешләре ягыннан ике төркемгә аерып карый алабыз:

а) *тамыр яки нигез сүздән гыйбарәт исемнәр:* Лена, Марат, Марс, Роза, Флер, Флера, Клара, Лилия, Венера, Луиза, Светлана, Резеда, Идеал, Идел, Лариса, Эдуард, Эльмира, Эльза, Карл, Люзия, Октябрь, Октябрина, Энгель, Роберт, Альберт, Розалия, Марсель, Розалина, Марсельеза, Эрнст, Аида, Спартак, Фрунзе, Фидель, Юрий, Юлия, Альбина, Тамара, Ирина, Эмма, Земфира, Нинель (Ленин фамилиясен азаккы авазДан башлап әйтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән) һ. б.

б) *аббревиатур* (кыскартылган кушма) *исемнәр.* Аларның күбесе революцион вакыйганың, халыкара яки совет оешмаларының, атаклы кешеләрнең исеменнән ясалган. Мәсәлән: Вил, Вилен, — Вилена (Владимир Ильич Ленин), Владлен — Владлена (Владимир Ленин), Марлен — Марлена (Маркс, Ленин), Изил (исполнитель заветов Ильича), Ким (Коммунистический интернационал молодежи), Дипр (Диктатура пролетариата), Юнир (Юный революционер), Ленуза (Ленин — Ульянов заветлары), Лениз — Ленизa (Ленинские заветы), Ленар — Ленара (Ленинская армия),

Дамир — Дамира (Да здравствует мир!) һ. б. Хезмәт халкына азатлык китергән революция сүзен икегә бүлү юлы белән Рево дигән ир балалар (сирәк булса да кыз балаларга да кушыла) һәм Люция дигән кызлар исеме барлыкка килде. Бер семья эчендә ир балага Рево, кыз балага Люция дип исем бирү фактлары булды. Аббревиатур исемнәрнең Вил, Ким, Изил, Дамир, Дамира, Люция, Ленар, Ленара, Лениза һ. б. Кебекләре татар антропонимиконында хәзер дә популяр.

Билгеле булганча, совет чорында рус телендә төрле типтагы бик күп кыскартылган кушма сүзләр — аббревиатуралар барлыкка килде. Телнең гомуми системасына хас булган бу күренеш шул системаның ялгызлык исемнәре тармагына үтеп керде. Аларның байтагы татар теленә, аның антропонимиясенә һәм топонимиясенә кабул ителде.

Телебезгә рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән исемнәрнең кайберләре хәзерге вакытта, әйткәнебезчә, бик киң таралган. Күренекле совет ономасты В. А. Никонов «Төрки халыкларда кеше исемнәре» дигән мәкаләсендә, 1967 елда татарлар арасында ир балаларга Альберт, Роберт һәм Марсель, кыз балаларга Лилия, Роза, Резеда, Венера, Эльмира, Лена исемнәренең бик күп бирелүен хәбәр итә. Татарстанда, мәсәлән, 1967 елда 300 малайга Альберт исеме кушылган (Никонов В. А., 1974).

Октябрьдән соң балаларга туган айларының исемнәрен бирү традициясе хәзерге ай исемнәрен бирү юлы белән дәвам иттерелә: Октябрь, Октябрина, Май, Маец, Август, Августина, Сентябрина, Декабрина, Ноябрина, Марта һ. б. «Безнең якларда Ватан сугышына кадәр һәм аннан соң да, бүгенге көннәрдә дә яңа туган балаларга, Азат, Ирек, Йолдыз исемнәрен еш кушалар. Сирәгрәк булса да, Рево, Люция, Октябрь, Октябрина исемнәре дә очрый», — дип яза Юныс Юсупов «Социалистик Татарстан» газетасының 1988 ел, 7 ноябрь санында басылып чыккан «Октябрев һәм Иректаң» дигән мәкаләсендә.

Шактый гына географик атамалар, кеше исемнәре итеп бирелү аркасында, топонимнан антропонимга әверелделәр. Мәсәлән: Идел, Урал, Казбек, Эльбрус, Һиндия, Алтай, Байкал, Ирания, Саян, Зәй, Рейн, Рим, Кавказ, Памир, Лена, Марсель, Дунай, Иргиз, Ферганә, Әнкарә, Ашказар һ. б. Кеше исемнәре белән географик атамалар арасында элек-электән үзара күчеш яшәп килгән (Килдеураз, Миңлебай, Әлмәт — Әлмөхәммәттән, Акъегет, Күккүз, Пәрәү, Балтач, Азнакай һ. б. — торак пунктлар; М. Болгари,

Әл-Казани, Г. Кандалый, Г. Курсави, Г. Чокрый, Г. Утыз Имәни, Ш. Мәрҗани һ. б.— «йай» нисбә фамилияләр). Совет чорында татар иҗат интеллигенциясе арасында тәхәллүс фамилияне топонимга нигезләп ясау күренеше тагын да активлаша: Г. Иделле, Фатих Сәйфи-Казанлы. Фатих Сәйфи-Уфалы, М. Сөндекле, С. Урайский, Г. Болгарская, Г. Кайбицкая, Г. Камская, Г. Минский һ. б.

Әдәби телдәге бик ерак гасырлардан килә торган *җир, су, таш, яшен, ут, үлән, тамчы, ак, кызыл, ике, өч, җиде, көн, төн, юкә, имән, тары, бодай, кузгалак, ябалак, карга, киңәш, табыш, җитен, туку, тун, күлмәк* һ. б. кебек сүзләр аерым бер җәмгыять, буын, коллектив яки шәхес зәвыгына карап башка сүз белән алмаштырыла алмый. Боларга озын гомер, дәвамчанлык, барлык иҗтимагый формацияләргә һәм буыннарга да шул мәгънәләрендә даими хезмәт итү хас. Хан, чура, ишан, мулла, мөрит, морза, мәдрәсә, азан, сука, тәпәч, гөбе, калдырча һ. б. кебек сословие титуллары, дини терминнар, иске җитештерү кораллары яңа иҗтимагый формация шартларында кулланылыштан төшеп, исемнәре архаизмга әверелә. Бу исә күмәклек исемнәре сферасында сайланмалылык процессының үзенчәлекле чагылышына бер мисал.

Антропонимиядә һәм топонимиядә лексик сайланмалылык бер үк дәрәҗәдә түгел. Антропонимиядә ул процесс шактый киң һәм хәрәкәтчән, чөнки кеше гомере, тормыш диалектикасы көн саен кемнеңдер тууы һәм кемнеңдер үлүе белән бәйле. СССР Үзәк Статистика Идарәсе, мәсәлән, 1965 елда безнең илебездә 4,5 миллион бала тууы турында матбугатта мәгълүмат бирде. Бу сан үзе генә дә бер ел эчендә СССР халыклары телләрендә кеше исемнәренең никадәр хәрәкәтчән булуын, сайланып, яңарып торуын ачык күрсәтә.

Топонимик сайланмалылыкның чикләнгәнлеге, иң элек, физик-географик объект атамаларының тотрыклылыгы, шул территориядә яшәгән халыкларга һәм буыннарга, нигездә, үзгәрешсез хезмәт итүе белән аңлатыла (бигрәк тә елга һәм тау исемнәре үзгәрмичә сакланалар: Идел, Агыйдел, Зөя, Зәй, Ык, Иртыш, Байкал, Шаран, Чирмешән, Сөн, Урал, Алтай, Кабан, Елантау, Кыз тавы һ. б.). Икенчедән, бер иҗтимагый формация икенчесе белән алмашынганда үз диктатурасын урнаштырган сыйныфларның идеологиясенә туры килми торган һәм иске идеологияне чагылдырган географик атамаларны (күбесенчә тарихи-административ объектлар, торак пунктлар һәм урам исемнәрен) җиңүче сыйныф идеологиясенә җавап бирә торган яңа символик

атамалар белән алмаштыру берничә елга сузыла, яңа исемнәргә көчү хөкүмәт карарлары белән һәм хезмәт ияләре тәкъдиме нигезендә дәүләт учреждениеләре (авыл, район, шәһәр Советлары, Верховный Советлар) тарафыннан тормышка ашырыла. Моңа өстәп, яңа торак пунктларның, урамнарның көн саен диярлек барлыкка килмәвен, ягъни мондый объектларга көн саен исем кушу ихтыяҗы булмавын күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң, дини эчтәлекле сүзләр, патша, аның түрәләре, эре сәүдәгәрләр, дворяннар, алпавытлар һ. б. исем-фамилиясе белән аталган торак пункт һәм урам исемнәре социалистик тормыш эчтәлегенә туры килә торган яңа исемнәр белән алмаштырылдылар. Тарихи-традицион һәм фәнни әһәмияткә ия булган күп кенә торак пункт һәм урамнарның элекке исемнәре үзгәртелмәде, бу исә географик объект исемнәренең стабильлеген һәм дәвамчанлыгын, элекке һәм хәзерге географик атамалар арасында мәгълүм бәйләнешне тәэмин итте.

Татар антропонимиясендә билгеле бер тарихи чорда яисә бер ел яки, әйтик, ун ел дәвамында теге яки бу торак пунктта, төбәктә, районда, өлкәдә, республикада ир-ат һәм хатын-кыз исемнәреннән кайсысының иң киң таралуын, кулланышка кайсы яңа исем кергәндә, икенче берсенең кулланылыш мәйданы тараюын яки бөтенләй юкка чыгуын билгеләү киләчәктә, статистик методка таянып һәм ЭВМ кулланып, махсус тикшеренүләр ясауны сорый. Безнең кулдагы мәгълүматларга караганда, мәсәлән, Казанның Идел буе районында иң киң таралган кыз бала исемнәре Гүзәл һәм Фирая, ирләр исемнәре — Фәрит һәм Рөстәм. Татарстанның Зеленодольск районы Норлат төбәгендә соңгы ун ел эчендә иң киң таралган ирләр исеме — Гомәр белән Госман, кызлар исеме — Әлфия белән Фәридә.

Бөек Октябрьдән соң татар антропонимиясе үсешендәге кайбер тенденцияләрне билгеләүдән чыгып, милли антропонимиконыбызда татар халкының социаль-экономик, политик һәм культура казанышлары киң чагылыш тапкан дигән нәтиҗә ясый алабыз.

Бала туды. Дөньяга яңа кеше килде. Аңа кушу өчен исем кирәк. Матур исем, мәгънәле исем, зәвыклы исем, аһәңле исем — кыскасы, әйбәт исем. Татар халкының дистәләрдән артык гасырларны эченә алган тоташ буыннар чылбырыннан гыйбарәт милли исемнәр тезмәсен өзмичә алга таба дәвам итәрлек исем, халык рухын саклый торган исем кирәк. Автор үзенең бу китабы укучыларга шундый исем табарга ярдәм итәр дип ышана.

# ТАТАР ИСЕМНӘРЕ ТУПЛАМЫ

*Татар исемнәре тупламына башта ир-ат (алардан отчество һәм фамилияләр ясалышының кыен очракларын күрсәтеп), аннан соң хатын-кыз исемнәре алфавит тәртибендә татарча һәм русча язылышта урнаштырылды. Тупламга татар халкының яшь, урта һәм өлкән буын вәкилләре йөртә торган милли исемнәрнең зур күпчелеге кертелсә дә, ул тулылыкка дәгъва итми.*

## ИР-АТ ИСЕМНӘРЕ

| *Татарча язылышы* | *Русча язылышы* |
|---|---|
| Абыз | Абыз |
| Абызбакый | Абызбакый |
| Абызгәрәй | Абызгарай |
| Аван | Аван |
| Агаз | Агаз |
| Агат | Агат |
| Агдәл | Агдал |
| Аги (отч. Агиевич, Агиевна; фам. Агиев, Агин) | Аги (отч. Агиевич, Агиевна; фам. Агиев, Агин) |
| Агиш (отч. Агишевич, Агишевна; фам. Агишев) | Агиш (отч. Агишевич, Агишевна фам. Агишев) |
| Азамат | Азамат |
| Азат | Азат |
| Айбак | Айбак |
| Айбар | Айбар |
| Айбарс | Айбарс |
| Айбулат | Айбулат |
| Айбүләк | Айбуляк |
| Айваз | Айваз |
| Айвар | Айвар |

| | |
|---|---|
| Айгиз | Айгиз |
| Айдан | Айдан |
| Айдар | Айдар |
| Айдархан | Айдархан |
| Айдаш | Айдаш |
| Айзат | Айзат |
| Айзәк | Айзак |
| Айкын | Айкын |
| Айман | Айман |
| Айморат | Аймурат |
| Айморза | Аймурза |
| Айназар | Айназар |
| Айнур | Айнур |
| Айрат | Айрат |
| Айсар | Айсар |
| Айсаф | Айсаф |
| Айтимер | Айтимер |
| Айтирәк | Айтиряк |
| Айтуар | Айтуар |
| Айтуган | Айтуган |
| Айчуак | Айчуак |
| Айшат | Айшат |
| Акбәк | Акбек |
| Акбулат | Акбулат |
| Акбүләк | Акбуляк |
| Акдәүләт | Акдавлет |
| Аклаш | Аклаш |
| Акморат | Акмурат |
| Акморза | Акмурза |
| Акназар | Акназар |
| Актай | Актай |
| Актаң | Актан |
| Актимер | Актимер |
| Актуган | Актуган |
| Акчулпан | Акчулпан |
| Акчуак | Акчуак |
| Акчура (отч. Акчурович, Акчуровна; фам. Акчуров, Акчурин, Акчура) | Акчура (отч. Акчурович, Акчуровна; фам. Акчуров, Акчурин, Акчура) |
| Акъегет | Акъегет |
| Акҗан | Акджан, Акзян |
| Алан | Алан |
| Албарс | Албарс |
| Алгай | Алгай |
| Алиш | Алиш |
| Алкын | Алкын |
| Алмаз | Алмаз |
| Алмай | Алмай |
| Алмас | Алмас |
| Алпак | Алпак |
| Алпар | Алпар |
| Алтай | Алтай |
| Алтын | Алтын |
| Алтынай | Алтынай |
| Алтынбай | Алтынбай |

| | |
|---|---|
| Алтынбәк | Алтынбек |
| Алтынгали | Алтынгали |
| Алтынгәрәй | Алтынгарай |
| Алтынтимер | Алтынтимер |
| Алчын | Алчын |
| Альберт | Альберт |
| Аман | Аман |
| Анар | Анар |
| Ансар | Ансар |
| Араз | Араз |
| Аргуван, Әргуван, | Аргуван |
| Ардак | Ардак |
| Ардаш | Ардаш |
| Арзу | Арзу |
| Арзубай | Арзубай |
| Арзубәк | Арзубек |
| Арсен | Арсен |
| Арслан, Арыслан | Арслан |
| Арсланбай | Арсланбай |
| Арслангали | Арслангали |
| Арслангәрәй | Арслангарай |
| Арсланзадә | Арсланзада |
| Артем | Артем |
| Артур | Артур |
| Артыш | Артыш |
| Аршат | Аршат |
| Асаф | Асаф |
| Асыл | Асыл |
| Асылбай | Асылбай |
| Асылбәк | Асылбек |
| Асылгәрәй | Асылгарай |
| Асылзадә | Асылзада |
| Асылзат | Асылзат |
| Асылморат | Асылмурат |
| Асылмәрдан | Асылмардан |
| Асылҗан | Асылджан |
| Атаҗан | Атаджан |
| Атилла | Атилла |
| Атлас | Атлас |
| Атнабай | Атнабай |
| Атнахуҗа | Атнахуджа |
| Афзал | Афзал |
| Афзалетдин | Афзалутдин |
| Афраз | Афраз |
| Ахияр | Ахияр |
| Ахун | Ахун |
| Ахунбай | Ахунбай |
| Ахунгәрәй | Ахунгарай |
| Ахунҗан | Ахунджан, Ахунзян |
| Ашкан | Ашкан |
| Аюхан | Аюхан |
| Аяз | Аяз |
| Аязгол | Аязгул |
| Аязҗан | Аязджан |
| Бабахан | Бабахан |
| Багъдасар | Багдасар |

| | |
|---|---|
| Бадак | Бадак |
| Бадакша | Бадакша |
| Бадам | Бадам |
| Бадамша | Бадамша |
| Байбарс | Байбарс |
| Байбулат | Байбулат |
| Байбәк | Байбек |
| Байбүләк | Байбуляк |
| Байгали | Байгали |
| Байдәүләт | Байдавлет |
| Байиш | Байиш |
| Байкара | Байкара |
| Байкилде | Байкилде |
| Байкуәт | Байкуат |
| Байморат | Баймурат |
| Байморза | Баймурза |
| Байназар | Байназар |
| Байрак | Байрак |
| Байсал | Байсал |
| Байсар | Байсар |
| Байсолтан | Байсултан |
| Байсәет | Байсаит |
| Байтазар | Байтазар |
| Байтимер | Байтимер |
| Байтирәк | Байтиряк |
| Байтуган | Байтуган |
| Байтулла | Байтулла |
| Байхуҗа | Байхуджа |
| Байчура (отч. Байчурович, Байчуровна; фам. Байчуров, Байчурин, Байчура) | Байчура (отч. Байчурович, Байчуровна; фам. Байчуров, Байчурин, Байчура |
| Байшат | Байшат |
| Байъегет | Байъегет |
| Байҗан | Байджан |
| Бакир | Бакир |
| Бакый | Баки |
| Балтай | Балтай |
| Балтач | Балтач |
| Барлас | Барлас |
| Барс | Барс |
| Барсай | Барсай |
| Барый | Бари |
| Басарый | Басари |
| Басыйл | Басиль |
| Басыйр | Басир |
| Баттал | Баттал |
| Бату | Бату |
| Батыр | Батыр |
| Батырбай | Батырбай |
| Батырбулат | Батырбулат |
| Батыргали | Батыргали |
| Батыргәрәй | Батыргарай |
| Батыркай | Батыркай |
| Батырхан | Батырхан |
| Батырша | Батырша |

| | |
|---|---|
| Батырҗан | Батырзян, Батырджан |
| Бахтураз | Бахтураз |
| Баязит | Баязит |
| Баян | Баян |
| Баһави | Багави |
| Баһир | Багир |
| Баһман | Бахман |
| Биарслан | Биарслан |
| Бибарс | Бибарс |
| Бигали (отч. Бигалиевич, Бигалиевна; фам. Бигалиев, Бигалин) | Бигали (отч. Бигалиевич, Бигалиевна; фам. Бигалиев, Бигалин) |
| Биги | Биги |
| Бикбай | Бикбай |
| Бикбау | Бикбау |
| Бикбулат | Бикбулат |
| Биккенә | Биккина |
| Биккол | Биккул |
| Бикморат | Бикмурат |
| Бикморза | Бикмурза |
| Бикмулла | Бикмулла |
| Биктай | Биктай |
| Бикташ | Бикташ |
| Биктаһир | Буктагир |
| Биктимер | Биктимер |
| Биктуган | Биктуган |
| Бикчура | Бикчура |
| Бикчәнтәй | Бикчантай |
| Бикшат | Бикшат |
| Бикҗан | Бикзян, Бикджан |
| Билал | Билал |
| Билалетдин | Билалутдин |
| Биҗан | Биджан |
| Болгар | Булгар |
| Борнаш | Бурнаш |
| Борһан | Бурган |
| Бостан | Бустан |
| Бохар | Бухар |
| Бохарай | Бухарай |
| Булат | Булат |
| Булаттимер | Булаттимер |
| Булатҗан | Булатджан |
| Буран | Буран |
| Буранбай | Буранбай |
| Бурангол | Бурангул |
| Бәдамша | Бадамша |
| Бәдигъ | Бадиг |
| Бәдретдин | Бадретдин |
| Бәйрәм | Байрам |
| Бәйрамгали | Байрамгали |
| Бәйрәмгол | Байрамгул |
| Бәкер | Бакер, Бакир |
| Бәсим | Басим |
| Бәхет | Бэхет |
| Бәхетгәрәй | Бахетгарай |
| Бәхетҗан | Бахетджан |

| | |
|---|---|
| Бәхти | Бахти |
| Бәхтиз | Бахтиз |
| Бәхтияздан | Бәхтияздан |
| Бәхтияр | Бахтияр |
| Бәшир | Башир |
| Бәшәр | Башар |
| Бәһрам | Бахрам, Баграм |
| Бәһрамбәк | Бахрамбек |
| Бәһрамша | Бахрамша |
| Бөркет | Беркут |
| Бөркетбай | Беркутбай |
| Бүзтимер | Бузтимер |
| Бүләк | Буляк |
| Вагыйз | Вагиз |
| Вазыйх | Вазих |
| Вазыйф | Вазиф |
| Ваиз | Ваиз |
| Ваис | Ваис |
| Ваккас | Ваккас |
| Вакыйф | Вакиф |
| Варис | Варис |
| Васи | Васи |
| Васиб | Васиб |
| Васихан | Васихан |
| Вассаф | Вассаф |
| Васыйт | Васит |
| Васыйф | Васиф |
| Ватан | Ватан |
| Вафа (отч. Вафович, Вафовна; фам. Вафин) | Вафа (отч. Вафович, Вафовна; фам. Вафин) |
| Вафи (отч. Вафиевич, Вафиевна; фам. Вафиев, Вафин) | Вафи (отч. Вафиевич, Вафиевна; фам. Вафиев, Вафин) |
| Вахит | Вахит |
| Важип | Вазип |
| Ваһап | Вагап |
| Вил | Виль |
| Вилдан | Вильдан |
| Вилдар | Вильдар |
| Вилнур | Вильнур |
| Вилсур | Вильсур |
| Вәдүт | Вадут |
| Вәзир | Вазир |
| Вәкил | Вакиль |
| Вәли (отч. Вәлиевич, Вәлиевна; фам. Вәлиев) | Вали (отч. Валиевич, Валиевна; фам. Валиев) |
| Вәлид | Валид |
| Вәлим | Валим |
| Вәлиморат | Валимурат |
| Вәлимордза | Валимурза |
| Вәлимәрдән | Валимардан |
| Вәлимөхәммәт | Валимухаммет |
| Вәлинур | Валинур |

| | |
|---|---|
| Вәлирахман | Валирахман |
| Вәлит | Валит |
| Вәлиулла | Валиулла |
| Вәлихан | Валихан |
| Вәлиша | Валиша |
| Вәлияр | Валияр |
| Вәлиәкрәм | Валиакрам |
| Вәлиәхмәт | Валиахмет |
| Вәсил | Василь |
| Вәсим | Васим |
| Вәсимхан | Васимхан |
| Вәсимҗан | Васимджан, Васимзян |
| Вәсиф | Васиф |
| Вәсият | Васият |
| Вәҗи | Ваджи, Вази |
| Вәҗип | Вазип |
| Вәҗит | Вазит |
| Вәҗиәхмәт | Вазиахмет |
| Вәҗүд | Ваджуд |
| Габбас | Габбас |
| Габделбәр | Габдельбар |
| Габделвәли | Габдельвали |
| Габделгазиз | Габдельгазиз |
| Габделгани | Габдельгани |
| Габделгафур | Габдельгафур |
| Габделкадыйр | Габделькадыр |
| Габделкасыйм | Габделькасим |
| Габделкаюм | Габделькаюм |
| Габделкабир | Габделькабир |
| Габделкәрим | Габделькарим |
| Габделлатыйф | Габдельлатиф |
| Габделмалик | Габдельмалик |
| Габделмән | Габдельман |
| Габделмәннаф | Габдельманнаф |
| Габделмәҗит | Габдельмазит |
| Габделнасыйр | Габдельнасир |
| Габделфаяз | Габдельфаяз |
| Габделхак | Габдельхак |
| Габделхаликъ | Габдельхалик |
| Габделхарис | Габдельхарис |
| Габделхәбир | Габдельхабир |
| Габделхәй | Габделхай |
| Габделхәлим | Габдельхалим |
| Габделхәмит | Габдельхамит |
| Габделәхәт | Габдельахат |
| Габделҗәббар | Габдельжаббар, Габдельзаббар |
| Габделҗәмил | Габдельджамиль |
| Габденур | Габденур |
| Габдерәззак | Габдераззак |
| Габдерәкыйп | Габдеракип |
| Гадберәхим | Габдерахим |
| Габдерәшит | Габдерашит |
| Габдерәүф | Габдерауф |
| Габдрахман | Габдрахман |
| Габдулла | Габдулла |

| | |
|---|---|
| Габдуллаҗан | **Габдулладжан, Габдуллазян** |
| Габетдин | Габетдин |
| Габидулла | Габидулла |
| Габит | Габит |
| Габитдин | Габитдин |
| Габсаттар | Габсаттар |
| Габсәлам | Габсалям |
| Габәши | Габаши |
| Гавас | Гавас |
| Гадел | Гадель |
| Гаделбәк | Гадельбек |
| Гаделгәрәй | Гадельгарай |
| Гаделнур | Гадельнур |
| Гаделша | Гадельша |
| Гаделҗан | **Габдельджан, Гадельзян** |
| Гадил | Гадил |
| Газам | Газам |
| Газар | Газар |
| Газзам | Газзам |
| Гази (отч. Газиевич, Газиевна; фам. Газиев) | Гази (отч. Газиевич, Газиевна; фам. Газиев) |
| Газиз | Газиз |
| Газизулла | Газизулла |
| Газизҗан | Газизджан, Газизъян |
| Газим | Газим |
| Газиморат | Газимурат |
| Газимулла | Газимулла |
| Газимхан | Газимхан |
| Газимҗан | Газимджан, Газимзян |
| Газинур | Газинур |
| Газиф | Газиф |
| Газиҗан | Газиджан, Газиян |
| Газыйм | Газим |
| Гайнан | Гайнан |
| Гайнанша | Гайнанша |
| Гайнетдин | Гайнетдин |
| Гайнияр | Гайнияр |
| Гайнулла | Гайнулла |
| Гайрәт | Гайрат |
| Гайсә | Гайса |
| Гайсар | Гайсар |
| Гайфетдин | Гайфетдин |
| Гайфи | Гайфи |
| Гайфулла | Гайфулла |
| Гакиф | Гакиф |
| Гали (отч. Галиевич, Галиевна; фам. Галиев, Галеев, Галин) | Гали (отч. Галиевич, Галиевна; фам. Галиев, Галеев, Галин) |
| Галиарслан | Галиарслан |
| Галибай | Галибай |
| Галибәк | Галибек |
| Гализадә | Гализада |
| Галим | Галим |
| Галимбәк | Галимбек |
| Галиморат | Галимурат |

| | |
|---|---|
| Галиморза | Галимурза |
| Галимулла | Галимулла |
| Галимәрдән | Галимардан |
| Галимҗан | Галимджан, Галимзян |
| Галинур | Галинур |
| Галирахман | Галирахман |
| Галиулла | Галиулла |
| Галихан | Галихан |
| Галишан | Галишан |
| Галишир | Галишир |
| Галияздан | Галияздан |
| Галияр | Галияр |
| Галиәкбәр | Галиакбар |
| Галиәсгар | Галиасгар, Галиаскар |
| Галиәсфәр | Галиасфар |
| Галиәхмәт | Галиахмет |
| Галләм | Галлям |
| Галләметдин | Галляметдин |
| Галәветдин | Галяветдин, Галяутдин |
| Галәви | Галяви |
| Гамбәр | Гамбар |
| Гамил | Гамиль |
| Гамир | Гамир |
| Гаммәр | Гаммар |
| Ганбәр | Ганбар |
| Гани | Гани |
| Гариф | Гариф |
| Гарифулла | Гарифулла |
| Гарифҗан | Гарифджан, Гарифзян |
| Гарәпша | Гарапша |
| Гарәф | Гараф |
| Гәрафетдин | Гарафетдин, Гарафутдин |
| Гарәфи | Гарафи |
| Гасим | Гасим |
| Гасимҗан | Гасимджан, Гасимзян |
| Гаскәр | Гаскар |
| Гата (отч. Гатович, Гатовна; фам. Гатин) | Гата (отч. Гатович, Гатовна; фам. Гатин) |
| Гатаулла | Гатаулла |
| Гатиф | Гатиф |
| Гатифулла | Гатифулла |
| Гатият | Гатият |
| Гатиятулла | Гатиятулла |
| Гаттар | Гаттар |
| Гатуф | Гатуф |
| Гафи | Гафи |
| Гафият | Гафият |
| Гафиятулла | Гафиятулла |
| Гафур | Гафур |
| Гафурбәк | Гафурбек |
| Гафурҗан | Гафурджан, Гафурзян |
| Гаффан | Гаффан |
| Гаффар | Гаффар |
| Гашикъ | Гашик |
| Гаяз | Гаяз |

| | |
|---|---|
| Гаязетдин | Гаязетдин |
| Гаян | Гаян |
| Гаяс | Гаяс |
| Гобәй | Губай |
| Гобәйдулла | Губайдулла |
| Гозәер | Гузаир |
| Гомәр | Гумер |
| Гомәрбәк | Гумербек |
| Госман | Госман, Усман |
| Гүмай | Гумай |
| Гыйбад | Гибад |
| Гыйбадулла | Гибадулла |
| Гыйзам | Гизам |
| Гыйзелхан | Гизельхан |
| Гыйзетдин | Гизетдин |
| Гыйззәт | Гиззат |
| Гыйззәтулла | Гиззатулла |
| Гыйлаҗ | Гиляз |
| Гыйлаҗетдин | Гилязетдин |
| Гыйлаҗи | Гилялжи, Гилязи |
| Гыйлем | Гилем |
| Гыйлемдар | Гилемдар |
| Гыйлемхан | Гилемхан |
| Гыйлемҗан | Гилемджан, Гилемзян |
| Гыйльметдин | Гильметдин |
| Гыйльмулла | Гильмулла |
| Гыйльфан | Гильфан |
| Гыймад | Гимад |
| Гыймади | Гимади |
| Гыймран | Гимран |
| Гыйният | Гинsocket |
| Гыйниятулла | Гиниятулла |
| Гыйрфан | Гирфан |
| Гыйсам | Гисам |
| Гыйсмәт | Гисмат |
| Гыйсмәтулла | Гисматулла |
| Гәрдан | Гардан |
| Гәрәй | Гарай, Гарей |
| Гәрәйхан | Гарайхан |
| Гәрәйша | Гарайша |
| Гүзәлбай | Гузельбай |
| | |
| Дабир | Дабир |
| Давыт | Даут |
| Дамир | Дамир |
| Дан | Дан |
| Данат | Данат |
| Данбулат | Данбулат |
| Данил | Даниль |
| Данис | Данис |
| Даниф | Даниф |
| Данияз | Данияз |
| Даниял | Данияль |
| Данияр | Данияр |
| Дастан | Дастан |
| Даян | Даян |

| | |
|---|---|
| Диар | Диар |
| Дибай | Дибай |
| Дил | Диль |
| Дилар | Дилар |
| Дилбаз | Дилбаз |
| Дилдар | Дильдар |
| Дилияр | Дилияр |
| Дилкәр | Дилькар |
| Дилморат | Дильмурат |
| Дилмөхәммәт | Дильмухаммет, Дильмухамет |
| Дилфар | Дильфар |
| Дилфикәр | Дильфикар |
| Дилшат | Дильшат |
| Дилүс | Дилюс |
| Диләрис | Диларис |
| Динар | Динар |
| Диндар | Диндар |
| Динислам | Динислам |
| Дираз | Дираз |
| Дифгать | Дифгать |
| Дияр | Дияр |
| Диңгез | Дингиз |
| Дунай | Дунай |
| Дусай | Дусай |
| Дусгали | Дусгали |
| Дусил | Дусиль |
| Дусморат | Дусмурат |
| Дусмөхәммәт | Дусмухаммет, Дусмухамет |
| Дуссадыйк | Дуссадык |
| Дәвран | Давран |
| Дәлил | Далиль |
| Дәмин | Дамин |
| Дәминдар | Даминдар |
| Даниф | Даниф |
| Дәүли | Давли |
| Дәүлихан | Давлихан |
| Дәүләт | Давлет |
| Дәүләтбай | Давлетбай |
| Дәүләтбирде | Давлетбирде |
| Дәүләтгали | Давлетгали |
| Дәүләтгәрәй | Давлетгарай |
| Дәүләтнур | Давлетнур |
| Дәүләтхан | Давлетхан |
| Дәүләтхуҗа (отч. Дәүләтхуҗович, Дәүләтхуҗовна; фам. Дәүләтхуҗин) | Давлетхуджа, Давлетхузя (отч. Давлетхуджович, Давлетхуджовна; фам. Давлетхузин, Долоткозин) |
| Дәүләтша | Давлетша |
| Дәүләтъяр | Давлетьяр |
| Дәүләтҗан | Давлетджан, Давлетзян |
| Дәүхан | Давхан |
| Дәүҗан | Давджан, Давзян |
| Дөрзаман | Дюрзаман |
| Егетбай | Егетбай |
| Едегәр | Едигар |
| Елгыр | Елгыр |

| | |
|---|---|
| Елдам | Елдам |
|Еникәй | Еники |
| Ерикәй | Ерики |
| Җан | Жан |
| Җорес | Жорес |
| Заид | Заид |
| Заим | Заим |
| Закир | Закир |
| Закирулла | Закирулла |
| Закирҗан | Закирджан, Закирзян |
| Закуан | Закуан |
| Заман | Заман |
| Замир | Замир |
| Зарафәт | Зарафат |
| Заретдин | Заретдин |
| Зариф | Зариф |
| Зарифулла | Зарифулла |
| Зарифҗан | Зарифджан, Зарифзян |
| Зарраф | Зарраф |
| Зартдин | Зартдин |
| Зарур | Зарур |
| Заһид | Загид |
| Заһидулла | Загидулла |
| Заһир | Загир, Захир |
| Заһирҗан | Загирджан, Загирзян |
| Зиадат | Зиадат |
| Зиннур | Зиннур |
| Зиннәт | Зиннат |
| Зиннәтнур | Зиннатнур |
| Зиннәтулла | Зиннатулла |
| Зиннәтҗан | Зиннатджан, Зиннатзян |
| Зирәк | Зиряк |
| Зияд | Зияд |
| Зиядулла | Зиядулла |
| Зияр | Зияр |
| Зияретдин | Зияретдин |
| Зиһат | Зихат |
| Зыя (отч. Зиевич, Зиевна; фам. Зиев) | Зия (отч. Зиевич, Зиевна; фам. Зиев) |
| Зыятдин | Зиятдин |
| Зыяфәт | Зияфат |
| Зыяәхмәт | Зияахмет |
| Зәбиб | Забиб |
| Зәбил | Забиль |
| Зәбир | Забир |
| Зәбих | Забих |
| Зәвил | Завиль |
| Зәгафуран | Загафуран |
| Зәет | Заит |
| Зәй | Зай |
| Зәйлал | Зайлал |
| Зәйнегали | Зайнегали |
| Зәйнелислам | Зайнелислам |
| Зәйнетдин | Зайнетдин |
| Зәйни (отч. Зәйниевич, Зәйниевна; фам. Зәйниев) | Зайни (отч. Зайниевич, Зайниевна; фам. Зайниев) |

| | |
|---|---|
| Зәйнулла | Зайнулла |
| Зәйсан | Зайсан |
| Зәйсур | Зайсур |
| Зәйтүн | Зайтун |
| Зәйфәр | Зайфар |
| Зәки (отч. Зәкиевич, Зәкиевна; фам. Зәкиев | Заки (отч. Закиевич, Закиевна; фам. Закиев) |
| Зәкиҗан | Закиджан, Закизян |
| Зәкәрия | Закария |
| Зәмил | Замиль |
| Зөбәер | Зубаир |
| Зөлал | Зулаль |
| Зөлкар | Зулькар |
| Зөлкарнай | Зулькарнай |
| Зөлкәбир | Зулькабир |
| Зөлкәрам | Зулькарам |
| Зөлфир | Зульфир |
| Зөлфәкар | Зульфакар |
| Зөлфәр | Зульфар |
| Зөлфәр | Зульфат |
| Зөннар | Зуннар |
| Зөфәр | Зуфар |
| Зөхәл | Зухаль |
| Ибниямин | Ибниямин |
| Ибраһим | Ибрагим |
| Ибриз | Ибриз |
| Ибәт | Ибат |
| Ибәтулла | Ибатулла |
| Игебай | Игебай |
| Игълам | Иглам |
| Идеал | Идеал |
| Идегәй | Идегей |
| Идел | Идель |
| Иделбай | Идельбай |
| Иделбәк | Идельбек |
| Идрис | Идрис |
| Изаиль | Изаиль |
| Изах | Изах |
| Изахетдин | Изахетдин |
| Изһар | Изхар |
| Икрам | Икрам |
| Икъбал | Икъбал |
| Ил | Иль |
| Илал | Илал |
| Илбай | Ильбай |
| Илбар | Ильбар |
| Илбарис | Ильбарис |
| Илбатыр | Ильбатыр |
| Илбәк | Ильбек |
| Илгар | Ильгар |
| Илгиз | Ильгиз |
| Илгизәр | Ильгизар |
| Илгәзәк | Ильгазак |
| Илдан | Ильдан |

| | |
|---|---|
| Илдар | Ильдар |
| Илдархан | Ильдархан |
| Илдус | Ильдус |
| Илдәүләт | Ильдавлет |
| Илзиннәт | Ильзиннат |
| Илкен | Илькен |
| Илкәй | Илькай |
| Илморат | Ильморат |
| Илморза | Ильмурза |
| Илназ | Ильназ |
| Илназар | Ильназар |
| Илнар | Ильнар |
| Илнур | Ильнур |
| Илсаф | Ильсаф |
| Илсуар | Ильсувар |
| Илсур | Ильсур |
| Илтаң | Ильтан |
| Илтимер | Ильтимер |
| Илтуган | Ильтуган |
| Илтөзәр | Ильтузар |
| Илфак | Ильфак |
| Илфан | Ильфан |
| Илфар | Ильфар |
| Илфат | Ильфат |
| Илхан | Ильхан |
| Илчебай | Ильчебай |
| Илчебәк | Ильчебек |
| Илчура | Ильчура |
| Илшан | Ильшан |
| Илшат | Ильшат |
| Ильяр | Ильяр |
| Ильяс | Ильяс |
| Илүс | Ильус |
| Илһам | Ильгам |
| Имай | Имай |
| Имам | Имам |
| Имаметдин | Имаметдин, Имамутдин |
| Имаш | Имаш |
| Имәнгол | Имянгул |
| Имәни | Имяни |
| Инам | Инам |
| Ингам | Ингам |
| Инзил | Инзиль |
| Инсан | Инсан |
| Инсар | Инсар |
| Инсаф | Инсаф |
| Инсафетдин | Инсафетдин |
| Инфаз | Инфаз |
| Иншәр | Иншар |
| Ирам | Ирам |
| Ирас | Ирас |
| Ират | Ират |
| Ирбулат | Ирбулат |
| Ирбәк | Ирбек |
| Ирвиз | Ирвиз |
| Иргази (отч. Иргазиевич, Иргазиевна; фам. Иргазиев, Иргазин) | Иргази (отч. Иргазиевич, Иргазиевна; фам. Иргазиев, Иргазин) |

Иргали
(отч. Иргалиевич, Иргалиевна; фам. Иргалиев, Иргалин)
Иргиз
Ирек
Иректан
Ирза
(отч. Ирзович, Ирзовна; фам. Ирзаев, Ирзин)
Ирзай
Ирзаһид
Иркен
Иркенбай
Иркенбәк
Ирморат
Ирморза
Ирназар
Ирнас
Ирсай
Иртуган
Ирхан
Иршат
Исбах
Искәндәр
Искәндәрбәк
Ислам
Исламбай
Исламбәк
Исламгали
Исламгәрәй
Исламетдин
Исламнур
Исламша
(отч. Исламшевич, Исламшевна; фам. Исламшин)
Исмәгыйль
Исраил
Исрар
Исрафил
Исхак
Исәнбәй
Исәнбәк
Исәнбәт
Исәнгали
(отч. Исәнгалиевич, Исәнгалиевна; фам. Исәнгалиев, Исәнгалин)
Исәнгилде
(отч. Исәнгилдиевич, Исәнгилдиевна фам. Исәнгилдиев, Исәнгилдин)
Исәнгол
Исәнморат
Исәнсәйф
Исәнтай
Исәнтимер

Иргали
(отч. Иргалиевич, Иргалиевна; фам. Иргалиев, Иргалин)
Иргиз
Ирек
Иректан
Ирза
(отч. Ирзович, Ирзовна, фам Ирзаев, Ирзин)
Ирзай
Ирзагид
Иркен
Иркенбай
Иркенбек
Ирмурат
Ирмурза
Ирназар
Ирнас
Ирсай
Иртуган
Ирхан
Иршат
Исбах
Искандер
Искандербек
Ислам
Исламбай
Исламбек
Исламгали
Исламгарай
Исламетдин
Исламнур
Исламша
(отч. Исламшевич, Исламшевна; фам. Исламшин)
Исмагил
Исраиль
Исрар
Исрафиль
Исхак
Исанбай
Исанбек
Исанбат, Исанбет
Исангали
(отч Исангалиевич, Исангалиевна; фам. Исангалиев, Исангалин)
Исангильде
(отч. Исангильдиевич, Исангильдиевна; фам. Исангильдиев, Исангильдин)
Исангул
Исанмурат
Исансайф
Исантай
Исантимер

| | |
|---|---|
| Исәнчура (отч. Исәнчурович, Исәнчуровна; фам. Исәнчуров, Исәнчурин) | Исанчура (отч. Исанчурович, Исанчуровна; фам. Исанчуров, Исанчурин) |
| Исәньяр | Исаньяр |
| Ифрат | Ифрат |
| Ихлас | Ихлас |
| Ихсан | Ихсан |
| Ихтирам | Ихтирам |
| Ишбай | Ишбай |
| Ишбарс | Ишбарс |
| Ишбирде (отч. Ишбирдиевич, Ишбирдиевна; фам. Ишбирдиев, Ишбирдин) | Ишбирде (отч. Ишбирдиевич, Ишбирдиевна; фам. Ишбердиев, Ишбирдин) |
| Ишбул | Ишбул |
| Ишбулат | Ишбулат |
| Ишбүләк | Ишбуляк |
| Ишдәүләт | Ишдавлет |
| Ишембай | Ишембай |
| Ишкенә (отч. Ишкениевич, Ишкениевна; фам. Ишкениев, Ишкенин) | Ишкена (отч. Ишкениевич, Ишкениевна; фам. Ишкениев, Ишкенин) |
| Ишкилде (отч. Ишкелдиевич, Ишкилдиевна; фам. Ишкилдиев, Ишкилдин) | Ишкильде (отч. Ишкильдиевич, Ишкильдиевна; фам. Ишкильдиев, Ишкильдин.) |
| Ишкуәт | Ишкуат |
| Ишкәй | Ишкай |
| Ишлеяр | Ишлеяр |
| Ишморат | Ишмурат |
| Ишморза | Ишмурза |
| Ишмөхәммәт | Ишмухаммет |
| Ишназар | Ишназар |
| Ишнияз | Ишнияз |
| Ишнур | Ишнур |
| Иштай | Иштай |
| Иштимер | Иштимер |
| Иштирәк (отч. Иштирәкович, Иштирәковна; фам. Иштирәков, Иштирәк) | Иштиряк (отч. Иштирякович, Иштиряковна; фам. Иштиряков, Иштиряк) |
| Иштуган | Иштуган |
| Иштукай | Иштукай |
| Ишхан | Ишхан |
| Ишьяр | Ишьяр |
| Йолдыз | Юлдуз |
| Йомагол | Юмагул |
| Йомадил | Юмадиль |
| Йортай | Юртай |
| Йосыф | Юсуп |
| Йосыфҗан | Юсупзян, Юсупджан |
| Йөзикәй | Юзикай |
| Йөзлебай | Юзлебай |
| Йөзлебәк | Юзлебек |
| Йөзленур | Юзленур |
| Йөзмән | Юзман |

| | |
|---|---|
| Йөзәй | Юзай |
| Йөрекбай | Юрукбай |
| Йөсер | Юсир |
| Кабай | Кабай |
| Кабиз | Кабиз |
| Кабил | Кабиль |
| Кабул | Кабул |
| Кави | Кави |
| Кавим | Кавим |
| Кавәс | Кавас |
| Кадер | Кадер |
| Кадербәк | Кадербек |
| Кадергали, Кадерали | Кадергали, Кадерали |
| Кадермәт | Кадермет, Кадырмет |
| Кадерҗан | Кадерзян, Кадерджан |
| Кадыйр | Кадир |
| Кадыйрбәк | Кадирбек |
| Кадыйргали (отч. Кадыйргалиевич, Кадыйргалиевна; фам. Кадыйргалиев, Кадыйргалин) | Кадиргали (отч. Кадиргалиевич, Кадиргалиевна; фам. Кадиргалиев, Кадиргалин) |
| Казанбәк | Казанбек |
| Казбек | Казбек |
| Казим | Казим |
| Казыйхан | Казыхан |
| Каим | Каим |
| Кайморза | Каймурза |
| Калбай | Калбай |
| Калкай | Калкай |
| Калморза | Калмурза |
| Камал | Камал |
| Камали | Камали |
| Камалетдин | Камалетдин |
| Камил | Камиль |
| Камильяр | Камильяр |
| Камус | Камус |
| Камәр | Камар |
| Камәретдин | Камаретдин |
| Карип | Карип |
| Карнай | Карнай |
| Касыйм | Касим |
| Касыймҗан | Касимзян, Касимджан |
| Катип | Катип |
| Кафи | Кафи |
| Кашап | Кашап |
| Кашшаф | Кашшаф |
| Кашшафетдин | Кашшафетдин, Кашшафутдин |
| Каюм | Каюм |
| Каһир | Кахир |
| Килдебай | Кильдибай |
| Килдебәк | Кильдибек |
| Килдеяр | Кильдияр |
| Килмөхәммәт | Кильмухаммет |
| Килчура (отч. Килчурович, Килчуровна, фам. Килчуров, Килчурин) | Кильчура (отч. Кильчурович, Кильчуровна; фам. Кильчуров, Кильчурин) |

| | |
|---|---|
| Кирам | Кирам |
| Кираметдин | Кираметдин, Кирамутдин |
| Кодаш | Кудаш |
| Колбарс | Кулбарс |
| Колгали | Кулгали |
| Колкамәр | Кулкамар |
| Колморат | Кулмурат |
| Колморза | Кулмурза |
| Колмөхәммәт | Кулмухаммет |
| Коләхмәт | Кулахмет |
| Корбан | Курбан |
| Корбангали (отч. Корбангалиевич, Корбангалиевна; фам. Корбангалиев, Корбангалин) | Курбангали (отч. Курбангалиевич, Курбангалиевна; Курбангалиев, Курбангалин) |
| Корбат | Курбат |
| Корыч | Курыч |
| Корычбай | Курычбай |
| Котдус | Кутдус |
| Котлы (отч. Котлиевич, Котлиевна; фам. Котлиев, Котлин) | Кутлы (отч. Кутлиевич, Кутлиевна; фам. Кутлиев, Кутлин) |
| Котлыбай | Кутлыбай |
| Котлыбулат | Кутлыбулат |
| Котлыбәк | Кутлыбек |
| Котлыгәрәй | Кутлыгарай |
| Котлызаман | Кутлызаман |
| Котлыкай | Кутлыкай |
| Котлыкач | Кутлыкач |
| Котлыкыя | Кутлыкыя |
| Котлыморат | Кутлымурат |
| Котлымөхәммәт | Кутлымухаммет |
| Котлытимер | Кутлытимер |
| Котлыяр | Кутлыяр |
| Котлыәхмәт | Кутлыахмет |
| Куандык | Куандык |
| Кушай | Кушай |
| Куәт | Куат |
| Кызылбай | Кызылбай |
| Кылыч | Кылыч |
| Кыям | Кыям |
| Кыяметдин | Кыяметдин |
| Кыяс | Кыяс |
| Кәбир | Кабир |
| Кәлим | Калим |
| Кәлимулла | Калимулла |
| Кәрам | Карам |
| Кәрим | Карим |
| Кәримбай | Каримбай |
| Кәримулла | Каримулла |
| Кәримҗан | Каримджан, Каримзян |
| Кәррам | Каррам |
| Катип | Катип |
| Кәшбетдин | Кашбутдин |
| Кәшби | Кашби |
| Кәшбулла | Кашбулла |

| | |
|---|---|
| Кәшиф | Кашиф |
| Кәшифулла | Кашифулла |
| Кәшфи | Кашфи |
| Кәшфинур | Кашфинур |
| Кәүсәр | Каусар |
| Көмешбай | Кумушбай |
| Көнтимер | Кюнтимер |
| Көнтуган | Кюнтуган |
| Күгеш | Кугуш |
| Күгәй | Кугей |
| Күзкәй | Кузкай |
| Күзәй | Кузей |
| Күктимер | Куктимер |
| Күчәрбай | Кучарбай |
| Күчүм | Кучум |
| Күчүмбай | Кучумбай |
| | |
| Лаек | Лаик |
| Лениз | Лазим |
| Лаис | Лаис |
| Латыйп | Латыйп Латип |
| Латыйф | Латиф |
| Латыйфулла | Латифулла |
| Латыйфҗан | Латифзян, Латифджан |
| Лачын | Лачин |
| Лемаз | Лемаз |
| Лемар | Лемар |
| Ленар | Ленар |
| Ленард | Ленард |
| Лениз | Лениз |
| Локман | Лукман |
| Лотфулла | Лутфулла |
| Лотфый | Лутфи |
| Лотфыйзадә | Лутфизада |
| Ләбиб | Лябиб |
| Ләзиз | Лазиз |
| Ләүз | Лауз |
| | |
| Мазун | Мазун |
| Мазһар | Мазгар |
| Максат | Максат |
| Максуд | Максуд |
| Малик | Малик |
| Мамак | Мамак |
| Маннур | Маннур |
| Мансаф | Мансаф |
| Мансур | Мансур |
| Марат | Марат |
| Марс | Марс |
| Марсель | Марсель |
| Маһиян | Махиян |
| Маһияр | Махияр |
| Мидхәт | Мидхат |
| Миллинур | Миллинур |
| Миндар | Миндар |
| Миндубай | Миндубай |
| Минһаж | Мингаз |

| | |
|---|---|
| Минһаҗетдин | Мингазетдин |
| Мирап | Мирап |
| Мирас | Мирас |
| Мират | Мират |
| Мирбат | Мирбат |
| Мирван | Мирван |
| Мирвәли | Мирвали |
| Миргази | Миргази |
| Миргазиз | Миргазиз |
| Миргазим | Миргазим |
| Миргали | Миргали |
| Миргалим | Миргалим |
| Миргасим | Миргасим |
| Миргата | Миргата |
| Миргаяз | Миргаяз |
| Миргаян | Миргаян |
| Мирза | Мирза |
| Мирзанур | Мирзанур |
| Мирзаһид | Мирзагид |
| Мирзыя | Мирзия |
| Миркасыйм | Миркасим |
| Миркәй | Миркай |
| Мирсалих | Мирсалих |
| Мирсаяф | Мирсаяф |
| Мирсәгыйть | Мирсагит |
| Мирсәет | Мирсаит |
| Мирсәлим | Мирсалим |
| Мирталип | Мирталип |
| Мирфатыйх, Мирфатих | Мирфатих |
| Мирхатим | Мирхатим |
| Мирхатыйп, Мирхатип | Мирхатип |
| Мирхуҗа (отч. Мирхуҗович, Мирхуҗовна;фам. Мирхуҗин) | Мирхуджа Мирхузя (отч. Мирхуджович, Мирхуджовна; фам. Мирхуджин, Мирхузин) |
| Мирхәйдәр | Мирхайдар |
| Мирхәсән | Мирхасан |
| Мирхәсәп | Мирхасап |
| Мирхәт | Мирхат |
| Миршәрәф | Миршараф |
| Мирҗан | Мирджан, Мирзян |
| Мисаил | Мисаиль |
| Мисбах | Мисбах |
| Мисбахетдин | Мисбахетдин |
| Мисхәт | Мисхат |
| Мифтах | Мифтах |
| Мифтахетдин | Мифтахетдин, Мифтахутдин |
| Миңлебай | Минлебай |
| Миңлевәли | Минлевали |
| Миңлегази | Минлегази |
| Миңлегали, Миңгали (фам. Миңлегалиев, Миңгалиев, Миңгалин) | Минлегали, Мингали (фам. Минлегалиев, Мингалиев, Мингалин) |
| Миңлегази | Минлегази |
| Миңлегазиз | Минлегазиз |
| Миңлегата | Минлегата |
| Миңлегаяз | Минлегаяз |

| | |
|---|---|
| Миңлегол | Минлегул, Миннегул |
| Миңлегәрәй | Минлегарай |
| Миңлекәй | Минлекай |
| Миңлекәрим | Минлекарим |
| Миңленур | Минленур |
| Миңлесафа | Минлесафа |
| Миңлесәет | Минлесаит |
| Миңлеталип | Минлеталип |
| Миңлетимер | Минлетимер |
| Миңлефатыйх, Миңлефатих | Минлефатих |
| Миңлефаяз | Минлефаяз |
| Миңлехак | Минлехак |
| Миңлехан | Минлехан |
| Минлехәер | Минлехаир |
| Миңлехәй | Минлехай |
| Миңлехәйдәр | Минлехайдар |
| Миңлехәсән | Минлехасан |
| Миңлешакир | Минлешакир |
| Миңлешәех | Минлешаих |
| Миңлеяр | Минлеяр |
| Миңлеәхмәт | Минлеахмет |
| Миңлеҗан | Минлезян, Минледжан |
| Миңлеһади | Минлехади |
| Миңнулла | Миннулла |
| Миһран | Миграв |
| Могаззам | Мугаззам |
| Могтәбәр | Мугтабар |
| Могыйн | Мугин |
| Мозаффар | Музаффар |
| Мокатдәм | Мукатдам |
| Мокатдәр | Мукатдар |
| Мокатдәс | Мукатдас |
| Морадым | Мурадым, Мурадим |
| Морат | Мурат |
| Моратбакый | Миратбаки |
| Моратбәк | Муратбек |
| Моратгали (отч. Моратгалиевич, Моратгалиевна; фам. Моратгалиев, Моратгалин) | Муратгали (отч. Муратгалиевич, Муратгагалиевна; фам. Муратгалиев, Муратгалин) |
| Морза (отч. Морзович, Морзовна, фам. Морзаев, Морзин) | Мурза (отч. Мурзович, Мурзовна; фам. Мурзаевич, Мурзин) |
| Морзабәк | Мурзабек |
| Морзавәли | Мурзавали |
| Морзагали (отч. Морзагалиевич, Морзагалиевна; фам. Мурзагалиев, Морзагалин) | Мурзагали (отч. Мурзагалиевич, Мурзалиевна; фам. Морзагалиев, Мурзагалин) |
| Морзанур | Мурзанур |
| Морзахан | Мурзахан |
| Морзахәбиб | Мурзахабиб |
| Морзаҗан | Мурзаян, Мурзаджан |
| Мортаза | Муртаза |
| Мосавир | Мусавир |
| Мостай | Мустай |
| Мостафа | Мустафа |

| | |
|---|---|
| Моталлап | Муталлап |
| Моталлип | Муталлип |
| Мотаһһар | Мутаххар |
| Мотыйгулла | Мутыйгулла |
| Мохлис | Мухлис |
| Мохтар | Мухтар |
| Муллабай | Муллабай |
| Муллагали (отч. Муллагалиевич, Муллагалиевна; фам. Муллагалиев) | Муллагали (отч. Муллагалиевич, Муллагалиевна; фам. Муллагалиев) |
| Муллагол | Муллагул |
| Муллакай | Муллакай |
| Мулланур | Мулланур |
| Муллахан | Муллахан |
| Муллаяр | Муллаяр |
| Муллаәхмәт | Муллаахмет |
| Муллаҗан | Муллазян, Мулладжан |
| Муса | Муса |
| Мусабай | Мусабай |
| Мусабәк | Мусабек |
| Мусагали (отч. Мусагалиевич, Мусагалиевна; фам. Мусагалиев) | Мусагали (отч. Мусагалиевич, Мусагалиевна; фам. Мусагалиев) |
| Мусакай | Мусакай |
| Мусанур | Мусанур |
| Мусахан | Мусахан |
| Мәгаз | Магаз |
| Мәгафур | Магафур |
| Мәгыйн | Магин |
| Мәгъдән | Магдан |
| Мәгънәви | Магнави |
| Мәгърур | Магрур |
| Мәгъруф | Магруф |
| Мәгъсум | Магсум |
| Мәгъсумҗан | Магсумджан, Магсумзян |
| Мәкъсуд | Магсуд |
| Мәмәт | Мамет |
| Мәмнун | Мамнун |
| Мәнзил | Манзиль |
| Мәннан | Маннан |
| Мәннап, Мәннаф | Маннап, Маннаф |
| Мәрван | Марван |
| Мәрви (отч. Мәрвиевич, Мәрвиевна; фам, Мәрвиев, Мәрвин) | Марви (отч. Марвиевич, Марвиевна; фам. Марвиев, Марвин) |
| Мәрвәт | Марват |
| Мәргуб | Маргуб |
| Мәргән | Марган |
| Мәрдан | Мардан |
| Мәрданша | Марданша |
| Мәрди (отч. Мәрдиевич, Мәрдиевна; фам. Мәрдиев) | Марди отч. Мәрдиевич, Мардиевна; фам. Мардиев) |
| Мәрҗән | Марджан |
| Мәсгут | Магсут |

| | |
|---|---|
| Мәснәви | Маснави |
| Мәсрур | Масрур |
| Мәхиян | Махиян |
| Мәхмүт | Махмут |
| Мәхмүтгәрәй | Махмутгарай |
| Мәхүб | Махуб |
| Мәшһүр | Машхур |
| Мәүла | Мауля |
| Мәүләбай | Маулябай |
| Мәүлаша | Мауляша |
| Мәүли (отч. Мәүлиевич, Мәүлиевна; фам. Мәүлиев, Мәүлин) | Маули, Мавли (отч. Маулиевич, Маулиевна; фам. Маулиев, Мавлиев, Маулин, Мавлин) |
| Мәүлихан | Маулихан |
| Мәүлияр | Маулияр |
| Мәүлиҗан | Маулизян, Маулиджан |
| Мәүләви | Мавлави |
| Мәүлән | Маулан |
| Мәүлүт | Маулют |
| Мәүҗүд | Маузюд |
| Мәҗит | Мазит |
| Мәһди | Магди |
| Мөбарәк | Мубарак |
| Мөбарәкша | Мубаракша |
| Мөбарәкҗан | Мубаракзян, Мубаракджан |
| Мөбин | Мубин |
| Мөгаззәм | Мугаззам |
| Мөгаллим | Мугаллим |
| Мөгыйн | Мугин |
| Мөгътәсим | Мугтасим |
| Мөгътәсип | Мугтасип |
| Мөдәррис | Мударрис |
| Мөкаддәм | Мукаддам |
| Мөкаддәр | Мукаддар |
| Мөкатдәс | Мукатдас |
| Мөкыйм | Муким |
| Мөкәррәм | Мукаррам |
| Мөнасип | Мунасип |
| Мөнзир | Мунзир |
| Мөнип | Мунип |
| Мөнир | Мунир |
| Мөнис | Мунис |
| Мөниф | Муниф |
| Мөнәвир | Мунавир |
| Мөнәвәр | Мунавар |
| Мөрсәлим | Мурсалим |
| Мөршид | Муршид |
| Мөрәсим | Мурасим |
| Мөсәви | Мусави |
| Мөсәвәт | Мусават |
| Мөсәгыйть | Мусагит |
| Мөслим | Муслим |
| Мөслих | Муслих |
| Мөстәкыйм | Мустаким |
| Мөсәвир | Мусавир |

| | |
|---|---|
| Мөсәлим | Мусалим |
| Мөфти | Муфти |
| Мөфәррах | Муфаррах |
| Мөфәххәр | Муфаххар |
| Мөхетдин | Мухутдин |
| Мөхиб | Мухиб |
| Мөхибулла | Мухибулла |
| Мөхсин | Мухсин |
| Мөхтәрәм | Мухтарам |
| Мөхәммәт | Мухаммет |
| Мөхәммәтхан | Мухаметхан |
| Мөхәммәтша | Мухамметша |
| Мөхәммәтьяр | Мухамметьяр |
| Мөхәммәтҗан | Мухамметзян, Мухамметджан |
| Мөхәррәм | Мухаррам |
| Мөштәри | Муштари |
| Мөшәрип | Мушарип |
| Мөэмин | Мумин |
| Мөяссәр | Муяссар |
| Мөҗавир | Муджавир |
| Мөҗип | Муджип, Музип |
| Мөҗәһит | Муджагит, Музагит |
| | |
| Набикъ | Набик |
| Набит | Набит |
| Навак | Навак |
| Навил | Навиль |
| Нади (отч. Надиевич, Надиевна; фам. Надиев) | Нади (отч. Надиевич, Надиевна, фам. Надиев) |
| Надим | Надим |
| Надир | Надир |
| Надирбай | Надирбай |
| Надирхан | Надирхан |
| Надирша | Надирша |
| Назар | Назар |
| Назарбай | Назарбай |
| Назаргали (отч. Назаргалиевич, Назаргалиевна; фам. Назаргалиев, Назаргалин) | Назаргали (отч. Назаргалиевич, Назаргалиевна; фам. Назаргалиев, Назаргалин) |
| Назир | Назир |
| Назиф | Назиф |
| Назифулла | Назифулла |
| Назих | Назих |
| Назыйм | Назим |
| Назыйр | Назир |
| Наиб | Наиб |
| Наид | Наид |
| Наиз | Наиз |
| Наил | Наиль |
| Наим | Наим |
| Наир | Наир |
| Намус | Намус |
| Нарбәк | Нарбек, Нарбик |
| Наргиз | Наргиз |
| Нарим | Нарим |

| | |
|---|---|
| Нариман | Нариман |
| Насих | Насих |
| Насихетдин | Насихетдин |
| Насретдин | Насретдин |
| Насрый | Насри |
| Насыйб | Насиб |
| Насыйбулла | Насибулла |
| Насыйр | Насыр |
| Насыйрулла | Насырулла |
| Насыйф | Насиф |
| Нажар | Назар |
| Нигъмәт | Нигмат |
| Нигъмәтулла | Нигматулла |
| Нигъмәтҗан | Нигматджан, Нигматзян |
| Низам | Низам |
| Низаметдин | Низаметдин, Низамутдин |
| Низами | Низами |
| Низуан | Низуан |
| Нил | Нил |
| Нияз | Нияз |
| Ниязбәк | Ниязбек |
| Ниязгали | Ниязгали |
| Ниҗат | Ниджат |
| Ниһат | Нихат |
| Ногман | Нугман |
| Нократ | Нукрат |
| Носрат | Нусрат |
| Нотфулла | Нутфулла |
| Нугай | Нугай |
| Нугайбәк | Нугайбек |
| Нур | Нур |
| Нурафшан | Нурафшан |
| Нурбулат | Нурбулат |
| Нурбәк | Нурбек |
| Нурвафа (отч. Нурвафович, Нурвафовна; фам. Нурвафин) | Нурвафа (отч. Нурвафович, Нурвафовна; фам. Нурвафин) |
| Нурвахит | Нурвахит |
| Нурвил | Нурвиль |
| Нурвәли | Нурвали |
| Нургази (отч. Нургазиевич, Нургазиевна; фам. Нургазиев, Нургазин) | Нургази (отч. Нургазиевич, Нургазиевна; фам. Нургазиев, Нургазин) |
| Нургазиз | Нургазиз |
| Нургазим | Нургазим |
| Нургали (отч. Нургалиевич, Нургалиевна; фам. Нургалиев, Нургалин) | Нургали (отч. Нургалиевич, Нургалиевна; фам. Нургалиев, Нургалин) |
| Нургалим | Нургалим |
| Нургата (отч. Нургатович, Нургатовна; фам. Нургатин) | Нургата (отч. Нургатович, Нургатовна; фам. Нургатин) |
| Нургафур | Нургафур |
| Нургаяз | Нургаяз |

| | |
|---|---|
| Нургаян | Нургаян |
| Нургиз | Нургиз |
| Нургизәр | Нургизар |
| Нургәрәй | Нургарай |
| Нурдәүләт | Нурдавлет |
| Нуретдин | Нуретдин |
| Нурзаман | Нурзаман |
| Нурзаһид | Нурзагид |
| Нурзил | Нурзиль |
| Нурзирәк | Нурзиряк |
| Нурзыя (отч. Нурзиевич, Нурзиевна; фам. Нурзиев, Нурзин) | Нурзия (отч. Нурзиевич, Нурзиевна; фам. Нурзиев, Нурзин) |
| Нури, Нурый | Нури |
| Нурис | Нурис |
| Нурислам | Нурислам |
| Нурихан | Нурихан |
| Нуриш | Нуриш |
| Нуришан | Нуришан |
| Нурияздан | Нурияздан |
| Нуриәхмәт | Нуриахмет |
| Нуркай | Нуркай |
| Нурлы (отч. Нурлиевич, Нурлиевна; фам. Нурлиев, Нурлин) | Нурлы (отч. Нурлиевич, Нурлиевна; фам. Нурлиев, Нурлин) |
